ISSN 2618-9623

Төбәк тарихы буенча журнал

Краеведческий журнал

# Туган җир

## Родной край

3*2019

## Из «Обращения Исполнительного комитета Всероссийского мусульманского совета» Временному правительству по вопросу национально-культурной автономии мусульман



*30 сентября 1917 г.*

Основа Культурно-национальной автономии сибирских мусульман

Принята I Сибирским областным мусульманским съездом, проходившем 4-I2 октября I9I7 г. в г. Томске

I. Сибирская областная Дума не должна вмешиваться, ни в коем случае, в дела национальные в области: I) духовной, культурно-просвитительной...

3. Право родного языка:

тюрко-татарский язык должен быть приравнен в правах с общегосударским [общегосударственным] языком и применяться: а) в школах, б) судебных учреждениях, в) административных учреждениях.

4. По народному образованию:

в открытых национальных низших, средних и высших учебных заведениях преподавание должно быть на родном языке причем в тех средних и высших учебных заведениях, открытых для других национальностей, если учащиеся тюрко-татары достигнут определенного количества, то должен преподаваться родной язык.

5. Управление и заведование по делам народного образования ... должно находиться в распоряжении соответствующих организаций, избираемых самими мусульманами.

6. Впредь, до открытия мусульманами высших учебных заведений, в Сибири, в Сибирских университетах должны открываться специальные восточные кафедры для преподавания тюрко-татарских: языка, истории и литературы.

7. ... в местностях, населенных тюрко-татарскими народностями, для них должны быть учреждены особые судебные учреждения ... и должен применяться родной язык, как устно, так и письменно.

8. Судьи, несомненно, должны владеть местным тюрко-татарским наречием.

Источник: I00-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов. Казань: Изд-во «Заман», 20I7. С. 40I-402.

Бөтендөнья татар конгрессы
Татарстан Республикасы татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте

# ТУГАН ҖИР

Төбәк тарихы буенча журнал

**3*2019**

Казан – 2019

Всемирный конгресс татар
Общество татарских краеведов Республики Татарстан

# РОДНОЙ КРАЙ

Краеведческий журнал

3*2019

Казань – 2019

УДК 908
ББК 26.89 (2Рос.Тат)
Т 70

**Баш мөхәррир:**
Дамир Мәүләви улы Исхаков,
тарих фәннәре докторы

**Баш мөхәррир урынбасары:**
Борһанов Альберт Әхмәтҗан улы,
тарих фәннәре кандидаты

**Редакцион коллегия:**
Аблязов Камил
Акчурин Мәгъсум
Бәйрәмова Фәүзия
Гатауллин Ринат
Гариф Нурулла
Гыйләҗев Искәндәр
Габдрафиков Илдар
Закиров Ринат
Измайлов Искәндәр
Ситдиков Айрат
Сафин Фаиль
Тычинских Зәйтүнә
Хисамов Олег
Шәйдуллин Рафаил

**Редакцион-нәшер итү төркеме**
***Җаваплы сәркәтип:***
Сәгыйдуллина Мөнирә Хәлим кызы
***Чыгарылыш өчен җаваплы***
Дәүләтшина Гөлнара Фарикъ кызы

**Главный редактор:**
Дамир Мавлявеевич Исхаков,
доктор исторических наук

**Заместитель главного редактора:**
Бурханов Альберт Ахметжанович,
кандидат исторических наук

**Редколлегия:**
Аблязов Камиль
Акчурин Магъсум
Байрамова Фаузия
Гатауллин Ринат
Гариф Нурулла
Гилязов Искандер
Габдрафиков Ильдар
Закиров Ринат
Измайлов Искандер
Ситдиков Айрат
Сафин Фаиль
Тычинских Зайтуна
Хисамов Олег
Шайдуллин Рафаиль

**Редакционно-издательская группа**
***Ответственный секретарь:***
Сагидуллина Мунира Халимовна
***Ответственный за выпуск***
Давлетшина Гульнара Фариковна

**Басманың адресы:**
Казан шәһәре, Карл Маркс ур., 38/5
e-mail: Monitoring_vkt@mail.ru
Татар төбәк тарихы буенча кварталлык журнал
Татар һәм рус телләрендә

**Адрес издания:**
г. Казань, ул. Карла Маркса, 38/5
e-mail: monitoring_vkt@mail.ru
Ежеквартальный журнал по татарскому краеведению
На татарском и русском языках

ISSN 2618-9623

**Туган җир:** Төбәк тарихы буенча журнал [Родной край: Краеведческий журнал].
№ 3. Казан: Бөтендөнья татар конгрессы. 2019.

## Эчтәлек

*Р.Ш. Шәйдуллина.*
Оныкларга хат ........................................ 10

***Киләчәккә юл: Татар стратегиясе – 2050***

«Татар халкының үсеш стратегиясе» структурасы........................................ 11

***Милли һәм төбәк тарихын өйрәнүнең фәнни-методологик яклары***

*Д.М. Исхаков.*
Халкыбызның эпик әсәрләрендә яшеренгән милли тарихыбыз. Өченче язма: «Чура батыр» дастаны һәм «киләчәк буыннарны кисәтү» (дәвамы). ........................................ 12

*И.Л. Измайлов.*
Үзәк Азиядәге борынгы татарлар (VI–IX гасырлар)(дәвамы)................ 39

*М.Х. Бакиров.*
Болгарга тоташкан тамырларыбыз (1-нче кисәк). ........................................ 50

*Р.Ф. Гатауллин.*
Милли мохитнең асылы һәм чикләре. ........................................ 64

***Төбәк тарихы буенча фәнни мәкаләләр***

*Ф.Ә. Бәйрәмова.*
Самар ярымутравында татар тарихы (дәвамы). ........................................ 68

*Р.Х. Әмирханов, И.Р. Габдуллин.*
Нефть сәнагатьчесе Надыр Уразмәтов һәм аның заманы (дәвамы). ...... 82

*И.Е. Алексеев.*
Мәрьям Ана иконасы барлыкка килү тарихында «татар эзе»... .......... 100

*С.П. Саначин.*
Казан Богородица иконасы барлыкка килүенең һәм Гермоген биографиясенең ике рәсемле повесть буенча яңа нечкәлекләре. .......... 121

*Ф.Ш. Нуриева.*
Татар халкы кулланган еллар, айлар һәм көннәрнең атамалары хакында Хәсән Гали язмасы. ........................................ 130

*А.И. Бугарчёв, О.В. Степанов.*
Татарстан Республикасы Әлки районыннан нумизматик материаллар. .. 139

***Фәнни-популяр язмаларда төбәк тарихы***

*Н.Г. Гариф.*
Нәсел тамырыңны барлыйм дисәң... ........................................ 146

*Ф.М. Гыйльманов.*
Чуракайның Пенза татарлары. ....................................................149

*Д.Н. Таҗи.*
Кыям Җәгъфәров: автобиографик истәлекләр (дәвамы)....................158

*Т.Т. Нигъмәтҗанов.*
Җиде муза-алиһә клубы. ............................................................170

*М.М. Гыймадиев.*
Иске Шәйморза авылы тарихыннан. ..............................................179

*И.Г. Закирова, Л.Х. Мөхәммәтҗанова.*
Халык җәүһәрләре сагында..........................................................182

**_Мирасыбызның төбәк тарихына кагылышлысы_**

«Идегә» дастаны (дәвамы). ..........................................................195

**_Төбәк тарихына караган тарихи чыганаклар_**

П.С. Паллас китабыннан өзек .......................................................207

Геодезия укучысы Павел Зубринскийның Надыр Уразмәтов бакчасындагы нефть урыннары турында Оренбург тау башлыгына белдермәсе. ..........................................................................210

**_Олуг Татар иле_**

*Балгынай Норлан.*
Чәүчәккә сәяхәт. ........................................................................212

**_Ирек мәйданы_**

*Ф.М. Нәбиуллин.*
Халыкның җәрәһәте.....................................................................215

**_Шәхесләребез_**

*Р.Р. Минһаҗ.*
Ялантауга ай кунган....................................................................223

*И.Г. Закирова.*
Луиза Себерле. ..........................................................................231

**_Татар рухы_**

*Р.М. Батулла.*
Чыңгыз хан. ..............................................................................235

*А.Г. Хәйретдин.*
Коръәндә бәян ителгән реинкарнация тәгълиматына кереш (дәвамы). ...................................................................................244

***Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар. Хатлар һәм кайтавазлар***

Хроника.....................................................................................................258

***Төбәк тарихына караган хезмәтләр турында мәгълүмат. Рецензияләр***

*Л. Р. Сурметова.*
Ф. Йосыповның «Себер татарлары фольклоры антологиясе»нә бер күзәтү. .........................................................................................262

***Хушлашу***

Ул яшәргә тиеш иде... .........................................................................267

***Авторлар буенча белешмә***

## Содержание

*Р.Ш. Шайдуллина.*
Письмо внукам. ....................................................................................10

***Путь в будущее: Татарская стратегия – 2050***

Структура «Стратегии развития татарского народа» ..............................11

***Научно-методологические аспекты изучения национальной истории и краеведения***

*Д.М. Исхаков.*
Наша национальная история, запрятанная в эпических произведениях народа. Третья публикация: дастан «Чура батыр» и «предупреждение будущих поколений» (продолжение). ......................................................12

*И.Л. Измайлов.*
Древние татары в Центральной Азии (VI–IX вв.) (продолжение)..........39

*М.Х. Бакиров.*
Наши корни из Булгар (часть 1)..............................................................50

*Р.Ф. Гатауллин.*
Сущность и границы этнопространства. ..................................................64

***Научные публикации по краеведению.***

*Ф.А. Байрамова.*
История Самарской Луки (продолжение)..................................................68

*Р.Х. Әмирханов, И.Р. Габдуллин.*
Нефтепромышленник Надыр Уразметов и его время (продолжение). ..82

*И.Е. Алексеев.*
«Татарский след» в истории обретения Казанской иконы Божией Матери.....................................................................................................100

*С.П. Саначин.*
Новые подробности обретения Казанской иконы богородицы и биографии Гермогена по двум лицевым повестям её явления. ............121

*Ф.Ш. Нуриева.*
Об использовании татарским народом терминов наименований годов, месяцев и дней в публикации Хасана Гали. ............................................130

*А.И. Бугарчёв, О.В. Степанов.*
Нумизматические материалы из Алькеевского района РТ...................139

***Краеведение в научно-популярных публикациях.***

*Н.Г. Гариф.*
Если захочешь установить свою генеалогию..........................................146

*Ф. М. Гильманов.*
Пензенские татары в Чуракаево. ........................................149
*Д. Н. Тажи.*
Киям Жагфаров: автобиографические воспоминания (продолжение)...158
*Т. Т. Нигаматзянов.*
Клуб семи муз. ........................................170
*М. М. Гимадеев.*
История села Старое Шаймурзино. ........................................179
*И. Г. Закирова, Л. Х. Мухаметзянова.*
На страже жемчужин народа. ........................................182

***Наше историко-краеведческое наследие***

Дастан «Идеге» (продолжение). ........................................195

***Исторические источники по краеведению.***

Отрывок из книги П. С. Палласа. ........................................207
Доношение геодезии ученика Павла Зубринского Оренбургскому горному начальснику о нефтяных местах в дачах Надыра Уразметева. ........................................210

***Magna Tartaria***

*Балгынай Норлан.*
Путешествие в Чаучак. ........................................212

***Площадь Свободы***

*Ф. М. Набиуллин.*
Травмы народа........................................215

***Известные личности***

*Р. Р. Мингазов.*
Взошел месяц над Ялантау........................................223
*И. Г. Закирова.*
Луиза Сибирская. ........................................231

***Татарский дух***

*Р. М. Батулла.*
Чингиз хан. ........................................235
*А. Г. Хайрутдинов.*
Введение в учение о реинкарнации, изложенное в Коране. ..................244

***Краеведческие конференции и встречи. Письма и отклики***

Хроника........................................258

***Информация о краеведческих трудах. Рецензии***

*Л. Р. Сурметова.*
Обзор книги Ф. Юсупова «Себер татарлары фольклоры антологиясе». ... 262

***Некрологи***

Он должен был жить… ... 267

***Сведения об авторах***

*Равилә Шәйдуллина*

## ОНЫКЛАРГА ХАТ

Сез бит – татар малайлары,
Сез мөселман затыннан.
Ягез, бер дога кылыгыз
Мин – дәү әни артыннан.

Сез – мөселман малайлары,
Мөхәммәт өммәтеннән.
Ә без, улым, табындык шул
Совет хөкүмәтенә.

Тыңламадык бабайларны,
Динне бар дип белмәдек.
Ничек дөнья исән калды,
Ничекләр тилермәде?!

Манарасыз мәчетләрдә
Элдек совет сурәтен.
Имеш, безгә туры юлны
Ленин үзе күрсәтте.

Изгеләрнең кабер ташын
Салдык чиркәү астына.
Имансыз калган күңелләр
Оялмады аз гына.

Тыпыр-тыпыр биедек без,
Мәчетләрне клуб итеп.
Гарипләнде безнең җаннар,
Шайтанның исе китте.

Кырга сыймады кыланыш,
Намусны без югалттык.
Никахсыз гына сөештек,
Никахсыз бала таптык.

Инде менә дингә килдек,
Намазлыкларны җәйдек.
Без аңлаган хөрриятнең
Ялгыш икәнен белдек.

Ярлыка, дип, бер Ходаем,
Сәҗдәдә башым орам.
Безнең буын ялгышларын
Кабатлама син, олан!

**Киләчәккә юл: Татар стратегиясе – 2050**

**Путь в будущее: Татарская стратегия – 2050**

*Группа татарских экспертов, объединенных вокруг Центра этнологического мониторинга ВКТ, в ходе обсуждения проекта «Стратегии развития татарского народа» до 2050 г. в первой половине текущего года, решила предложить собственный вариант структуры данного документа. Редакция полагает, что она заслуживает внимания и поэтому решила ее опубликовать. В дальнейшем данная группа разработчиков предполагает подготовить и концептуальную часть «Стратегии развития татарского народа».*

## СТРУКТУРА «СТРАТЕГИИ РАЗВИТИЯ ТАТАРСКОГО НАРОДА»

Введение: нация и государство.

I. Состояние нации. Исторический и структурный анализ.
II. Национальная экономика и формирование национального капитала.
III. Социальная стратификация татарского общества: проблема становления среднего класса.
IV. Воспроизводство нации. Семья. Генофонд.
V. Экология и нация.
VI. Формирование национальной системы воспитания и образования.
VII. Языковая политика.
VIII. Национальная культура: новые парадигмы в информационный век.
IX. Национальная гуманитарная наука. Формирование татарской идентичности.
X. Основные направления научно-информационного обеспечения национального развития. Национальная информационная система.
XI. Кадры и интеллект нации.
XII. Татарско-мусульманская умма: организационное строение и интеллектуальное развитие.
XIII. Геополитическое измерение татарского мира: принципы и механизмы связей региональных групп татар с Татарстаном.

## Милли һәм төбәк тарихын өйрәнүнең фәнни–методологик яклары

## Научно-методологические аспекты изучения национальной истории и краеведения

***Д.М. Исхаков***

### ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ЭПИК ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ЯШЕРЕНГӘН МИЛЛИ ТАРИХЫБЫЗ.
### Өченче язма: «Чура батыр» дастаны һәм «киләчәк буыннарны кисәтү».

*«Чора батыр» – телдән сөйләнүче эшкәртелгән дастан.*
*Ул Үзәк Азиядәге миллилекнең (идентитетның)*
*әһәмиятле якларын чагылдыра».*

*Хәсән Б. Паксой*

***«Чура батыр» дастанының кыскача эчтәлеге***

Кыпчак телле күп кенә төрки халыкларда (төрле төркем татарларда, башкортларда, нугайларда, каракалпакларда, казахларда) сакланган «Чура (Чора~Шора) батыр» исемле эпик әсәр (кайбер халыкларда, мәсәлән, казахларда, аның атасына багышланган дастан да бар) төрки-татарлар тарихының әһәмиятле бер чорын яктырта – сүз Алтын Урданың сәяси варислары булган дәүләтләрнең бәйсезлекләрен югалта башлаган дәвер турында бара.

Шушы заманнарда (исегезгә төшерәм, XVI-нчы гасыр урта гасырларның соңгы йөз еллыгы булган, чөнки Яңа вакыт XVII-нче гасырдан башлана) татарлар руслар белән бик нык конфронтациягә кергәннәр. Бу дәвер турында без күбесенчә рус чыганакларыннан гына беләбез, чөнки татар җәмгыятьләрендә тудырылган тарихи чыганаклар аз сакланган (Кырым ханлыгы буенча күбрәк), шуның өстенә озак еллар буенча Россияда официаль тарихчылар аларны, беренче чиратта яулап алучылар белән татарлар арасында булган каршылыклар турындагыларын, инкарь итеп килделәр. Аеруча бу идеологик мәсьәләләрне яктырткан чыганакларга карый. Шуңа күрә дә XVI-нчы йөздән сакланган эпик әсәрләрнең

әһәмияте бик зур. Бу әсәрләр яулап алу эшенә керешүчеләр тарафыннан «санкцияләнмәгән» [Paksoy: 1986. P.253] булу сәбәпле, аларда шул дәвер бабаларыбызның дөньяга аутентик, чын карашлары сакланып калган. АКШта яшәп иҗат иткән күренекле төрек тарихчысы һәм фольклорчысы Хәсән Б.Паксой язганча, тикшерә торган дәвергә караган «Чура батыр» дастаныныда башка проблемалар белән бергә «киләчәк буыннарны кисәтү» дә сакланган [Paksoy: 1986. P.253]. Нәрсә турында кисәтә соң безне ул дастан? Бу кисәтүнең асылын аңлау өчен безгә шушы эпос аркылы XVI-нчы йөз татар җәмгыятьләренең үзенчәлекләрен, гомүми яшәү контекстларын өйрәнү кирәк булачак. Шул вакытта рус чыганакларының тарихи процессны берьяклы гына яктыртулары ачылыр һәм бабаларыбыз яшәгән XVI-нчы йөз тарихы белән бүгенге буыннарны бер тарихи агымга тоташтыруның дастаннарда сакланган мәгълүматлардан, татарларның дөньяга, тарихи вакыйгаларга үз карашларыннан башка, мөмкин түгеллеге күренер. «Чура батыр» дастаны моның өчен җирлекне җитәрлек итеп бирә.

Без тикшерә торган дастан фольклорчылар тарафыннан, шул исәптән, Татарстанда да (карагыз: [Урманче: 1995–1996; Ибраһимова: 2002]), шактый өйрәнелде. Әйтик, Л.Х. Ибраһимова хезмәтендә «Чура батыр» эпосының милли версияләрен барлау һәм аларны тикшерү тарихы да бирелгән. Казахстанда да шундый хезмәт басылды [Қорғанбеков: 2014]. Бу безгә аларда тикшерелгән мәсьәләләргә кермичә турыдан-туры төп проблемага – дастан кысаларында сакланып калган халкыбыз тарихына, аның XVI-нчы гасырдагы кискен борылыш дәвере өчен хас булган татар менталитетына, ул дастанда хәрәкәт иткән батырларның тарихи прототипларына мөрәҗәгать итү мөмкинлеген бирә.

Иң башлап, өйрәнелә торган эпосның төп сюжет линиясен карап чыгып, аның героеның кемлеге мәсьәләләренә тукталып китик.

Татарларда язып алынган дастан версияләреннән (карагыз: [Татар халык иҗаты: 1984. 108–119 бб.; Татар эпосы: 2004. 386–398 бб.; Къырымтатар: 1991. 57–72 бб.]) эпосның түбәндәге эчтәлекле булуы күренә.

«Дагстан йортыннан» булган Казый би атлы бер «олуг мирза» күчеп йөргән вакытта бер ир бала табып ала, аңа Наррән/Нарәң (нар рәңле – кызыл битле, ут төсле) дип исем бирә һәм ул бала шушы би янында тәрбияләнеп, үсеп җитә. Казый би аны Миңсылу исемле «Кабак башы Кара үздән» исемле кешенең кызына өйләндерә. Соңыннан Казый бинең энесе Канмирза Миңсылуга гашыйк булып, Нарәң батыр аны, хатынына дәгъвә кылган өчен, би янында кылыч белән чабып үтергәч, бу батыр хатынын алып качып китә һәм «Хаҗитархан шәһәренә, Акча солтанга килеп», шунда көн итә башлый. Ләкин бу солтанның да аның бик чибәр хатыны-

на күзе төшә, шуннан Нарәң батыр аны да үтереп, тагы качып китә, шул вакытта юлда аның улы туа, аңа Чура дигән исем кушыла. Ахыр чиктә алар «Кырымга барып», шунда торалар. Кечкенә вакыттан ук Чура балалар башына басып, «батыр» исеме йөртә, аның даны Кырымнан «Идел халкына» да барып җитә. Үскәч шунда китеп Чура Колынчак атлы берәүнең кәләшен урлап, аның белән бергә кача, соңыннан алар кире кайтып, Колынчакның рөхсәте белән, никах кылалар, ә Чура Колынчакка үзенең кыз туганын хатынлыкка бирергә вәгъдә итеп, алар Кырымга кайтып китәләр.

Чура батыр «Идел тарафында» йөргәндә, Кырымдагы Акташтан Гали (Али) бәк атлы берәү Нарәң батырны талап, кыйнап, Миңсылуга «яман сүзләр» әйтеп, китеп бара. Чура батыр кайткач, атасы аңа бу турыда сөйли, моны тыңлаганнан соң батыр Гали бине башын кисеп үтерә, әмма нәтиҗәдә аңа читкә китәргә туры килә – «шул киткәндә Чура батыр Казан шәһәренә барды», – диелә эпоста. Ул анда килгәндә Колынчак батыр да шунда икән, башка батырлар арасына кергән Чура алар белән бергә Казан шәһәрен алырга тырышкан рус гаскәре белән сугышларда катнаша. Ә Кырымда ул вакытта үтерелгән Гали бәкнең кардәшләре Нарәң батырдан үч алып, аның бөтен байлыгын тартып алалар, ул хатыны Миңсылу белән бөлгенлеккә төшә.

Русларны исә Казанда үзләренә нык каршылык күрсәткән Чура батыр борчый, алар хәтта астрологларын (мөнәҗҗимнәрен) җыеп, азтырләб (астрономия приборы астролябия) аркылы карап, белергә уйлыйлар – ничек Чура батырның әҗәле килүе мөмкин икәнлеген. Ысул табыла: Чура батырның әҗәле бер кыздан икән. Шуңа күрә руслар матур киенгән кызны сайлап алып, аңа җибәрәләр, ул аннан йөкле булгач, качып кире кайтырга тиеш була. Ул шулай эшли дә, кайткач исә бу хатын бер ир бала таба. Аны руслар үзләрендә тәрбияләп үстерәләр һәм Чура батырның улы рус гаскәрендә хезмәт итә башлый.

Ул заманда Кырымда калган Нарәң батыр ярлылыкка түзә алмый Казандагы улы Чура янына килә, бик хәерче кыяфәттә булгач, Чура аны башта танымаган булып тора, аннан соң төрле хәйләләр белән аны үзе хезмәт иткән гаскәр белән таныштыра. Нарәң турында сүз Шаһали ханга барып ирешә. Хан исә Нарәңне үз янына алдырып, хөрмәт итеп, аңа бүләкләр бирә, бу батырны үзендә тота.

Ул арада Шаһали кызы Сарыкани батырларга, һәрберсенең дәрәҗәсенә күрә, бүләкләр өләшә. Чура батырга фәкать тик бер «алтын котык», ягъни, шкатулка/тартма гына эләгә. Мондый аз бүләккә үпкәләгән Чура аны ташлап, сугышка бармас була. Соңыннан Сарыкани аның янына барып, әйтте: «Шул котыкны ачып карачы», – дип. Чура аны ачса, анда «Күк

чыбык» атлы бик яхшы кылыч күрә һәм кызны гафу итеп, гаскәр белән килгән яуларга каршы сугыша. Ә Шаһали хан аның атасына күп мал, хәзинә биреп, аны кире Кырымга кайтара, анда исә Нарәң батыр зур туй, мәҗлес үткәрә.

Шул вакытларда Чура батыр Колынчакка меӊ куй, ат биреп, Кырымга барып, ата-анасының хәлләрен белеп, үзенеӊ кыз карендәше Айсылуны да күрерсеӊ дип, аӊа Кырымга юл тотарга кирәклеген әйтә һәм тегесе шунда чыгып китә. Ул Кырымга барып Чура батырның өенә килсә, батырның анда калган хатыны бер егет белән кочаклашып ята икән. Күргәннәрен Колынчак Чурага кайтып сөйләгәч, моӊа түзә алмаган батыр Кырымга юнәлә һәм хатынын үтерергә уйлый. Әмма, каршысына чыккан карендәше Айсылу аӊа әйтә, ул егет түгел иде, ә мин идем, без аны бер хәйлә ясап сине Кырымга китерү өчен эшләдек, – ди. Чура моннан соӊ өендә бер кич кунып, хатыны мине үзеӊ белән ал дип әйтсә дә, аны калдырып, кире Казанга кайтып китә.

Чура батыр шәһәргә кайтып җитсә, бөтен халык каядыр качып бара. Чураның сорауына, аӊа аӊлаталар: «Казан шәһәрен яу алды, аның өчен качып барамыз», – дип. Шунда Чура мондый җырны башкара:

Мин Чурамын, Чурамын,
Түрә түгел, карамын,
Асылымны сорасаӊ –
Күкес углы Тамамән» [Татар халык иҗаты: 1984. 118 б.].

Аннан соӊ ул «Казанга килеп» дошманны җиӊә, ул турыда ишетеп, аның янына Шаһали хан һәм Сарыкани киләләр. Алга таба рус гаскәре тагы да яу белән ябырыла һәм ул юлы анда Чура батырның инде үсеп жткән улы да була, шуӊа күрә Казан гаскәре Мәскәү гаскәрен җиӊә алмый. Бу сугышны күзәткән Сарыкани Чураны үз янына чакырта, «сусагансың, килеп су эчеп кит», – дип әйтә ул. Чура аӊа җавап итеп, каһәрләнеп әйтә:

Шаһали ханның йорты өчен,
Сарыканиның күӊеле өчен
Күк чобарым арытмай,
«Күк чыбыгым» кара канга җебетмәй,
Бу гавернеӊ кереш күзле малаен
Иӊрә-иӊен ана Иделгә колатмай,
Бу гавер менә серен чыктырмай,
Ак мәсҗедләр салдырмай,
«Аллаһ»лап азан әйттермәй,
Морадыма җиткермәй
Кайтмам да, кайтмам да, – дип.

[Татар халык иҗаты: 1984. 119 б.].

Шушы сүзләрне әйткәннән соң, Чура батыр тагы гаскәр эченә чума, анда нык сугыша, ләкин үз улын үтерә алмый азаплана. Аның бу бик каты булган сугышта атының аягы кыза һәм ул туктый алмый, ат, хуҗасы белән бергә, Иделгә сикерә, шунда Чура батыр «суга китеп», үлә. Үлеп барган Чура җырлап әйтә [Татар халык иҗаты: 1984. 119 б.]:

Казан алды катлау-катлау кара су,
Камышлап төшеп идем сай да дип.
Тирән дә юк, сай да юк,
Индегедән арбаган [уңыш, бәхет] бездәй ирләргә
Казан атлы сар [шәһәр] да юк, – дигән сүзләрне һәм үлә.

Чураның үлеме турындагы эпизод буенча дастанның татарларда телдән язып алынган бер вариантында мондый өстәмә бар: аның атының аягын дошман ягында сугышкан улы яралый, нәкъ шуннан соң Чура Иделгә егылып төшә дә [Татар эпосы: 2004. 398 б.]. Кырым татарлары арасында язып алынган дастан версиясендә исә атасы белән улы берсен-берсе куышып барганда, икесе дә суга төшеп китеп үләләр [Къырымтатар: 1991. 72 б.]. Суга төшеп үләр алдыннан улын җиңә алмаган Чура батыр, эпосның бу версиясендә әйтә:

Алай да достлар, алай да,
Алдангъанман малайгъа.
Къатип отсин кълычым.
Озюмден тувгъан балайгъа, – дип [Къырымтатар: 1991. 72 б.].

Башка халыкларның милли версияләрендә дә Чураның үлеме турында шундый ук мәгълүмат бар. Мәсәлән, нугайларда язып алынган «Шора баьтир» дастанында әйтелә: «Соннан сонъ Казан уьстине яв келеди. Бу согыста Шора баьтир йигитлерше согысып Карагер аты ман Эдил сувына батып оьледи», – дип [Ногай: 1969. 79 б.]. Ә менә казахларда сакланган «Шора» дастанында аның үлеме башкача сурәтләнә – калмыклар белән каты сугыштан соң Шора белән булган Колынчакның көнчыгыштан килеп чыккан бер аждаһа (айдаһар) еланга корал белән кизәнүе аркасында Шора юкка чыга, аны убылып киткән җир йота. Чынлыкта, бу елан Шораның әрвахы булган икән, – дип белдерелә дастанда [Батырлар жыры: 1989. 368–369 бб.].

## Кем ул Чора (Шора)~Чура батыр?

Башка тарихи эпослардагы төсле үк, дастанның төп герое булган Чура батырның да реаль прототипы бар. Аның кемлеге мәсьәләсен Татарстанда иң элек без (карагыз: [Исхаков, 1994; 1997; 2002], аннан соң башка

галимнәр дә тикшерде [Урманче: 1995–1996; Ибраһимова, 2002; Қорғанбеков: 2014]. Нәтиҗәдә, хәзер тарихи Чураның кем булганлыгы шактый якшы өйрәнелгән. Ләкин ул өйрәнү берьяклырак барды һәм бара, чөнки бу «батырның» XVI-нчы йөз төрки-татар дәүләтләрендә тоткан урынын аның нинди кабилә-ырудан икәнлеген төгәл билгеләмичә аңлап булмый. Бу турыда исә тәшвишләп фәкать тик без генә яздык.

Әйтергә кирәк, дастанның төрле вариантларын анализлаганда Чура батырның кабилә-ыруын гына түгел, ә шактый озын шәҗәрәсен дә чамалап була. Шул мәгълүматлардан чыгып, аның Алтын Урданың сәяси варислары булган татар дәүләтләренең социаль-сәяси структураларындагы урынын да ачыклау мөмкин. Бу исә феодаль җәмгыятьләр өчен бик әһәмиятле, чөнки аларда кешенең тоткан урыны аның нинди социаль катламнан, нинди кабилә-ырудан, нәселдән булуы белән бәйле булган. Шуннан инде «Чура батыр» дастаны героеның тормышы күпкә якшырак аңлашыла башлый. Гомумән, ул яшәгән дәвердәге татарларның көнкүреше, уй-фикерләре яңача ачылып китә, без элегрәк аңлап җиткермәгән мәсьәләләргә башка җирлектән чыгып карау мөмкинлеге туа.

Эпик Чура батырны Казан ханлыгында XVI-нчы йөзнең беренче яртысында билгеле булган бер аксөяк татар – Чура Нарыков (рус чыганакларында фамилиясе шулай бирелә) белән тәңгәлләштерү соңгы вакытта әдәбиятта киң таралды [Урманче: 1995–1996; Исхаков: 1994; 1998; Ибраһимова: 2002; Қорғанбеков: 2014]. Ә бит әле күптән түгел генә Чура Нарыков турындагы мәгълүмат күбесенчә М.Г.Худяковның «Очерки истории Казанского ханства» (1923) исемле хезмәте кысаларында гына билгеле иде. Анда исә бу шәхес турында аның «талантлы дәүләт эшлеклесе» булуы гына билгеләнеп, Чура Нарыковның Казандагы 1545–1546-нчы еллардагы тәхет өчен көрәштә катнашуы белән чикләнде бу автор [Худяков: 1990. С.102–104, 110]. Ләкин мондагы информация нигезендә ул аксөякнең кем булганлыгын, ни өчен аңа аерым дастан багышланганлыгын аңлап булмый. Казан ханлыгы тарихы буенча соңрак вакытларда чыккан хезмәтләрдә дә ул турыда ачык кына язылмый [Алишев: 1990. С.53; 1995. С.81–847; Бахтин: 1998. С.92–93; История татар. Т.IV: 2014. С.320–321]. Фольклорчылар да үз хезмәтләрендә Чура Нарыков турында күбрәк шушы тарихчылар китергән шактый чикләнгән мәгълүматларны гына кулланып киләләр [Урманче: 1995–1996; Ибраһимова: 2002; Қорғанбеков: 2014]. Чынлыкта исә Чура Нарыков турында тарихи чыганакларда мәгълүмат шактый, ләкин ул информация систематик рәвештә өйрәнүне таләп итә. Аннан соң, «Чура батыр» дастаны эчендә дә бик әһәмиятле тарихи мәгълүмат бар, әмма аны эзләп табу һәм аңлату өчен татар ханлыклары турында концептуаль фикерләү дә, чагыштырма материаллар да

кирәк, алардан башка бу үзенчәлекле чыганактан әллә ни алып булмый. Дөресен әйткәндә, Чура батырның кемлеген аңлау өчен тарихи рус һәм шәркый чыганакларны барлап чыгып, алар нигезендә шушы шәхескә багышланган дастанда сакланган информацияне яңадан тикшерү кирәк. Шул очракта гына без дастанның төп героеның чын йөзен ачыклап, ни өчен аның аерым дастанга лаек булганлыгын төшенә алачакбыз.

Бөек Мәскәү кенәзлеге эчендә барлыкка килгән тарихи чыганаклардан башласак дөрес булыр, чөнки нәкъ менә алар эпик Чура батырның прототипы булган Чура Нарыковның Казан ханлыгында яшәү дәвере турында кайбер әһәмиятле мәгълүмат биреп, аның үлү елын, дәүләт сәясәтендә катнашуының төгәл даталарын билгеләп, бу шәхеснең тормышын конкрет хронологик кысаларга кертеп карау мөмкинлеген тудыралар.

Чура исеме рус чыганакларында беренче мәртәбә 1526-нчы елны күренә – шушы елның март аенда Мәскәүгә Казаннан өч кешелек илчелек килеп, анда «кенәз» дип күрсәтелгән ике шәхеснең берсенең исеме «Чура» дип атала [ПСРЛ. Т. 13: 1965. С. 45]. Бу вакыйга алдыннан Казан ханлыгында зур сәяси үзгәрешләр күзәтелә: 1519-нчы елның мартында Казанга 13 яшьлек Шаһали Касыймнан китерелеп (бу кандидатура Мәскәү белән килешенгән була) тәхеткә утыртыла. Ләкин ул Казан аксөякләренә тиз арада охшамый башлый һәм алар теләге буенча 1521-нче елны ханлыкның тәхетенә Кырымнан Гәрәйләр нәселеннән булган Сахиб-Гәрәйне күтәрәләр. Тәхеттәге үзгәрешләр вакытында Шаһали тарафдарлары һәм аның янында булган рус отряды бик нык зыян күрә, ә яшь хан 300 кешелек исән калган яраннары белән Мәскәүгә качып китә. Әмма, яңа хан да Казан тәхетендә озак утырмый – 1524-нче елның язында ул Кырымнан үзенең туганы Сафа-Гәрәйне чакыртып алып, Стамбулга китеп бара һәм аннан кире кайтмый (1532-нче елны ул аннан төрек солтаны карары белән Кырымга хан итеп җибәрелә).

Шулай итеп, әле бик яшь булган (13 яшендә) Сафа-Гәрәй Казан ханлыгында хөкем итә башлый, русларга исә аның монда калуы бер дә охшамый, алар 1524-нче елны ханлыкка каршы поход та ясап карыйлар, ул уңышсыз тәмамлана һәм Бөек Мәскәү кенәзлеге Сафа-Гәрәйнең ханлык итү хокукын таныйрга мәҗбүр була. Менә шул турыда сөйләшүләр алып бару өчен килгән илчелек составында «Чюра князь» була да [Худяков: 1990. С. 77–93]. Дөрес, исеменнән башка бу шәхес турында 1526-нчы елгы рус документлары башка мәгълүмат бирмиләр, шуңа күрә дә аның Чура Нарыков булуын бер гипотеза буларак кына расларга мөмкин. Әмма, Чура батырның дастаннарда сакланган Кырым белән бәйлелеген (алга таба карагыз) искә алганда һәм «Чюра кенәзнең» 1526-нчы елны Кырым династиясе вәкиле булган Сафа-Гәрәй исеменнән килгән илчелек

составында булуыннан чыгып караганда, ул безне кызыксындырган Чура Нарыков булган дип уйларга мөмкинбез. Моның шулай булганлыгын раслаучы бер факт 1540-нчы елга карый. Шул ел астында рус елъязмаларының берсендә Кострома тирәләренә Казан ханлыгыннан килгән яу турында сөйләнә һәм әйтелә: «...приходили казаньские люди, Чюра Нарыков, а с ним было [8000] человек казанцев и черемисы и чуваши, а воевали многие Костромские места» [Шмидт: 1951. С. 288]. Дөрес, бу очракта да без барыбер 1526–1540-нчы еллар арасында бу шәхес турындагы информациядән хәбәрдар түгелбез. Шулай булса да, шушы затлы татар алга таба да Казан ханлыгында яшәгән дип уйлыйбыз, ләкин озак вакыт ул рус чыганакларында бүтән искә алынмый тора. Икенче тапкыр югарыда китерелгән чыганакта, ягъни, 1512-нче елгы Хронографның дәвамында, Чура Нарыков 1545-нче елга караган рус җирләренә килгән яу турындагы язмада искә алына. Шушы елның кышында менә нәрсә була: «...приходили на Володимирские места с казанскими людьми в головах [Амона/Аманак] князь казанской да Чюра [Нарико]в... А у Гороховца, у острогу, с казанскими людми травилися мужики гороховцы, да взяли у казанских людей голову их Аманака князя» [Шмидт: 1951. С. 290].

Өченче тапкыр Чюра (Чура) – аның Нарыков фамилиясен дә күрсәтеп – «Патриарх (Никон) елъязмасында» 1546-нчы елны искә алына – Казаннан шул елның 17 гыйнварында тәхеттән төшерелгән Сафа-Гәрәй урынына үзләренә хан итеп яңадан Шаһалине сорап килгән илчелек составында була ул. Бу очракта аның титулы күрсәтелми [ПСРЛ. Т. 13: 1965. С. 148]. Әмма, 1546-нчы елның 13 июнендә тәхеткә утыртылган Шаһали Казанда озак ханлык итә алмый – бер айдан соң казанлылар Сафа-Гәрәйне яңадан тәхеткә кайтаралар, Шаһали исә аз гына үлемнән калып, Мәскәү ягына кача. Шушы элек Касыйм ханы булган Шаһалинең качу эпизодына аерым игътибар итү кирәк, чөнки ул турыда бер рус чыганагында өстәмә мәгълүмат бар. Аңа килгәнче әйтеп китик: 1546-нчы елны казанлылар исеменнән Мәскәүгә килгән өч илче (Абеюрган сәййед, Кадыш кенәз һәм Чюра Нарыков) исеменә һәм «бөтен Казан җиренә» Иван IV тарафыннан җавап хаты җибәрелүен искә алсак, Чура Нарыковның Казан ханлыгының югары аксөякләре арасында булганлыгы ачык.

Хәзер тарихи Чура Нарыковның ничек һәлак булганлыгына тукталабыз, чөнки безне кызыксындырган чыганакта ул мәсьәләгә карата өстәмә информация бар. Башлап, «Патриарх (Никон) елъязмасындагы» 1547-нче елның 20 сентяберендә Мәскәүгә хезмәт итәргә килгән татарлар (алар арасында «Чюра Нарыковның энеләре» булганлыгы да күренә) турындагы мәгълүматка килик. Алар хәбәр иткәнчә, «царь (ягъни, Сафа-Гәрәй – Д. И.) в Казани побил Чюру-князя Нарыкова (игътибар, монда аның «кенәз» ти-

тулы ачык күренә), Баубека-князя, Кадыша-князя и иных многих» [ПСРЛ. Т. 13: 1965. С. 149]. Димәк, Чура Нарыков Сафа-Гәрәй яңадан тәхеткә кайткач үтерелә. Сәбәбе билгеле – ул Сафа-Гәрәй урынына Шаһалине Казан тәхетенә китереп утыртуда катнаша. Ә менә «Казанская история [Казанский летописец]» дип аталган чыганакта (аны озак еллар Казанда яшәгән билгесез рус авторы язган) мондый юллар бар: Казанга хан булып килгән Шаһали белән Чура Нарыков нык якыная һәм ул ханның хәле авырайгач, аңа качарга ярдәм итә, хәтта качып китүчеләрне Идел буена кадәр озатып куя. Шул вакыт ул ханга әйтә: «Аз царю, вместо тебе умру в Казани, и моя буди глава во твоея место главы. Ты же мною да избавлен буди и не забуди мене, егда будеши преже меня на Москве, пред самодержцем станеши, вспоманя мя ему и о себе». Күренә ки, Чура үзе дә Мәскәү ягына китәргә уйлый, ахрысы, ләкин бераз курка, ул бит Иван IV каршында казанлылар исеменнән Шаһалине тәхеткә чакырып ант китергән булган. Шулай да, Чура Нарыков, «Казанская история» авторы күрсәткәнчә, Шаһалигә үзен билгеле бер урында көтеп торырга кирәклеген искәртә һәм ун көннән соң байлыгы, гаиләсе, өй эчендәге хезмәткәрләре, 500 сугышчы колы, барысы 1000 чамасы сугышчылары белән хан артыннан чыгып китә, әмма тегесе аны билгеләнгән җирдә көтеп тормый. Казанлылар исә алар артыннан куа чыгып, бер урында аның отряды белән бәрелешәләр, шул вакытта ул үзе, аның улы һәм бөтен «отрок»лары (сугышчы кабиләдәшләре булса кирәк) үтерелә, хатыннары һәм кол хатын-кызлары исә кире Казанга алып кителә [Казанская история: 1954. С. 80–82]. Әгәр дә Казан тәхетенә 1546-нчы елның 13 июнендә утыртылган Шаһалинең анда нәкъ бер ай утырганын истә тотсак, Чура Нарыковның үлеме шул елның июль урталарына туры килгәнлеге билгеле була.

Димәк, Чура (Чюра) Нарыков («Нарыкович») затлы аксөяк татар, кенәз (би, бәк) статуслы тарихи шәхес, рус чыганаклары буенча Казан ханлыгында 1526–1546-нчы еллар арасында яшәп, ул андагы сәяси тормышта актив катнашкан кеше булган. Аның социаль статусы турында «Казанская история» тагы мондый мәгълүмат бирә – ул анда «большой князь», «волостель казанский», «храбрый воевода» дип тә атала (карагыз: [Казанская история: 1954. С. 80, 82]). Бу төшенчәләр барысы да әһәмиятле, алга таба ул турыда аерым тикшерү үткәрербез.

Хәзер инде төрки чыганакларга мөрәҗәгать итү кирәк булыр. Аларның иң әһәмиятлесе – «Чура батыр» дастаны, әмма Чура Нарыков турында башка төр чыганаклар да бар. Шуларның берсе – шәҗәрәләр. Алдан аларга мөрәҗәгать итәрбез, чөнки шәҗәрәләр аркылы Чура батырның нинди аксөяк нәсел белән бәйләнгән булуын чамаларга була.

Чура батырның шәҗәрәләре Идел-Урал буенда сакланган. Алардан башка бу шәхеснең нәселе турындагы мәгълүматны тагы ике төркем шәҗәрәләр аркылы алып була: беренчесе – Кырым ханлыгындагы аргын кабиләсе бәйләренең шәҗәрәсе, икенчесе – нугайлардан язып алынган Чурага (Шорага) багышланган дастан эчендәге аның нәселенә караган берничә буынлы шәҗәрә. Чура (Шора) батырның нәселе турында кызыклы мәгълүмат казахларда аңа һәм аның атасына багышланган эпик әсәрләр эчендә дә бар. Алар катлаулы структуралы һәм әлегә кадәр тулаем өйрәнелеп бетмәгән. Шулай да, ул әсәрләрдәге информацияне дә алга таба игътибарга алырга кирәк булачак.

Татарларда язып алынган Чура би шәҗәрәсенең берничә версиясе бар, әмма ахыр чиктә алар бер нигездә һәм бер үк төбәктә барлыкка килгәнгә охшый. Сүз Татарстандагы Зур Карауҗа, Кече Карауҗа һәм Кармыш авыллары (Яшел Үзән районы) турында бара (карагыз: [Әхмәтҗанов. I том: 2011. 33–34 бб.]). Шул авылларда язып алынган җирле тарих турындагы легендалар эчендә мондый информация бар: «...Карауҗаның атасы Кара би булган. [Ул] Казан ягында Каравай авылында ил тотып яшәгән. Аның улы Карауҗа, Кече Карауҗа урынына килеп, авыл корып утырган... Карауҗа ... өч улын чакырып ... [укларыгыз] кая төшсә, шунда барып нигез корырсыз! – дигән. ... Укларның берсе Каратмән авылы урынына килеп төшкән. Ул урынга Карауҗаның олы улы нигез корган. Аның исеме Кара Төмән икән. Икенче улының исеме Чура би... Аның угы хәзерге Зур Карауҗа авылындагы Чура би чокыры турысына килеп төшкән. Карауҗа Чура би исемле улы белән шул урынга нигез салган. Өченче улының угы Күлбәш авылы урынында бер күл башына төшкән, ул шул җиргә урнашкан. Карауҗа, Иван Грозныйга каршы сугышта, Казан ханына хыянәт итә... Аның кабере Чура би чокыры дигән урында. Чура бинең улы Чура батыр була. Иван Грозный гаскәрләре Казанны алган вакытларда Чура батыр ... Карауҗа авылы җирләре өчен сугышып үлә» [Татар халык иҗаты: 1987. 160 б.].

Шушы ук легенданың тагы бер версиясендә Карауҗаның олы улының угы Җәке авылы урынына төшеп кадала, диелә. Анда да беренче чыганактагы төсле Чура батырның улы Ресмәт, аның улы Кадермәт, соңгысының улы Гыйззәтулла дип бирелә [Әхмәтҗанов. Том I: 2011. 109–110 бб.]. Әлегә бу легендар тарихның нечкәлекләренә кермичә, андагы шәҗәрәгә игътибар итик: Караби →Карауҗа → 1) ......

2) .....

3) Чура би → Чура батыр →Ресмәт → Кадермәт → Гыйззатулла һ.б. Бу шәҗәрәдәге Ресмәт (Рыстмөхәммәттән) башланган башка бер тулырак шәҗәрә дә бар һәм ул шул ук төбәк

белән (Мәмдәл, Иябаш, Яңа Кенәр авыллары) бәйле [Әхмәтҗанов: 1995. 91–97 бб.]. М.И. Әхмәтҗанов, бу шәҗәрәләрне тикшергәндә, аларның тагы бер версиясенең Р. Фәхретдиннең «Асар» китабында булганлыгын да күрсәтә (Эстәрлетамак шәһәрендә 1858-нче елда вафат булган шәхестән калган ул версия). Менә бу шәҗәрәнең өске өлеше: Караужа би → Кармыш би → Карлыгач би → Мәрҗән бабай → Рысай бабай һ. б. [Әхмәтҗанов. Том I: 2011. 111 б.]. Ахрысы, бу шәҗәрә югарыда әйтелгән, әмма исемнәре аталмаган Караужаның ике өлкәнрәк улларының берсенеке һәм аның исеме Кармыш би булган булырга тиеш. Татарстанның көнчыгышында яшәгән (Ык тамагындагы Бикбау авылы белән бәйле булган алар), ләкин соңыннан хәзерге Башкортостанның төрле урыннарында яшәгән татарлар белән бәйле бу шәҗәрә түбәндәгечә: Күкәс → Нәрек → Чура → Уразбакты → Үзи → Кайбиш һ. б. [Әхмәтҗанов: 2002. 323–324 бб.].

Шулай итеп, Идел-Урал буе татарларында сакланган Чура батыр дастанының төп герое булган Чура Нарыковның һәм аның белән бәйле башка шәхесләрнең берничә версияле шәҗәрәсе барлыкка килә безнең алда. Аның төп тамыры уртак булса да, аларда аермалыклар да бар (түбәндә карагыз):

I Кара би → Караужа → Чура би → Чура батыр ...

II Күкәс → Нәрек → Чура → Уразбакты ...

III ... → Караужа → Кармыш би → Карлыгач би ...

Күрсәтелгән шәҗәрәләрдәге мәгълүматларның асылына төшенү өчен безгә Чура батырның башка төбәкләрдә һәм бүтән милли версиләрдә сакланган шәҗәрәләрен дә карап үтү кирәк булыр.

Башта Кырым татарларыннан язып алынган «Чорабатыр» дастаны эчендәге бер шәҗәрәгә игътибар итик. Менә ул: «...Чоранынъ бабасы Нарик, Нарикнинъ агъасы Арик...» [Къырымтаатр: 1991. 57 б.]. Ул дастаннан күренгәнчә, кайбер очракларда Нарикка да «Чора» дип эндәшкәннәр [Шунда ук, 58 б.]. Бу исә татар ханлыкларында «чура» дигән төшенчәнең «кол»дан башка тагы бер мәгънәсе дә булганлыгы белән бәйле – аның икенче мәгънәсе «югары дәрәҗәле йомышлы хезмәтче, хан вассалы» [Валиханов. Т. I: 1984. 284–285 бб.; Усманов: 1972. С. 94]. Шулай ук дастанны укыган вакытта Чораның (Чураның) шушы Нарикның улы икәнлеге бик ачык күренә [Къырымтатар: 1991. 61, 66–67 бб.]. Чора дастанда үзе дә әйтә:

Атамнынъ адыны сорасанъ,
Нарик огълу Чораман, – дип [Шунда ук: 69 б.].

Димәк, безгә кырым татарлары арасында язып алынган дастаннан Чора батырның Нарик улы икәнлеге билгеле була, ә Нарикның Арик атлы агасы булганлыгы ачыла. Бу мәгълүмат Кырым ханлыгында яшәгән бер

төркем аксөякләрнең шәҗәрәләренә игътибарны юнәлтергә кирәклеген күрсәтә. Сүз Кырым ханлыгындагы дүрт карача бәкләр нәселенең берсе булган аргын кабиләсе бәкләрнең шәҗәрәсе турында бара [Лашков: 1895. С. 129].

Менә ул шәҗәрә: Кара Коджа бәк → Адил бәк ...
→ Али-Шукур бәк →
→Аджи-Ямгурчы бәк (1551) →
Джан-Мәмбәт бәк ...
→ Кара бәй (1585) → Тоган мирза
→ Батырша бәк (1682).

Монда турыдан-туры дастандагы Чора б. Нәрик белән бәйлелек күренмәсә дә, Идел-Урал буенда язып алынган Чура батыр шәҗәрәләрендә булган информация нигезендә Кырымдагы аргыннарның нәсел башы итеп күрсәтелгән «Кара Коджа» бәкнең Чура батыр шәҗәрәсендәге Караужа би белән бер үк шәхес икәнлеген чамаларга була.

Өйрәнелә торган мәсьәләне нугайлар һәм казахлар арасында язып алынган дастаннар нигезендә тагы да тикшерсәк, бу нәтиҗә ныграк нигезләнгән булачак.

Әйтик, нугайларның «Шора бағытир» дастаныныда аның герое үзенең кем икәнлеге турындагы сорауга мондый җавап бирә (җавапның икенче өлешен китерәбез, кабилә-ыруга нисбәтле алдагы өлешен соңрак тикшербез):

Аргы атамды сорасанъ
Астын улы Бай-газы,
Онынъ улы эр Тоьлек,
Нарик улы Шораман, – дип белдерә Шора [Ногай халк: 1969. 77 б.].

Беренчедән, монда Чураның (Шораның) Нарик улы икәнлеге раслана, икенчедән, аның шәҗәрәсе шактый озыная һәм XV-нче гасыр башларына барып җитә: Шора ← Нарик ← эр Тоьлек ← Байгазы ← Астын. Дөрес, Нарикның Төлек улы булуын мантыйк нигезендә генә торгызып була, шигъри юлларда ул туп-туры күрсәтелми. Әмма, моның шулай булуын Добруджа (Буджак) татарлары арасында сакланган Чура батыр турындагы дастаннан ачык күреп була. Анда әйтелә:

Арыслан улы Байгазы,
Аның улы Ир-Түләк,
Аның улы Ир-Нарык
Чура улы Чурамын, – дип [Чура Батыр: 1993. 39, 54–55 бб.].

Күренә ки, монда «чура» атамасы Ир-Нарыкка карата кулланыла, ләкин Чураның аның угылы икәнлеге дә күп тапкыр раслана [Шунда ук, 22, 27, 33, 38, 39, 43, 53 бб.].

Алга таба казахларда язып алынган дастан версияләре эчендә булган шәҗәрә вариантларын да карап китик. Әйтик, «Шора» дастанында, Нәрік Шорага Акташның бие өстенә яу белән барырга тәкъдим иткәндә, атасы Нәріккә әйтә: «Ата сіз», – дип [Батырлар жыры. Т. 5: 1989. 386 б.]. Шул ук эпизодта, атасы улына булай ди:

Айналайын, Шоражан,
Туѓан балам сен болсаң,
Алпыс биді өлтеріп
Кесіп басын алып кел [Батырлар жыры. Т. 5: 1989 . 339 б.].

Һичшиксез, бу сүзләрдән һәм эпосның башка җирләреннән [Шунда ук, 340–341, 342, 350–351 бб.] Чураның (Шораның) Нәрик (Нарык) угылы икәнлеге күренә, бигрәк тә дастандагы мондый юллардан:

..............................
Сонда Шора сөйледі
Менің елім сурасаң,
Ноѓайлы деген ел деді,
Әкем атын сұрасаң,
Нәрік деген хан деді.
Өз атымды сұрасаң,
Шора батыр мен деді [Шунда ук, 348 б.].

Ләкин, казах дастаннарындагы Чура (Шора) батырның шәҗәрәсенә бәйле мәгълүмат чынлыкта катлаулырак. Шуңа күрә ул информациянең башка якларын да барламыйча булмый. Беренче чиратта бу мәгълүмат аның кабилә-ыру бүленешенә кагылышлы өлешенә карый. Ул турыда «Нәрік» дастанындагы Шораның «Син кем», – дигән сорауга җавап итеп әйтелгән мондый юллар сөйли:

Асылымды сұрасаң,
Асылым артык арѓынмын.
Тегімді менің сұрасаң,
Кок Нарлы танамын,
Өз атымды сұрасаң,
Нәрікулы Шорамын [Батырлар жыры. Т. 5: 1989. 328 б.].

«Шора» дастанында исә аның герое үзе турында әйтә:

– Менің елім сұрасаң,

Ноѓайлы деген ел деді.
Әкем атын сұрасаң,
Нәрік деген хан деді.
Өз атымды сұрасаң,
Шора батыр мен деді [Шунда ук, 348 б.].

Ләкин, Шора калмыклар башында торган Мусахан белән очрашканда, тегесе аннан «Кай ногайсың син», – дип сорагач, аңа мондый җавап бирә:

– Ногайлының ішінде
Асылым артыі арѓынмын.
Бергі атамды сұрасаң,
Көк нарлы танамын,
Атам аты қарт Нәрік,
Мен сонда туған Шорамын, – дип [Шунда ук: 366 б.].

Димәк, казахлар арасында таралган Чура (Шора) батырга багышланган дастаннар циклында (алар өчәү) аның кабилә-ыру бүленешенә мөнәсәбәте дә чагыла. Ләкин бу мәсьәлә буенча казахлардагы һәм башка төркиләрдәге эпос вариантларында чагылган мәгълүматта каршылыклар бар.

Беренчедән, казахларда таралган «Тана» дастанында (анда Нәрікнең бабалары турында сөйләнә) шул исемдәге хан дәрәҗәсендәге шәхеснең «ногайлы баласы» буларак Казанда яшәгәнлеге, аны саклауда катнашканлыгы турында сөйләнә дә, аның Баба Тукті Шашты Әзиз (ягъни, Әхмәт Ясәви) ярдәме белән баласы туып, ул балага «хан Нәрік» аты кушылу турында әйтелә [Шунда ук: 294–297 бб.]. Чынлап та, Тама кабиләсенең (тана~тама булса кирәк) шәҗәрәсендә Нәрыкның атасы Кара-бура, аның атасы Тама дип бирелә [Тынышпаев: 1925. С. 75]. Ә Чора Нарыков, М. Тынышпаев күрсәткәнчә, «күп тама кабиләдәшләренең бабасы» булып саналган [Шунда ук: 47 б.]. Мондый караш Казахстан гуманитар фәнендә элек тә бар иде [Валиханов. Т. 1: 1984. С. 109], хәзер дә яшәп килә (карагыз [Корғанбеков: 2014. 179–180, 214 бб.]). Казахстан фольклорчылары йогынтысы аркылы бу фикер татар фольклорчылары эшләренә дә үтеп керде [Урманче: 1995. 133–134 бб.]. Чынлыкта, эш монда казахлар арасында таралган Чора (Шора) батырга кагылышлы дастаннардагы аның «тамалы» булуы турындагы мәгълүматта гына түгел, чөнки шуңа якын информация бу дастанның башка милли версияләрендә дә бар. Әйтик, нугайларның «Шора бaьтир» эпосында аның төп герое үзен «асылы» буенча «ай тамгалы Тамаман», дип атый [Ногай халк: 1969. 76 б.]. Шул ук аңлатма Добруджа (Буджак) татарларыннан язып алынган «Чора батыр» дастанында да бар:

Köyimniñ adin soracañ
Kökişli Tama derler oğa [Bozcigit kitabindan: 1988].

Ул юлларны хәзерге татар әдәби телендә мондый рәвештә биргәннәр:

Каламның исемен сорасаң,
Күкешле Тамга, диерләр [Чура Батыр: 1993. 53 б.].

Чынлыкта «көй» – авыл, торак пункты (шул исәптән, шәһәр/кала да була ала) дигән сүз. Бу очракта, димәк, казахларда һәм нугайларда ыру/кабилә исеме булып йөргән «тама» төшенчәсе торак пункты мәгънәсендә бирелгән. Мондый мәгънә кырым татарларының «Чора Батыр» дастанында да бар. Мәсәлән, В.В. Радлов язып алган шушы дастанның бер версиясендә Чора батырның атасы Нарик карт турында ул «Кокешлу Тама[да] мäкан тикти, отурду», – диелә [Образцы. Ч. VII: 1896. С. 124; тагы карагыз: [Къырымтатар: 1991. 69 б.]. Чора батырның үзе турында да дастанның бу һәм башка версияләрендә аның «Кукушле Тама» яисә «Кокушле Кок Тама» дигән урында яшәгәнлеге турында сөйләнә [Образцы. Ч. VII: 1896. С. 127–129, 170; Къырымтатар: 1991. 61–62, 66 69 бб.]. Кырым татарлары вариантларының берсеннән күренгәнчә, сүз аларда да торак пункт – «көй» турында бара [Образцы. Ч. VII: 1896. С. 182].

Идел-Урал буе татарлары арасында таралган «Чура батыр» эпосында да Чураның мин «Кукес углы Тамамән», – дигән сүзләре бар [Татар халык иҗаты: 1984. 118 б.]. Бу фраза Чура батырның дусты саналган Колынчак батырга багышланган бер «хикәят»тә дә китерелә [Татар эпосы: 2004. 396 б.]. Күренә ки, бу очракта Чура батырның Күкес угълы булып, Тама ыруына караганлыгы күз алдында тотыла булса кирәк. Чынлыкта, башкортларның тамьян-катай ыруы шәҗәрәсе дә шундый нәтиҗә бирә: анда «Нурек исемле морзаның Җагалбай нәселеннән, казакъ булганлыгы», аның «Бохара тамагыннан Уил елгасы буена күчкәнлеге», турында әйтелә [Хусаинов: 1985. С. 15–16] һәм Нурекнең угълы Сура (Чура) икәнлеге күрсәтелә дә алар шушы тамьян-катай ыруы белән бәйләнелә. Монда без «тамьян» терминына игътибар итәргә тиешбез, чөнки ул атама Чура батырның татарлар арасында язып алынган югарыда китерелгән шәҗәрәсендә дә чагыла – Карауҗаның олы улы булып исәпләнгән Кара Төмән исеме (авыл атамасында – «Каратмән») төмән/тäмäн/тамьян атамалары белән бәйле дип уйларга урын бар һәм алга таба без бу фикерне аерым рәвештә нигезләрбез.

Шулай итеп, сорау туа: Чора батыр – Чура Нарыков, тама/тана/төмән (тамьян) ыруыннан булганмы яисә аның кабилә-ыруы башкача аталганмы? Бу сорау урынлы, чөнки Чура батырга багышланган дастаннарда без аның башка бер кабилә белән бәйләнгән булганлыгын да күрәбез. Ул турыда кайбер мәгълүматлар инде китерелде, аларга хәзер ныграк тукта-

лырга тиешбез. Анализ ясау өчен безгә түбәндәге дастаннардан алынган юлларга мөрәҗәгать итәргә кирәк:

***I Нугай варианты:***

а) Мен аргынмын аргын ман,
Ак сункардай кыргый ман,
Асылымны сорасаң,
Ай тамгалы Тамаман [Ногай халк: 1969. 76 б.].
б) Тоьре тувыл караман,
Анадан эгиз тувмай дараман,
Асылымды сорасань,
Ноькис улы Тамаман [Ногай халк: 1969. 74 б.].

***II Добруджа татарлары варианты:***

а) Мен arğinman, yorginman
………………………………
б) Asilimni sorasañ
Qirimdaki Kökişli Tama’nin
Köyinden kvilgăn uliman.
в) Tőre tuvil, qaraman
Eqiz tuvil, daraman
Kőyimiñ adin soracañ
Kőkişli Tama derler oğa,
Ondan кelip baraman [Bozcĭgĭt kitabindan: 1988].

***III Кырым татарлары варианты:***

а) Тёре дигиль, къараман,
Коюмнинъ адыны сорасанъ,
Кокушли кок Тамалыман [Къырымтатар: 1991. 69 б.].
б) Ман торо тугул, караман,
Äкäу тугул, дараман,
Койумнун адын сурасан,
Кокушлу кой Тама [Образцы. Ч. VII: 1896. С. 182].

***IV Идел-Урал буе татарлары варианты:***

а) Мән Чурамын, Чурамын,
Түрә түгел карамын,
Асылымны сорасаң –
Кукес углы Тамамән [Татар халык иҗаты: 1984. 118 б.; Татар эпосы: 2004. 396 б.].

***V Казахлар варианты:***

а) «...в древние времена в г. Казань, обитали в нем народы, носившие название «Тама». В числе их три брата … Старшего звали Кариббаем, среднего Нарикбаем, младшего Исым-бием… Скот [Нарика] … пасли 40

юртовладельцев, таминцев. [Они] кочевали с ним, были его верными слугами…» [Сборник. Т. IV: 1895. С. 2].

б) Асылымды сұрасаң,
Асылым артык арғынмын.
Тегімді менің сұрасаң,
Көк нарлы танамын [Батырлар жыры: 1989. 328 б.].
в) Ногайлының ішінде
Асылым артық арғынмын.
Бергі атамды сұрасаң,
Көк нарлы Танамын [Батырлар жыры: 1989. 366 б.].

Югарыда китерелгән мәгълүматлардан Чура батырның ике төрле «асылга» ия булганлыгы килеп чыга: бер яктан ул – аргын, икенче яктан – тана/тама (ай тамгалы, Көкеш (Ноькис) улы, Көкешле, Көк нарлы). Әгәр дә мантыйк нигезендә уйлап карасак, шәхес бер үк вакытта ике кабилә яисә ыру вәкиле була алмый. Шуңа күрә дә безнең элегрәк чыккан популяр язмабызда бу каршылыкны чишү өчен тама ыруын аргын кабиләсенең бер кисәге дип карарга тәкъдим ителгән иде [Исхаков: 1994; 1998]. Ләкин, хәзер без бу мәсьәләне башкача аңлатырга кирәк дип уйлыйбыз һәм бу яңа чишелеш казахлар арасында таралган «Нәрік» дастанындагы бер билгеләмә аркылы табыла ала.

Әйтеп үтелгәнчә, казахлар арасында Чура батырның үзенә генә түгел, ә аның атасына багышланган «Нәрік» исемле дастан да бар. Ул эпостагы бер эпизодта Нәрик белән аның хатыны Меңди аруның илләреннән качып киткәч калмыклар башлыгы Өгезханга барулары тасвирлана һәм Өгезханның Нәрикне башка җиргә җибәреп, аның хатынына кул сузуы сурәтләнә. Шул вакытта хезмәтчеләре белән бергә Меңди аруның каршысына килеп баскан «Төрехан», ягъни, Өгезхан исеменнән аның бер хезмәтчесе тарафыннан Меңди аруга ясалган шушы ханга сөяркә булу турындагы тәкъдименә каршы Нәрикнең хатыны мондый сүзләр әйтә:

– Арғы атамды сұрасаң,
Карадөң сынды карт еді
........................................
Онан туған Жұбаныш
........................................
Онан туған Сүйініші
........................................
Онан туған Бегіс деп,
....................................
Бегістен туған Тама еді

..................................
Таманың улы Тана еді,
Оның улы карт Нәрік... [Батырлар жыры: 1989. 320 б.].

Кызыклы шәҗәрә килеп чыга: Нәрік ←Тана ← Тама ← Бегіс ← Суйініші ← Жубаныш ← Карадөң. Ә бит чынлыктагы бу шәҗәрәдә сүз Чура батырның атасы турында түгел, ә аның анасы ягы турында бара, ул бит үз нәселе, үз ыруы турында сөйли! Бу шәҗәрәнең тагы бер варианты казахларның «Тана» исемле дастанында да бар. Анда «ак төре» һәм «хан» булган, «Астана халкының» башында торган Тана (аның баласы буларак Нәрік күрсәтелә) үзенең «аргы атасы» дип Карадөңне күрсәтә, аннан соң Жубаныш һәм Суйініші исемнәре атала [Батырлар жыры: 1989. 289, 291, 297, 300, 302 бб.]. Күренә ки, бу шул ук шәҗәрә һәм анда Нәрикнең исеме барлыкка килсә дә, әйтелгән нәсел җебенең аның хатыны ягыныкы икәнлеге ачык.

Гомумән алганда, тана (тама) кабиләсе (ыруы) ике (аргын-тама) бер-берсе белән туганлык мөнәсәбәтендә торган фратриаль бүленештәге берләшмәнең «хатын» ягы кабиләсе булып чыга һәм дөрестән дә ул якка – ана ягына, Чура (Шора) батырның мөнәсәбәте булмыйча булдыра алмый. Әмма, ирләр дөньясы беренче урында торган күчмә төркиләрдә – ә Нәрикнең үзен һәм аның улы Чураны дастаннар «токсан баулы ногай» (монда инде безгә билгеле булган Алтын Урда татарларының 90 кабилә-ыруга бүленеше күз алдында тотыла) белән бәйлиләр [Батырлар жыры: 1989. 321 б.] – әни ягының кабилә билгесенең беренче урынга чыгуы үзенчәлекле күренеш һәм ул аерым аңлатуны таләп итә. Беренче башка килгән фикер, билгеле, Чура батырның трагик үлеменнән соң аның нәселеннән булган исән калучыларның Казан ханлыгы җирләреннән ана ягы булган кабилә җирләүләренә китеп, шунда «сеңүләре» нәтиҗәсе буларак тама (тана) кабиләсенең дастаннарда өскә чыгуы. Ләкин бу аңлатма кайбер каршылыкка китерә. Әйтик, Казан арты татарларыннан язып алынган тарихи легендада сакланган «Чура батыр» дастанындагы Чураның «асылын» Күкес угълы Тамадан чыгару нәрсә турында сөйли? Кырым һәм Добруджа татарларындагы тикшерелә торган дастан версияләрендә «Көкешле кок (кой) Тама» атамасының торак пункты булып йөрүен истә тотсак та ул исемнең нәрсә аңлатуы турындагы проблема кала. Безнең бу турыда бер гипотезабыз бар, әмма аның эчтәлегенә кереп киткәнче аргын кабиләсенә бәйләнгән кайбер генеалогик һәм тарихи мәгълүматка тукталып китү кирәк.

Алда әйтелгәнчә, Казан янындагы авыллардан язып алынган тарихи легендаларда Кара бинең улы Карауҗа искә алына. Кырым татарларында исә Кара Коджа бәк аргыннарның бабасы саналган. Бу уңайдан игъ-

тибар итик: казахларның Урта Урдасы (Йөзе) составына кергән аргын кабиләсенең ике ораны булып (*Акжол* һәм *Кара Ходжа*) [Тынышпаев: 1925. С. 29], аның икенчесендә Кара Хуҗа исеме чагыла. Искә төшерик, бу исем «Идегәй» дастанында да бар – анда «Аргыннарның башы идең, Кара Кужа батырым», – дигән Туктамыш хан тарафыннан әйтелгән сүзләр китерелә [Идегәй: 1988. 47 б.]. Эпоста ул башка урыннарда да «Аргылның углы Кара Кужа» [Шунда ук, 205 б.], «Кара Кужа Аргын би» [Шунда ук: 141 б.] буларак инде безгә таныш булган Туктамыш ханның «тугыз батыры/бие» исемлегендә күренә. Чынлыкта Кара Кужа/Хуҗа – тарихи шәхес. Шәрәф әд-дин Йездинең «Зафәр-наме» (1424/1425 елны төгәлләнгән) әсәреннән күренгәнчә – ә ул автор Тимурид Шахрухка һәм аның улы Ибраһим солтанга хезмәт иткән – Тимур янына ул үләсе елны «берникадәр вакыт начар хәлдә далаларда йөргән» Туктамыш хан исеменнән аның «борыңгыдан килгән нукерларыннан» булган Кара-ходжа илче буларак килә һәм ханы исеменнән гафу үтенә, нәтиҗәдә аны Тимур «Жучи Олысын» алга таба Туктамышка кайтарып бирүне вәгъдә итеп Отрар шәһәреннән походка киткәндә бүләкләр белән кире кайтарып җибәрә [История Казахстана в персидских источниках. Т. IV: 2006. С. 350–351]. Бу вакыйга Тимурның 1405-нче елның 18 февралендә үлүе алдыннан була. Шулай итеп, аргын кабиләсенең бие Кара-хуҗа (Караҗау/Кара Коджа) 1405-нче елны ханы янына китеп бара һәм соңыннан берьюлы ике ханлыкта – Кырым һәм Казан ханлыкларында, аргыннарның нәсел башы булып санала башлый, ә казах далаларында ул заманалар үтү белән аргын кабиләсенә һәм кайбер башка (тама/тана, каратамыр) ыруларга нисбәтле буларак искә алына. Бу мәгълүмат нәрсә турында сөйли соң?

Моны аңлау өчен Алтын Урда таркалу алдыннан булган вакыйгаларга кыскача күзәтү кирәк.

Инде алда әйтелгәнчә, таралып бетә язган дәүләтне кире «җыеп» алган Туктамыш хан (1377/78–1406) Алтын Урданың үзәк өлешенә аның сул канаты җирләреннән килеп керә (бабаларының биләмәләре – Мангышлак якларында булганлыгы билгеле) һәм үзе белән борыңгыдан бу нәселгә буйсынган дүрт кабиләне (шырын, барын, аргын һәм кыпчак) дә алып килә. Аларның берсенең – шырын кабиләсенең – шул дәвердә Кырымда урнашуы (аның элекке хөкемдары кыйат кабиләсе бәге темник Мамайның биләмәсен алып) төгәл билгеле [Исхаков, Измайлов: 2007. С. 154–155]. Бәлки, башка Туктамыш ханга бәйле кабиләләр дә шул тирәләрдә яшәгәннәрдер. Һәрхәлдә, 1399-нчы елдан соң бүтән Алтын Урда тәхетенә якын килә алмаган (ул тәхетне алдагы елларда Идегәй тәхеткә утырткан ханнар билиләр) Туктамыш хан янында, әле 1405-нче

елны да, бу хан качып йөргән вакытларда, «искедән калган нукерларыннан» саналган аргын кабиләсенең бие Кара-Хуҗа булуы күп нәрсә турында сөйли – ахрысы, искә алынган 4 кабилә хан тирәсендә калуларын дәвам иткәннәр. Соңрак чорга караган тарихи материаллар күрсәткәнчә, Туктамыш ханның уллары һәм туганнары тирәсендә (хан үзе 1406-нчы елны Шадибәк хан һәм Идегәй тарафыннан Себердә, Төмән/Чимги-Тура тирәләрендә үтерелә [Миргалеев: 2003. С. 148]) бу кабиләләрнең барысы да диярлек искә алына. Димәк, алар чыннан да бу хан нәселе янында калганнар.

Билгеле булганча, инде картайган (аңа үләр алдыннан 55–60 яшьләр чамасы була) һәм авыр хәлгә калган Туктамыш хан һәлак булганнан соң аның уллары (билгелеләре бишәү) төрле якларга таралалар, ләкин Алтын Урда тәхете өчен көрәшләрен туктатмыйлар. Бу канкойгыч сугышларда – каршы якны озак вакыт сул канатның башында торган Идегәй җитәкли – Туктамыш ханның уллары берсе артыннан берсе тәхеткә күтәрелеп, юкка чыгалар. Идегәй дә 1419/1420-нчы елны бер җиңелүдән соң Туктамышның кече улы Кадыйрбирде хан боерыгы буенча, инде әйтелгәнчә, баарын (барын) кабиләсе бәге Сарай тарафыннан үтерелә (бу заман турында тулырак карагыз: [Миргалеев: 2003; Гулевич: 2018]). Ләкин сәяси вакыйгалар агымы тукталмый һәм аларда Туктамыш хан нәселе вәкилләре катнашуларын дәвам итәләр. Безгә аларны бераз барлау кирәк, чөнки Чура батырның бабаларының тарихын шуннан башка бөтен тирәнлеге белән аңлап булмый.

1418-нче елны Алтын Урда җирләрендә төрле татар төркемнәре арасында үзара көрәш кызган вакытта, Туктамыш ханның кече улы Кадыйрбирде (аны 1407/1408-нче елны ук Идегәйдә кияүдә булган Җаникә исемле апасы Кырымга озата) Кырым белән бәйле бәкләр тарафыннан тәхеткә күтәрелә һәм ул Идегәйгә каршы яу белән китә. Аның гаскәрләрендә төп рольне уйнаучылар ширын кабиләсенең бәге Тегинә һәм конграт кабиләсенең бәге Айдар (Хәйдәр) булганнар. Идегәй бу төркем белән (алар кулында ким дигәндә 100 мең кешелек гаскәр булган) килешергә тырышып караса да, ахыр чиктә 1419-нчы елны җиңелә һәм, инде сөйләнгәнчә, үтерелә. Төрле мәгълүматлар буенча, аны үтерүгә барын кабиләсен җитәкләгән Сарай бәктән башка ширын кабиләсе бәге Тегинә һәм тиздән хан буласы Олуг-Мөхәммәтнең атасы Ичкиле Хәсән углан да катнашкан (тулырак итеп карый аласыз: [Гулевич: 2018. С. 129–145]). Элегерәк тасвирланганча, нәкъ шушы бәрелеш вакытында каты яраланган Кадыйрбирде хан да үлә һәм аның урынына ширын бәге Тегинә һәм конграт кабиләсе бәге Айдар тырышлыгы белән Туктамыш хан нәселеннән булган Олуг-Мөхәммәт утыртыла. Бу дәвердә ул җитәкләгән га-

скәрләр составында барын кабиләсе һәм кыпчак кабиләсе дә, һичшиксез, булганнар. Аргын кабиләсе турыдан-туры искә алынмаса да, ул да Олуг-Мөхәммәт тирәсендә булган дип уйларга урын бар (алга таба бу фикер тулырак итеп нигезләнер).

Чура батырның бабасы Кара-Хуҗаның 1405-нче елдан соңгы язмышын күзаллау өчен Олуг-Мөхәммәтнең ханлыгы дәверенә бераз тукталып китү кирәк, чөнки ул Болгар/Казан виләйәте җирләренә килеп урнашканчы шактый катлаулы сәяси юл үтә.

Иң башлап, шуны әйтергә кирәк: 1419-нчы елны Олуг-Мөхәммәт ханлыкка күтәрелгәндә ул Олуг Урда ханы (генуэзлылар аны «Урда императоры», «бөек император»/«imperatoris de Lordo» дип атаганнар) буларак, ягъни, Сарай ханы дәрәҗәсендә, тәхеткә утыртыла. Шул ук вакытта аның кайбер якын туганнары Кырым biләмәсендә (=олысында, төмәнендә) утыралар һәм алар да «император», «Солхат императоры» (хан яки солтан) титулына ия булалар [Гулевич: 2018. С. 149–162]. Олуг-Мөхәммәт шушы шартларга – истә тотыйк, Алтын Урда таралып килгән заман бу – риза булса да, 1423-нче елның язында Олуг Урданың зур өлеше көндәше Мөхәммәт-Барак хан кулына күчкәч, Кырым тирәсенә чигенә, нәтиҗәдә Солхатта 1424-нче елның башында аның вәкиле булып безгә таныш булган шырын бәге Тегинә урнаша, берничә айдан соң хан үзе дә анда килеп, элекке хөкемдар булган туганы Дәүләт-Бирдене ул урыннан бушата, яисә, аны, үз урынбасары Тегинә бәкне янына куеп, ныграк контрольгә ала. Ахыр чиктә, Олуг-Мөхәммәт Кырымда төпләнә, ә Дәүләт-Бирде аннан качып китә. Ләкин, 1424–1425-нче елларның чикләрендә Дәүләт-Бирде үзенең биләмәсен кире кайтаруга ирешә, ә Олуг-Мөхәммәт, үз чиратында, Бөек Литва кенәзлегенә кача. Витовтның ярдәме белән ул тиз арада үз хәлен яхшырта һәм Кырымны яңадан контроль астына ала, әмма үзе 1425–1426-нчы елның кышын Түбән Днепр җирләрендә, далада, үткәрә дә, 1426-нчы елның язында Мөхәммәт-Барак ханга һәм аңа хезмәт иткән Идегәйнең улы Мансурга каршы һөҗүм башлый. Олуг-Мөхәммәт көнчыгышта походта булганда Дәүләт-Бирде Кырымда үз хөкемлеген яңадан торгыза. Олуг-Мөхәммәт исә Сарай шәһәрен кире кайтара, ә Мөхәммәт-Баракны Урта Азияга кысырыклап чыгара. Ахрысы, алга таба Дәүләт-Бирде берникадәр уңышларга ирешеп, Сарайны да ала (һәрхәлдә, анда аның исеменннән 831 х.е./1427/1428-нчы елда сугылган акчалары билгеле). Әмма, чынлыкта ул 1427-нче елдан соң чыганакларда башка искә алынмый, Олуг-Мөхәммәт исә Бөек Литва кенәзе Витовт ярдәме белән Кырымны кире кайтаруга ирешә.

Бу вакыйгаларда шырын кабиләсе бәге Тегинә актив роль уйный. Гомумән алганда, Олуг-Мөхәммәткә буйсынган Олуг Урдада бу дәвердә

Тегинә бәктән башка тагы конграт бәге Айдар һәм мангыт кабиләсе башлыгы Идегәйнең улы Нәүрүз көчле лидерлардан саналган. Әмма, соңгысы атасы дәрәҗәсенә ирешә алмаган һәм ханнан шуңа күрә риза булмаган. Тегинә (аның Кырымдагы ставкасы Солхат/Иске Кырым шәһәрендә була) исә 1431–1432-нче елның кышында Идел буеннан үзенең Кырымдагы ставкасына кышлауга киткәндә, Олуг-Мөхәммәт белән арасын боза (Мәскәү бөек кенәзлегенә кемне утырту мәсьәләсе буенча ханның һәм аның ягында хәрәкәт иткән конграт бәге Айдарның фикере белән ширин кабиләсе бәге фикере туры килмәү аркасында). Башка сәяси вакыйгалар белән бергә, бу, сарай эчендәге конфликт, Олуг-Мөхәммәт өчен начар бетә – 1433-нче елның көзендә аның кияүе булган Айдар бәк тәхеткә Сәйед-Әхмәтне (ягъни Дәүләт-Бирденең энесен) ханлыкка күтәрә, ә Олуг-Мөхәммәт кулында Олуг Урданың бер өлеше генә (Кырым, Днепр-Дон елгалары арасы) кала. Шуның өстенә, 1436-нчы елны мангыт Нәүрүз бәй Иделнең Хаҗитархан шәһәре тирәләрендә хөкем иткән Кече-Мөхәммәт хан ягына чыга, ә бу, үз чиратында, Сәйед-Әхмәткә Кырымны яулап алу мөмкинлеген тудыра (карагыз: [Гулевич: 2018. С. 159–182]). Олуг-Мөхәммәт үзенең якыннары һәм зур булмаган гаскәре белән (барысы – 3500 кеше чамасы) төньякка – рус җирләренең чикләренә, Белев шәһәре янына чигенә һәм озак та үтмәстән Болгар/Казан вилайәте җирләренә килеп кереп, шунда кала. Бу әһәмиятле сәяси вакыйга турында – ул бит, ахыр чиктә, Казан ханлыгына нигез салуга китерә – аерым зур сөйләшү кирәк, монда андый бурыч куелмый, шуның өстенә бу мәсьәлә инде бераз тикшерелде. Ләкин бер сорауга җавап бирү таләп ителә: Олуг-Мөхәммәт белән аңа электән хезмәт иткән кабиләләр (ширин, барын, аргын, кыпчак) тулаем киткәннәрме, әллә аларның бер өлеше генә төньякка юл тотканмы?

Бу сорауга тулы җавап бирү мөмкин түгел, шулай булса да, Олуг-Мөхәммәт белән аның нәселенең «иске нукерларының» бер өлешенең үз кешеләре белән күчеп киткәнлеген расларга була. Әйтик, Казан шәһәреннән ерак булмаган ике авылның (Зур Карауҗа һәм Кече Карауҗа) һәм алар белән бәйле (хәзер Казан эчендә калган) «Каравай»/«Караби» исемле бистәнең булуы, бу торак пунктларга нигез салучыларның шәҗәрәләренең Чура би Нарыков белән тоташуы, безнең фикер буенча, бер төркем аргын кабиләсе вәкилләренең Кара-хуҗа би җитәкчелегендә монда килеп утыруларын раслый. Бу күчеп утыру, аргын кабиләсе бәге Кара-хуҗаның тарихи чыганакта соңгы тапкыр 1405-нче елны күрсәтелүен (ул, илче буларак килгәч, бик яшь булмагандыр) дә искә алсак, фәкать тик Олуг-Мөхәммәт һәм аның улы Мәхмүтәк заманында гына була ала. Шушындый күчешнең чынлап та булганлыгын, инде алда әй-

телгәнчә, Казан ханлыгында 1455-нче елны күрсәтелгән Шаптяк Сараевич исеме дә раслый. Әгәр дә ул барын кабиләсе бөге Сарай белән бәйле булса – ә бу бик мөмкин – барыннар да шул ук дәвердә Олуг-Мөхәммәт белән Казан җирлегенә күчкән булып чыгалар.

Чура батыр белән бәйле авыллар XVI–XVII-нче йөзләрдә Казан өязенең төньяк-көнбатышындагы «Галич юлында» (Галицкая даруга) булганлыктан [Исхаков: 2002. С. 348–353], шушы территорияне Казан ханлыгындагы аргын кабиләсе бәкләре биләмәсе дип санарга кирәк. Бу мәсьәләне без әле аерым тикшерербез, аңарчы башка бер проблемага тукталыйк. Ул – Кырымда калган безгә инде таныш булган дүрт кабилә турындагы мәсьәлә. Аның төп эчтәлеге шунда: Олуг-Мөхәммәт үзенә буйсынган Олуг Урданы (аңа, әйтелгәнчә, Кырым биләмәсе дә караган) ташлап китәргә мәҗбүр булгач, Кырымда элеккеге Туктамыш ханның бабаларыннан килгән кабиләләрнең бер өлеше калу мәсьәләсе. Бу калу исә тарихи чыганаклар тарафыннан раслана. Аларны карап үтик, чөнки Чура Нарыковның Кырымдагы «эзләренә» шулай гына төшәргә мөмкин.

Безнең өчен әһәмиятле бер мәгълүмат кырымлы тарихчы Реммал хуҗаның (Кайсуни-заде Мехмед Нидаи) «Тарих-и Сахиб-Гәрәй хан» исемле хезмәтендә сакланган. Бу, XVI-нчы йөзнең беренче яртысына караган чыганакта, сүз 1538–1551-нче еллар арасындагы Кырым ханлыгының хәрби походларын тасвирлаганда, аның авторы 1543-нче елга караган армиядә булган кабилә гаскәрләре турында информация биреп, безгә таныш булган дүрт карачы бәкләргә буйсынган кабиләләрнең өчесенең (дүртенче булып бу очракта 1502-нче елдан соң Кырымда көчәйгән мангыт кабиләсе атала) хәрби потенциалын күрсәтә: ул елда ширыннар 5 мең, аргын һәм кыпчак кабиләләре 3 мең сугышчы чыгарганнар [Инальчик: 1995. С. 76]. Безгә XVI-нчы йөз башларындагы ширын кабиләсе вәкилләренең гомуми саны билгеле – 20 мең кеше [Исхаков: 2009-а. С. 41]. Шушы саннан чыгып карасаң, Кырымда төпләнеп калган кабиләләрдәге гомуми халык саны белән аның сугыш эшләрендә катнашучыларының пропорциясе 4:1 булып чыга. Шулай булганда, аргын һәм кыпчак кабиләләре кабиләдәшләренең гомуми саннары XVI-нчы йөзнең беренче яртысында якынча 12 мең чамасы булган дип уйлый алабыз. Дөрес, аерым рәвештә аргын кабиләсенең кеше саны безгә билгеле түгел. Һәрхәлдә, ул сан әллә ни зур булмаган. Ләкин, барыбер Кырым ханлыгында аргын кабиләсенең бер өлеше Олы-Мөхәммәттән соң да калган һәм анда әһәмиятле роль уйнаган, дип раслый алабыз. Бу фикерне өстәмә рәвештә дәлилләүче тагы берничә факт китерә алабыз. Әйтик, 1501-нче елны, Иван III Кырымга затлы татарларга бүләкләр җибәргәндә, алар ара-

сында шырын, барын һ.б. кабиләләрнең җитәкчеләре белән бергә «Мардан Аргын» дигән шәхес тә искә алына [Сборник: 1884. Т.41. С.352]. Ул чынлыкта бәк булган, чөнки икенче тапкыр ул 1508-нче елны Кырым ханы Меңгли-Гәрәй хатында башка бәкләр белән (алар ике өлештән торалар: беренче төркем – Кырым ханлыгына 1502-нче елдан соң кушылган Олуг Урда бәкләре – кыйат, мангыт, салҗигут, конграт кабиләләренең лидерлары; икенче төркем – шырын, барын, аргын, кыпчак кабиләләре лидерлары) бергә «Аргын Мардан князь», дип искә алына [Сборник: 1895. Т.95. С.20]. Күренә ки, бу очракта да күрсәтелгән ике төркем (бәлки ул икегә бүленү Кырым ханлыгы гаскәрләренең уң һәм сул канатка бүленүе белән бәйледер) бәкләре (кнәзләре) дәүләттәге төп кабиләләрне чагылдырганнар. Һичшиксез, Мардан бәк артында Кырым ханлыгындагы аргын кабиләсе торган.

Аргын кабиләсенең бәкләре Кырым ханлыгына караган документларда алга таба да искә алыналар: Кырым ханы Меңгли-Гәрәйнең 1515-нче елга краган «Сүзендә» аргын Манташ «князь» (чыганак рус телендә сакланган) башка аксөякләр исемлегендә күренә, Баһадир-Гәрәй солтанның «яхшы хезмәтчеләре» арасында 1519-нчы елны аргын Али-Шукур «князь» булганлыгы билгеле [Сборник: 1895. Т.95. С.161, 610]. Шулай ук, 1517-нчы елны Кырым ханы Махмед-Гәрәй Мәскәү бөек кенәзе Василий Иванович белән килешү төзү турында сөйләшкәндә, шартнамәгә ризалык бирергә тиешле карачы бәкләр арасында без белгән дүрт кабилә аталып, алар арасында аргын кабиләсе дә саналып кителә [Сборник: 1895. Т.95. С.388]. Ниһаять, 1519-нчы елгы Мәскәү белән Кырым арасында килешүгә кул кую өчен төзелгән Кырым ханлыгының аксөякләре исемлегендә кыпчак, конграт, кыят кабиләләренең бәкләре белән бергә ике аргын кабиләсе вәкиле дә күренә – берсе инде безгә таныш Али-Шукур «князь», икенчесе – Корбан-Али «князь» [Малиновский: 1863. С.415]. Чынлыкта бу исемлектә кабилә лидерларының ике төркеме булып, аның беренчесе шырын кабиләсе башлыгы Мемеш «князь»дан башланса, икенчесе (аргын кабиләсе бәкләре шунда күрсәтелгән) кыпчак кабиләсе лидеры Исмаил «князь»дан башлана. Инде әйтелгәнчә, бу Кырым ханлыгындагы кабиләләрнең уң һәм сул кул кабиләләренә бүленүе белән бәйле булып, аргыннар һәм кыпчаклар, башка кайбер кабиләләр белән (конграт, кыят) бергә, бу дәүләтнең сул канатын тәшкил иткәннәр булса кирәк. Бу нәтиҗәне истә тотыйк, чөнки ул безгә әле кирәк булачак. Хәзергә исә без тагы бер тапкыр тулы ышаныч белән аргын кабиләсенең бер өлешенең Кырым ханлыгында инде XV-нче йөздән үк яшәгәнлеген раслый алабыз.

Шушы нәтиҗә нигезендә яңадан Чура Нарыковның Казан ханлыгындагы социаль статусы мәсьәләсенә кире кайтыйк.

*(Дәвамы бар)*

**Әдәбият**

***1. Чыганаклар.***

1. Әхмәтҗанов М. И. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. Казан: «Мәгариф» нәшр., 2002. – 343 б.
2. Әхмәтҗанов М. И. Татар шәҗәрәләре (Беренче китап). Казан: Татар. кит.нәшр., 1995. – 128 б.
3. Әхмәтҗанов М. И. Татар шәҗәрәләре. Том I. Казан: Г. Ибраһимов исем. ТӘСИ, 2011. – 584 б.
4. Батырлар жыры. Бесінші том. Қырымның іырыі батыры (Мұрын жыраудан жазылған мұралар). Алматы: «Жазушы», 1989. – 384 б.
5. Идегәй. Татар халык дастаны. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 254 б.
6. История Казахстана в персидских источниках. Т. IV / Сб. материалов, относящихся к истории Золотой Орды. Извлечения из персидских сочинений, собр. В. Г. Тизенгаузеном и обраб. А. А. Ромаскевичем и С. Л. Волиным. Доп. и перераб.издание. Алматы: «Дайк-Пресс», 2006. – 620 с.
7. Казанская история. Под-ка текста, вступ.ст. и прим. Г. Н. Моисеевой. Под ред. чл.-корр. АНСССР В. П. Адриановой-Перетц. М.-Л.: Изд-во АНСССР, 1954. – 191 с.
8. Къырымтатар халкъ агъыз яратыджылыгъы. Хрестоматия. Тертип этиджи Дж. Бекиров. – Ташкент: «Ўқитувчи», 1991. – 248 б.
9. Малиновский А. Историческое и дипломатическое собрание дел, происходивших между российскими великими князьями и бывшими в Крыме татарскими царями с 1462 по 1533 год. // Записки Одесского ОИД. Т. 5. Одесса, 1863. – С. 178–419.
10. Ногай халк йырлары. М.: Наука. Гл. ред. Вост. лит-ры, 1969. – 215 с.
11. Образцы народной литературы северных тюркских племен. Ч. VII. Наречия Крымского полуострова. Собр. В. В. Радловым. СПб., 1896. – 935 с.
12. ПСРЛ. Т. 13. Патриаршая или Никоновская летопись. М.: Наука, 1965. – 532 с.
13. Сборник материалов для статистики Сыр-Дарьинской области. Т. IV. Ташкент, 1895. – 240 с.
14. Сборник РИО. Т. 41. Памятники дипломатических сношений Московского государства с Крымскою и Ногайскою Ордами и с Турци-

ею. Т. 1. с 1474 по 1505 гг.Эпоха свержения монгольского ига в России. СПб., 1884. – 558 с.
15. Сборник РИО. Т. 95. Памятники дипломатических сношений древней России с державами иностранными. Т. 3. Памятники дипломатических сношений Московского государства с Крымом, Ногаями и Турциею. 1508–1521 гг. Под ред. Г. Ф. Карпова и Г. Ф. Штендмана. СПб., 1895. – 706 с.
16. Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан: Татар кит. нәшр., 1984. – 383 б.
17. Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 367 б.
18. Татар эпосы. Дастаннар. Казан: «Раннур» нәшр., 2004. – 639 б.
19. Чура Батыр. Татар халык дастаны. Казан. Татар кит. нәшр., 1993. – 63 б.
20. Шмидт С. О. Продолжение хронографа 1512 г. // Исторический архив. VII. М.: Изд-во АНСССР, 1951. – С. 254–299.
21. Bozcigit. Dobruca Tatar Masalları. Birinci kitap / Toplagan, kaytabaştananlatkan hem azirlegenler: N. Mahmut, E. Mahmut. – Bucureşti: Kriterion Kitap Üyi, 1988. –258 s. (электронный ресурс: http://qirimtatar-bg.blogspot.ru/2012/09/cora-batr-destan.html. Керү датасы: 11.01.2019.).

***2. Тикшерүләр.***

22. Алишев С. Х. Казань и Москва государственные отношения в XV – XVI вв. Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. – 160 с.
23. Алишев С. Х. Исторические судьбы народов Среднего Поволжья. XVI – начала XIX в. Отв. ред. д.и.н. З. И. Гильманов, А. А. Преображенский. М.: Наука, 1990. – 270 с.
24. Бахтин А. Г. XV–XVI в. в истории Марийского края. Йошкар-Ола: Мар. полигр. – изд. комб., 1998. – 191 с.
25. Валиханов Ч. Ч. [Заметки при чтении книги] проф. И. Н. Березина «Тарханные ярлыки» // Валиханов Ч. Ч. Собрание сочинений в пяти томах. Т. 1. Алма-Ата: Гл. ред. Казахской сов. энциклопедии, 1984. – С. 104–114.
26. Гулевич В. П. От ордынского улуса к ханству Гиреев: Крым в 1399–1502 гг. Казань: Ин-т истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2018. – 492 с.
27. Ибраһимова Л. Х. Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. Казан: Фикер, 2002. – 192 б.
28. Инальчик Х. Хан и племенная аристократия: Крымское ханство под правлением Сахиб Гирея // Панорама-Форум. 1995. № 5. – С. 73–94.

29. История татар с древнейших времен в семи томах. Т. IV. Татарские государства XV–XVIII вв. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2014. – 1080 с.
30. Исхаков Д. Чора батыр – кто он? // Татарстан. 1997. № 12. – С. 24–30.
31. Исхаков Д. Чура батыр кем ул? // Идел. 1994. № 9. – 16–19 бб.
32. Исхаков Д.М. Родословные и эпические произведения как источник изучения истории сословий Улуса Джучи и татарских ханств // Источниковедение истории Улуса Джучи (Золотой Орды). От Калки до Астрахани. 1223–1556. – Казань, 2002. – С. 329–366.
33. Исхаков Д.М. Тюрко-татарские государства XV–XVI вв. – Казань: Тат. кн. изд-во, 2009-а. – 142 с.
34. Исхаков Д.М., Измайлов И.Л. Этнополитическая история татар (III– середина XVI вв.). Научное издание. Казань: РИЦ «Школа», 2007. – 356 с.
35. Исхаков Д.М. От средневековых татар к татарам нового времени (этнологический взгляд на историю волго-уральских татар XV–XVII вв.). Казань: Изд-во «Мастер-Лайн», 1998. – 276 с.
36. Қорғанбеков Б.С. «Шора батыр» эпосы: нұсқалары, генезисы, тарихылығы. Монография. Астана: Фолиант, 2014. – 304 б.
37. Лашков Ф.Ф. Исторический очерк крымско-татарского землевладения // Известия Таврической УАК. 1895. № 23. – С. 71–129.
38. Миргалеев И.М. Политическая история Золотой Орды периода правления Тохтамыш-хана. – Казань: Алма-Лит, 2003. – 164 с.
39. Тынышпаев М. Материалы к истории киргиз-казахского народа (Читаны в Туркестанском отделе РГО в 1924 и 1925 гг.). Ташкент: Вост. отд. Киргиз. гос. изд-ва, 1925. – 62 с.
40. Урманче Ф. Чура батыр (эссе) // Мирас. 1995. № 7–8. 145–152 бб.; № 9. 98–109 бб.; 1996. № 1–2. 165–170 бб. (дәвамы № 7–12).
41. Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. Казань: Изд-во Казан.ун-та, 1972. – 222 с.
42. Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. Репринтное воспр. издания 1923.: – Казань: Фонд ТЯК, 1990. – 310 с.
43. Хусаинов Г.Б. Шежере как историко-литературный памятник // Башкирские шежере (Филологические исследования и публикации): Сб.ст. Уфа: БФ АН СССР, 1985. – С. 3–23.
44. Paksoy H.B. Chora Batir: A Tatar Admonition to Future Generations // Studies in Comparative Communism. 1986. Vol. 19. Nos. 3–4. – PP. 253–265.

*И.Л. Измайлов*

# ДРЕВНИЕ ТАТАРЫ В ЦЕНТРАЛЬНОЙ АЗИИ (VI–IX вв.)

*(Продолжение. Начало: № 2, 2019)*

## Татары и каганаты тюрков: вместе и врозь.

Внутренняя ситуация в степях Монголии и Восточного Туркестана в период Тюркского каганата была достаточно стабильной, но письменные источники описывают ее очень кратко и фрагментарно, что не позволяет во всех деталях проследить историю татар в этот период. Не помогает в этом и археология, поскольку ее данные для VI–VII вв. немногочисленны и отличаются определенным единообразием (в основном это погребения, где умерший похоронен с конем: довольно стандартный набор погребальных вещей – посуды, украшений, конского снаряжения и оружия), при значительных различиях в деталях, а это затрудняет их этнокультурную атрибуцию. Практически невозможно пока отличить друг от друга погребения различных племен, упоминаемых в письменных источниках.

Можно определенно сказать только то, что татары по мере ослабления Тюркского каганата стали стремиться к самостоятельности. Власть тюркских каганов не позволяла им бороться за власть над Кашгарией и караванными путями, по которым китайский шелк поступал в Среднюю Азию и далее в страны Средиземноморья. Добились желанной цели они после распада и гибели каганата в середине VII в., когда вместе с уйгурами стали претендовать на гегемонию в Восточном Туркестане. К этому времени в составе татар, очевидно, произошли определенные изменения. Судя по тюркским источникам, в этот период они уже именуются «отуз-татарами», т.е. их правители стали управлять более сильной конфедерацией из тридцати племен. Вместе с уйгурами они, видимо, заняли территории, которыми ранее владели тюрки и стали выходить к китайским границам, добиваясь признания их прав на тюркское наследие и долю в выплатах дани.

Расширив свою территорию после гибели Тюркского каганата, они не желали ее отдавать. Поэтому им пришлось вступить в борьбу с возрожденным Вторым Тюркским кагантом. Уже в начале VIII в., после объявления о возрождении Тюркского каганата, при правлении Капаган-кагана началась всеобщая война. Реалии этнополитической обстановки описывались в надписи на эпитафии Кюль-тегину весьма красноречиво. Из этого текста следует не только то, что тюрки, вернувшись в степи и стремившиеся к прежнему великодержавию, сломали сложившуюся си-

стему владений и должны были завоевать свои земли и подчинить другие народы не столько силой своей власти, сколько заставить их смириться с перераспределением земли. Это не могло не вызвать ожесточенного сопротивления, которое возглавили уйгуры, ставшие во главе девяти племен огузов («токуз-огузов»). При этом татары участвовали во всех коалициях, направленных против тюрков.

Неудивительно, что они враждебно восприняли возрождение Тюркского каганата и сразу вступили в конфронтацию с ним. В той же надписи Кюль-тегина отуз-татары названы в числе врагов его отца Ильтерес-кагана (ум. в 691 г.), когда они вместе с *кыргызами* поддержали *токуз-огузов* (т.е. уйгуров), воевавших с тюрками:




Уйгурский каганат (по материалам Издательства ДИК) и локализация татар.

«Справа (т.е. на юге) народ табгач был врагом, слева (т.е. на севере) народ токуз-огузов Баз-кагана был врагом, кыргызы, курыканы, отуз-татар, кытай и татабы все были врагами…» [КТб: 14; Малов: 1951. С. 30, 38.].

*И если справа (т.е. на юге) нас табгачи (империи Тан) стерегли,*
*То слева (т.е. с севера) Баз-каган токуз-огузов гнал на нас –*
*Не счесть врагов: кыргызов, курыкан,*
*киданей, татабов и отуз-татар – все к нам…*
[КТб: 14; Перевод см.: Малов: 1951. 1993. С. 29.].

В борьбе с врагами, которые окружали тюрков, они продемонстрировали небывалую дерзость и мощь, нанеся поражение своим врагам, разбив их поодиночке. Это были жестокие и кровавые войны непримиримых противников. По словам той же надписи, Ильтерес-каган в ходе сорока семи военных походов и двадцати сражений:

*По милости неба он отнял (у враждебных народов – И.И.) племенные союзы (или) у имевших племенные союзы и отнял каганов у имевших (своих) каганов, врагов он принудил к миру, имевших колени он заставил преклонить колени, а имевших головы заставил склонить (головы)* [Малов: 1951. С. 38.].

Татары и уйгуры играли в этих событиях важную роль. Их объединяло не только желание не допустить возрождения и усиления власти тюркских каганов, но также географическая близость и союзнические отношения. Об этом писал автор эпитафии Бильге-кагану: «…тогда народ огузов пришел, объединившись с токуз-татарами. Я дважды вступал с ними в крупные сражения при Агу и разгромил их войско; их страну тогда я захватил» [БКб: 34; Тугушева: 2008. С. 61.]. Поражение ослабило уйгур и татар, но не заставило смириться и покориться власти тюрков.

Спустя некоторое время, в 723–724 гг., токуз-татары, вновь вступив в союз с токуз-огузами (уйгурами) и карлуками, начинают войну против Бильге-кагана, как о том повествует руническая стела с эпитафией старшему брату Кюль-тегина Бильге-кагану: «…тогда народ огузов, объединившись с токуз-татарами, подступил к нам…» [БКб: 34; Тугушева: 2008. С. 51–67]. Но коалиция вновь была разбита тюрками. Не исключено, что, преследуемые тюрками, татары отступили вглубь Монгольского Алтая, а часть расселилась в Южной Монголии и даже в Северном Китае, где возникли их племенные объединения. Впрочем, возможно, что еще ранее отдельные племена татар и уйгур сами переселились к границам Империи Тан – в район р. Эдзин-Гол и Приманьшанье. Некоторые из них после падения тюрок вернулись обратно в родные кочевья, но некоторые остались, положив начало новым татарским племенам.

Поражения и переселения, видимо, настолько ослабили татарское объединение, заставив на время забыть о независимом государстве, что, войдя в союз с *кыргызами*, они стали накапливать силы, на два десятилетия перестав проявлять заметную активность на исторической арене

Великой степи. На ней между тем происходили драматические перемены этнополитических декораций. Под ударами уйгуров, кыргызов и карлуков окончательно распадается Тюркский каганат, а в степях наступает период гегемонии уйгур.

### Татары и уйгуры: война и вынужденный мир.

Этнополитическая и географическая близость уйгуров и татар делало их, с одной стороны, естественными союзниками, а с другой – активными и непримиримыми противниками тюрков. Особенно эта враждебность усилилась в условиях возрождения Тюркского каганата. Неоднократные военные конфликты определенное время заканчивались поражением врагов тюрков. Но восстания и сражения не прекращались.

Сопротивление врагов тюрков только усиливалось, а их силы постепенно таяли. Периодические войны уйгуров, карлуков, басмылов и татар с тюрками привели, в конце концов, к разгрому и распаду второго Тюркского каганата. В 744 г. басмылы нанесли несколько серьезных поражений тюркам. Но в том же году уйгурский вождь Гули Пэйло, внезапно восстал и разбил кагана басмылов Иси-кагана. В 745 г. он окончательно разбил остатки кок-тюрок и, казнив Баймэй-кагана, отослал его голову китайскому императору, положив конец власти и династии тюрков. Остатки народа кок-тюрок вошли в состав нового Уйгурского каганата.

Падение каганата тюрков не принесло независимости татарам. Уйгуры, свергнув власть тюрок, унаследовали их государственные традиции и великодержавные амбиции (Подробнее см.: [Кляшторный: 2010. 328 с.]). События первых лет становления Уйгурского каганата нашли отражение в тексте на поминальной стеле, обнаруженной в местечке Могон Шине Усу, посвященной уйгурскому кагану Элетмиш Бильге-каган (Моюн-чор) (760 г.) [Ramstedt: 1913. vol. XXX. № 3. S. 17; Тугушева: 2008. С. 94–111].

По свидетельствам автора эпитафии, уже в 748–749 гг. первый уйгурский каган Элетмиш Бильге-каган (Моюн-чор), воевал с токуз-татарами, предводитель которых, Тай Бильге-тутук, вступил в союз с огузскими племенами. В эпитафии уйгурскому кагану Моюн-чору, сказано: «Чтобы в Бюкегюке не оставалось секиз-огузов и токуз-татар, во второй день новолуния я вступил в бой с восходом солнца… и тогда я их сокрушил. Простой народ я не стал уничтожать, их жилища, имущество и скот я не отбирал. Я назначил им налог и оставил жить. Я назвал их своим народом, повелел им последовать [за мной] и, оставив их удалился, но они не пришли. Я снова стал их преследовать и настиг их в Боргу. Вступил с ними в сражение в девятый день новолуния и нанес им поражение. Их скот и имущество, дев и жен я доставил [с собой]» [МЧб: 13–14; Малов: 1959. С. 30–44; Тугушева: 2008. С. 104].

В ответ огузы и токуз-татары собрали основные силы и двинулись на уйгуров. В надписи, посвященной Моюн-чору, это сражение подробно описано: «В пятом месяце они пришли следом; секиз-огузы и токуз-татары пришли без остатка. Я поставил войска вплоть до западной оконечности Селенги, до южных окраин Йылун-Кола и до вершин Шипа. Они подошли, продвигаясь по Кергю, Шакшу и вершине Шипа, и выстроили войско, фланги которого доходили до Селенги. В двадцать девятый день пятого месяца я сразился и тогда их сокрушил» [Тугушева: 2008. С. 104–105].

Но татары продолжали сражаться. Спустя три месяца они собрали новое войско, но в сражении на озере Чыгылтыр вновь потерпели поражение. В эпитафии Моюн-чора написано, что он стал преследовать отступающих и в 19 день восьмого месяца у истоков Кейре в Уч-Беркю «в очередной раз сразился с татарами. Часть народа покорилась, [другая] часть вошла [в состав]» [Тугушева: 2008. С. 105].

Таким образом, в конце VII – первой половине VIII в. татары были тесно связаны с уйгурами и огузами, вступая с ними в союз, или воюя с ними. В этой круговерти войн татары теряли отдельные племена и роды, которые постепенно заселяли южную кромку центральноазиатских степей и Восточную Монголию, где образовывались несколько крупных племенных объединений.

В этот период татары, скорее всего, были одним из вассальных племенных союзов в Уйгурском каганате и в основном проживали в долинах рек Орхон и Селенга, Онона и Керулена и предгорьях Хингана и Ябленова хребта (Северо-Восточная Монголия). По словам китайского автора XII в. Ван Минцзи, на заре своей истории «татары были пастухами коров у уйгуров» [Кычанов: 1980. С. 143.]. Воспоминание об этом, сохранившееся через века, видимо, в устной традиции, указывает на вполне реальные исторические обстоятельства. Татары на некоторое время были покорены и не помышляли о новой войне, как и их союзники кыргызы и карлуки.

Таким образом, в первой половине VIII в. имеются явные следы серьезных структурных изменений в татарской этнополитической общности.

Интересно отметить, что примерно с начала VIII в. китайские чиновники (по «Синь Тан шу»), создававшие в степи вассальные округа, также начинают описывать тюрков как «девять племен» или «девять фамилий», иногда с определением «тюркские племена девяти фамилий», а также «татары девяти фамилий / цзю син дада» или «уйгуры девяти фамилий / цзю син хуэйхэ» [Малявкин: 1981. С. 116.]. С одной стороны, это показывает некую этнополитическую близость между уйгурами и та-

тарами, а с другой – дробление старых родоплеменных объединений и формирование новых. Подобные перекройки этнополитической системы Центральной Азии особенно бурно протекали в период становления и распада тюркских империй – Тюркского и Уйгурского каганатов.

В течение ста лет Уйгурский каганат развивался, успешно сопротивляясь попыткам Тибета и Танского Китая завоевать его земли. Уйгурские каганы носили титул бильге-каганов (т.е. «мудрых каганов»), а вся их титулатура была аналогична тюркской. Ставка уйгурского кагана называлась «ячжан» и была настоящим поселением. Каган жил в замке, обнесенном стеной, который именовался «уйгурский город». Летом каган сидел «в золотом шатре» (См.: [Кычанов: 1997. С. 122.]). Представления о великом правителе, который сидит в своей «золотой ставке»/«золотом шатре», с этого времени стали традиционными для тюркской, и особенно, татарской политической культуры.

В степи наступает относительное спокойствие. Но это было затишье перед бурей.

Целый ряд факторов способствовал изменению обстановки в восточном крае Великой степи и падению уйгурского великодержавия. Один из них – усиление в этот период Тибета, который в 783 г. заключил мир с Танской империей, которая вынуждена была признать власть тибетцев над Кашгарией. Спустя некоторое время Тибет нанес ряд существенных поражений Уйгурскому каганату, а к 791 г. весь Западный край оказался во власти Тибета, который и установил контроль за развивающейся торговлей по кашгарскому коридору из Китая в Среднюю Азию. Это заметно ослабило уйгуров, но еще не было концом их каганата.

Другая причина, которую подметили китайские современники, состояла в том, что уйгуры, испробовав дары цивилизации, как до них тюрки, переживали период сословно-классового расслоения. Военные дружины их, еще недавно наводившие ужас на соседей, сократились в числе, поскольку часть скотоводов стала строить поселения в благодатных долинах Восточного Туркестана и переходила к земледелию. Китайский автор того времени Шао Бо-вэнь интерпретировал эти перемены по-своему. Он писал: «Вначале обычаи уйгуров отличались простотой и искренностью и различия между князьями и народом не были очень большими. Поэтому помыслы народа были едиными и /уйгуры/ были сильны и непобедимы. … Танский двор делал им богатые пожалования. Каган Дэн-ли впервые зазнался, стал строить дворцы для жилья. У женщин имелись пудра, краска для бровей и /одежда/ украшенная парчёвыми вышивками, все это изготовлено в Срединном государстве. Расточительство вызвало разложение варварских обычаев» [Малявкин: 1974. С. 92.]. Богатства

высшей уйгурской аристократии вызывали раздражение у основной части уйгурской знати, к чему примешивалось недовольство принятием чуждых тюркам религиозных вер – манихейства и буддизма. До поры до времени это недовольство сдерживалось, но в период военных неудач и природных бедствий, выплеснулось наружу.

Основной причиной, усугубившей все остальные социально-политические факторы, стали идущие подряд засухи, снежные зимы и массовый падеж скота. В течение двух лет подряд в степях Западной Монголии был джут. В китайском источнике «Тан хуэйяо» под 839 г. есть такая запись: «…Ряд лет подряд был голод и эпидемии. Павшие бараны покрывали землю. Выпадал большой снег», в других хрониках пишется о массовом падеже скота и голоде (Цит. по: [Малявкин: 1983. С. 23.]). Природная катастрофа обострила внутренние противоречия. Дело в том, что незадолго до этого в 795 г. пресекся род уйгурских каганов из клана йаглакар и титул кагана принял один из правителей – Кутлуг. Он опирался на племя эдизов, которое не входило в состав девяти телесских племен, но было долгое время в союзе с уйгурами. Сам этот факт свидетельствует о резком ослаблении влияния уйгур и не могло не привести к желанию рода йаглакар и других уйгурских родов восстановить былое.



Развалины Орду-Балыка. Фото И. Л. Измайлова

Одновременно ослабление уйгур вызвало восстание побежденных, но не покоренных, племен карлуков и кыргызов. Все закончилось тем, что началась междоусобная война, в ходе которой один из претендентов на власть призвал себе на помощь кыргызов. Кыргызы ворвались в степи Центральной Азии, но не для того, чтобы укрепить власть уйгуров,

но чтобы установить свою. Перед нанесением решающего удара кыргызский правитель (*ажо*) писал уйгурскому кагану: «Твоя судьба кончилась. Я скоро возьму золотую твою орду (т.е. ставку), поставлю перед ней своего коня, водружу мое знамя» [Бичурин: 1950. Т. 1. С. 355.]. В ходе молниеносной войны 839–840 гг.уйгуры были разбиты. Их города, включая столицу Орду-Балык, разрушены, а каган и его родственники убиты. Некоторая часть уйгуров и их союзников, включая татар, были вынуждены бежать к границам Империи Тан и в Восточный Туркестан, где из-за внутренних противоречий рушилось Тибетское государство, а местные князья были очень слабы.

Кыргызы нанесли страшный удар не только по уйгурам, но и по их союзникам татарам. Уникальным свидетельством этого является обнаруженная в 1960 г. в местности Хербис-Баары (Тува) неизвестная дотоле кыргызская стела с рунической надписью. Памятник содержит эпитафию знатному воину по имени Кюлюг Йиге. Главным его подвигом, упомянутым в тексте, был поход на татар: «В свои двадцать семь *лет,* ради *моего* государства, я ходил на токуз-татар». Об этих же событиях повествует и стела с рунической надписью (девятый памятник с Уйбата), найденная в Хакасии близ р. Уйбат. В ней упомянут «татарский враждебный эль» и сообщается о выплате татарами дани или контрибуции кыргызам [Кляшторный: 1987. № 1. С. 33–36.]. В связи с событиями 842 г. татары впервые упомянуты в китайском источнике – письме китайского чиновника Ли Дэюя, как враги кыргызов и союзники последнего уйгурского кагана [Pel1iot: 1949. C. 125–126]. В 842 г., когда Уйгурский каганат был окончательно разгромлен кыргызами, некоторые общины татар, судя по надписи в долине р. Тес, подпали под власть Кыргызского каганата и стали его частью.

Кыргызы распространили свою власть практически на весь Восточный Туркестан и Южную Сибирь. Но великодержавие их оказалось слишком недолговечным. Небольшое племя внезапно распространило свою власть на огромную территорию, но Кыргызский каган просто не имел столько аристократии и воинов, чтобы держать покоренные народы в повиновении, и чиновников, чтобы управлять ими и собирать подати. Здесь необходимо вспомнить истину, что завоевать престол верхом на коне можно, но управлять, продолжая сидеть на нем, невозможно. Не имея развитой социальной структуры и чиновничества, опираясь только на крепкое и умелое войско, оказалось возможным завоевать чужие земли, но наладить мирную жизнь оказалось затруднительным. Этот кыргызский феномен показывает, вопреки мнению некоторых историков, что кочевые империи не имели развитой социальной базы, а обладали только

сильным войском. Опыт более успешных средневековых империи, созданных кочевниками, как раз наглядно демонстрирует, что только высокий уровень социальной организации, кадры чиновников и устойчивая религиозная система, гарантируют сравнительно успешное и долговременное существование кочевой империи.

Кыргызский каганат же в результате ждал неизбежный крах, который закономерно наступил буквально через три десятка лет. Но если в Южной Сибири кыргызы еще долго сохраняли свою гегемонию, то в Восточном Туркестане удержать земли на «уйгурской дороге» в Таримском бассейне, важном участке Великого Шелкового пути, они не смогли. Около 875 г. ганьчжоуские уйгуры и татары восстали и восстановили здесь свою власть. Не удержали кыргызы и Северо-Западную Монголию, где в конце IX в. татарские племена образовали свое государство, а часть их племен вошли в состав уйгурских княжеств.

Интересно, что в ситуации VI–VII вв. союз татарских племен назван в орхонских надписях «тридцатью татарами» (*отуз-татар*), а в середине VIII в., как и в енисейской надписи из Хербис-Баары, они названы объединением «девяти татар» (*токуз-татары*). Из этого можно сделать два вывода. Вероятно, в VIII в. объединение отуз-татар под военно-политическим давлением китайцев, тюрков и уйгур, распалось на несколько союзов племен, а наиболее известным и сильным из них стало объединение *токуз-татар*. Возможно также, что деление на девять родов было характерно для тюркских конфедераций того времени, например, уйгуры в это же время также названы *токуз-огузами*. Именно под этим этнонимом они оказались зафиксированы в арабо-персидской историко-географической традиции.

После первого удара, который им нанесли кыргызы, последовали вторжения монголоязычных киданей из современной степной Манчжурии, захватившие Ордос и бассейн Хуанхе, вытеснив уйгур и татар в различных направлениях – на запад в Восточный Туркестан, на юг – в Ордос, где позднее возникло объединение онгутов – «белых татар», а также на северо-запад – в Прииртышье. Отдельные племенные группы татар, несомненно, вошли в состав киданей и остались на прежних территориях проживания вокруг оз. Буир-Нур. Эти группы по мере ослабления киданей стали играть все более значительную роль в истории Центральной Азии, противоборствуя с племенным объединением монголов под руководством Хабул-хана.

Если брать сведения источников шире и протянуть цепочку событий вглубь веков, то можно вслед за С. Г. Кляшторным сделать вывод о тюркоязычности раннесредневековых татар [Кляшторный: 1993.]. Убеждает

в этом не только этнокультурная история татар, но и постоянное упоминание татар в контексте с другими тюркскими народами в том районе, где исторически проживали тюрки.



Уйгурские беки. Фреска из Дуньхуана.

Распавшееся под ударами кыргызов уйгурское объединение расплескалось по всем краям монгольской степи. В это движение были втянуты и татары, хотя часть их, очевидно, осталась в Северо-Западной Монголии, где они вошли в состав других племенных объединений. Но наиболее сильная и могущественная часть татарских родов, отступала вместе с разгромленными остатками девяти уйгурских племен. Главным направлением отступления уйгуров, разгромленных кыргызами в Северной Монголии, были Ганьсу, Восточный Туркестан и Прииртышье.

## Литература

1. Бичурин Н. Я. (Иакинф). Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. 1. М., Л., 1950.
2. Большая надпись Кюль-тегина (КТб: 4; Перевод см.: Малов С. Е. Памятники древнетюркской письменности. Тексты и исследования. М., Л.: Изд-во АН СССР, 1951. Поэтический перевод см.: Поэзия древних тюрков).
3. Большая надпись Моюн-Чура (МЧб. Малов С. Е. Памятники древнетюркской письменности Монголии и Киргизии. М., Л.: Изд-во АН СССР, 1959. С.30–44).
4. Кляшторный С. Г. Терхинская надпись // Советская тюркология. 1987. № 1.
5. Кляшторный С. Г. Государства татар в Центральной Азии (дочингисова эпоха) // Mongolica. К 750-летию «Сокровенного сказания». М., 1993.
6. Кляшторный С. Г. Рунические памятники Уйгурского каганата и история евразийских степей. СПб.: Петербургское востоковедение, 2010.
7. Кычанов Е. И. Монголы в VI–первой половине VII в. // Дальний Восток и соседние территории в средние века. Новосибирск, 1980.
8. Кычанов Е. И. Кочевые государства от гуннов до маньчжуров. М.: Издательская фирма «Восточная литература» РАН, 1997.
9. Малов С. Е. Памятники древнетюркской письменности. Тексты и исследования. М., Л.: Изд-во АН СССР, 1951.
10. Малов С. Е. Памятники древнетюркской письменности Монголии и Киргизии. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1959.
11. Малявкин А. Г. Материалы по истории уйгуров в IX–XII вв. Новосибирск: Наука, 1974.
12. Малявкин А. Г. Историческая география Центральной Азии. (Материалы и исследования). Новосибирск: Наука, 1981.
13. Малявкин А. Г. Уйгурские государства в IX–XII вв. // Новосибирск: 1983.
14. Тугушева Л. Ю. Тюркские рунические письменные памятники из Монголии. М.: ИНСАН, 2008.
15. Ramstedt G. J. Zwei uigurische Runeninschriften in der Nord-Mongolei // Journal de Societe Finno-ougrienne. Helsinki, 1913. vol. XXX. № 3.
16. Golden P. B. An introduction to the history of the Turkic peoples. – Wiesbaden, 1992.
17. Pel1iot P. Notes sur L’histoire de la Horde d’Or. P., 1949.

*Марсель Бакиров*

## БОЛГАРГА ТОТАШКАН ТАМЫРЛАРЫБЫЗ

- Легенда-риваятьләргә төренгән тарих
- Мәчет-кальганы, каберләрне һәм чик буйларын саклаучы илаһи зат
- Этнос һәм этнокультура билгесе буларак елан-сазаган образлары
- Казан ханлыгыннан калган трофей-ганимәтләр хакында
- Рус храмы диварларында – болгар символлары
- Бараҗ еланы турындагы легенда эзеннән
- Кимак-кыпчаклар: татар кавеме һәм «татар» этнонимы
- Иске татар теле болгар теленең турыдан-туры дәвамымы?
- «Алабуга» атамасында сер-хикмәт бар
- Идел-Кама җирлегендәге татарларның дәүләтчелеге Болгар дәүләтеннән башлана

Төрле гыйлемнәрнең табышларын, шулай ук борынгы культура мирасы материалларын файдалануга нигезләнгән комплекслылык методы хәзерге фәннең бик мөһим бер казанышы булып исәпләнә. Теге яки бу халыкның этногенезына (килеп чыгышына) һәм этник тарихына бәйләнешле проблемалар да, табигый ки, аеруча уңышлы булып төрле фәннәр һәм милли культура ядкарләре үзара очраша торган уртак җирлектә генә хәл ителә ала. Безнең темага мөнәсәбәтле тарихи фольклор да, һичшиксез, халкыбызның этник тарихына бәйләнешле культура мирасына керә.

Фольклорның аерым жанрлары, бигрәк тә риваятьләр һәм легендалар, аеруча кыйммәтле чыганак булып исәпләнәләр, чөнки алар гасырлар тирәнлегеннән килә торган бай мәгълүматлар белән сугарылганнар. Риваятьләр алар – халыкның буыннан-буынга тапшырыла килгән тел-авыз иҗаты елъязмасы. Аларның төп вазыйфасы – борынгы мөһим вакыйгалар һәм шәхесләр турында халыкның хәтерен-истәлекләрен саклау һәм җиткерү, аларга тарихи-эстетик бәя бирү [Соколова: 1971. С. 27.]. Легендалар да, риваятьләр кебек үк, дөреслеккә дәгъва итә торган, заманында сөйләүче тарафыннан да, тыңлаучы ягыннан да булган хәл итеп кабул ителгән һәм кайчакта хәзер дә шулай булып кала торган эпик хикәятләр. Ләкин, риваятьтән аермалы буларак, легендаларда гадәттән тышлык, хыял-фантастика, уйдырма һәм кайчакларда хәтта мифологик башлангыч та катнаша. Тик шулай да легендалар да вакыт-вакыт аерым тарихи мәгълүматлар белән үрелеп-керешеп киләләр. Димәк, алардагы шул тарихи орлыкны яки нигезне күрә һәм таба белергә, иң мөһиме – чынны уйдырма катламнан аерып ала белергә кирәк [Толстова: 1984. С. 19.].

Борынгы Болгар дәүләте һәм аның көнчыгыш чигендә урнашкан меңьеллык Алабуга шәһәре белән бәйләнешле тарихи фольклорны фәнни кулланышка керткәндә һәм бәяләгәндә, без әнә шундый таләпләрдән һәм методологик принциплардан чыгып эш итәргә тиешбез. Бүгенге көндә безгә Алабуга турында һәм, руслар биргән атама белән әйткәндә, «Шайтан каласы» («Чертово городище») хакында берничә риваять һәм легенда билгеле. Аларның иң борынгыларында сүз Кама (Чулман) елгасы буендагы әлеге «кала»да заманында канатлы зур елан-сазаган яшәгәнлеге турында бара һәм җирле халыкның шуңа бәйләнешле ышанулары китерелә. Бу мәҗүси-мифологик легендалар безнең көннәргә Казан ханлыгында әсирлектә булган исеме билгесез кеше язып калдырган «Казанская история» (XVI йөз) һәм Шәрәфетдин Болгари-Мөслими язган «Тәварих-и Болгария» (XVIII йөз) кебек чыганаклар аша килеп җиткәннәр [Казанская история: 1954. С. 194; Усманов: 1972. С. 113,165.]. Шул ук легендаларның аерым вариантлары шулай ук XIX йөз галимнәре П. Рычков, Н.Рычков һәм Ф.Эрдман хезмәтләре аша да мәгълүм [Рычков: 1767. С. 45–46; Рычков: 1870. Ч. I. С. 60–67.].

XIX йөзнең ахырында тарихи мәгълүматларга таянып Платон Заринский ачыклавынча һәм соңрак профессор А. Халиков раславынча, канатлы елан-сазаган образы Болгар дәүләте чорында һәм, өлешчә, хәтта Казан ханлыгы дәверендә дә әле, җирле халык тарафыннан изгеләштерелгән һәм саклаучы-яклаучы мәҗүси-мифик зат итеп күз алдына китерелгән [Заринский: 1880. С. 76, 83; Халиков: 1976. С. 3–19.]. Ата-бабадан килгән бу традициянең, ягъни илаһилаштырылган сазаган культының башы болгарлар һәм татарлар составына субстрат (субстрат – иң борынгы катлам мәгънәсендә) һәм этник компонентлар булып кергән һун-гуннар, сувар-хазарлар, угызлар һәм кимак-кыпчакларга барып тоташа. Ачыклап әйткәндә, кытай язмаларында Үзәк Азия һуннарының Лун-сы («Елан-ләү храмы») дигән гыйбадәтханәдә күккә (Тәңрегә) багышлап корбан бирүләре, хөкемдар-шаньюйлары мәетен ак елан-сазаган сурәте төшерелгән кара ефәккә чорнап күмүләре турында тарихи мәгълүматлар теркәлеп калган [Мелиоранский: 1898. Ч. 317. С. 269.]. Себердәге төрки каһанлык идарәчеләре Билге-каһанның һәм Күл-тегинның каберләре өстенә исә ләү-сазаган ясалган ташлар куелган булган [Руденко: 1962. С. 205.]. Ә менә болгарларның бер кабиләсен тәшкил итүче савир/суварлар Төньяк Кавказда яшәгән вакытта муеннарына алтыннан һәм көмештән елан-сазаган сурәте ясалган бөти-амулет тагып йөргәннәр [Гадло: 1979. С. 145; Каланкатуци: 1984. С. 127.]. Янә килеп, көньяк далаларда яшәгән кыпчаклар канатлы елан-сазаган сурәтен кылыч-хәнҗәр сапларына, садакларына – ук савытларына һәм ат дөрбия-сбруйларына ясый тор-

ган булганнар, һәм, Мурад Аджиның тикшереп ачыклавынча, әлеге яклаучы-саклаучы образ кыпчакларның этник символы булып әверелгән (сүз бара торган мифик образ исеменең кыпчак-куман телендәге һәм Идел буе болгарларындагы вариантлары: сазаган/саруган/шарукан) [Аджи: 1994. С. 87, 335–336.]. Боларга өстәп тагын шуны әйтергә кирәк: Дон буе кыпчакларының башында 150 ел буена «елан-сазаган халкы»ннан чыккан Шаруканнар династиясе-нәселе торган һәм аларның Шарукан исемле шәһәре дә булган [Ахинжанов: 1989. С. 133–135.]. Безнең карашыбызча, «саз»/«шар» тамырыннан ясалган әлеге сүзләрнең этимологиясе сак диалектларында «елан» мәгънәсен белдергән sazda, sausda сүзләренә барып тоташа булса кирәк [Восточный Туркестан: 1992. С. 76.].

Яңа тикшеренүләр күрсәткәнчә, сазаган образы хәтта борынгы болгарларның һәм кыпчак-кимакларның күмү йолаларында да яклаучы-саклаучы мифик зат буларак катнашкан. Бу очракта мин, барыннан да элек, Дунай буе Болгар дәүләтенең беренче башкаласы Плиска янында Аспарух (VII йөз) каберлегендә табылган сазаган сурәтен күздә тотам [Салихова: 1990. № 9. С. 32–33.]. Кубрат хан династиясенең тамга-мөһере булып исәпләнүче җиз тәңкәгә ясалган әлеге мифологик образ, безнең уебызча, хан каберенә йола таләп иткән өчен генә түгел, ә теге дөньяда хуҗасын яклау һәм саклау өчен дә күмелгән булырга тиеш.

Икенче мисал IX йөздә Көнбатыш Себердә барлыкка килгән кимаклар дәүләте территориясендә – Иртыш буенда ачылган Зевакин каберлеге белән бәйле. Безнең темага кагыла торганы – байбикә хатын күмелгән әлеге каберлектә табылган рун язмалы бронза көзге (рун – төрки бабаларыбызның борынгы шрифт-язу төре). Утыз хәрефтән торган бу ике юллык төркичә язманы археолог Ф.Арсланова белән тюрколог С. Кляшторный, текстта күрсәтелмәгән сузык авазларны үзләре фараз иткәнчә ачыклап, болай укыганнар: isi k$^{ü}$n$^{i}$s$^{i}$n s$^{ä}$s$^{ä}$r guty b$^{ä}$s$^{ä}$r (беренче юл); j$^{ä}$bči j$^{ä}$gr$^{ä}$n sn (?) lü (икенче юл). Аларча тәрҗемәсе: «Знатная женщина освобождается от своего [чувства] зависти (гнева). Ее счастливый удел (ее благость) наступает». «Ябчи – рыжий (вар. огненно (ярко)-красный) ... дракон» [Арсланова, Кляшторный: 1973. С. 306–315.].

Мин бу укылыш һәм әлеге тәрҗемә белән килешмәдем, текстны тартмый-сузмыйча, башка сузыклар белән үземчә укыдым. Түбәндәге гыйбарә һәм мондый кызыклы мәгънә килеп чыкты. Беренче юл: iši k$^{ü}$n$^{ä}$šn s$^{e}$š$^{ä}$r quty b$^{o}$š$^{a}$r; икенче юл: jbči j$^{a}$ġ$^{ï}$n s$^{e}$ņ lü. Тәрҗемәсе: «Байбикә кояшыннан аерыла, рухы (җаны) ташлап китә»; икенче юл: «Якла (каплачы) дошманнан, изге лү (сазаган)». Аңлатма рәвешендә өстик: борынгы төркиләрдә «кояшыннан аерылу», «кояшы сүнү», «кояшы бату» кебек гыйбарәләр үлү, вафат булу мәгънәсен белдергән. Мәсәлән, Мәхмүд Кашгарида ölük

bilä qošuldy, toǧmyš kÿni uš batar – ʾүлек(ләр)(/мәетләр) белән кушылды, туган (чыккан) кояшы инде батаʾ (МК, II, 146); якутларда: кунім сан буолла – «кояшым сүнде» (үлгәндә бәхилләшү формуласы). Бронза көзгедә без «jар-/jав» (йап) дип укыган сүзнең, «ябу»дан тыш, каплау, саклау дигән мәгънәләре дә булган: er qalqan japïndï – ’ир калкан белән капланды’ (~сакланды) (МК, III, 82). Безнеңчә, борынгы төркиләрдә баш хөкемдарның титулы булган «йабгу» сүзе дә шушы ук тамырдан ясалган булырга тиеш – саклаучы, яклаучы мәгънәсендә. Ә инде борынгы төрки телдә һәм текстта кулланылган лү (вар. ләү) сүзе исә кытайларның изгеләштерелгән елан-аждаһаны белдерүче «луң» сүзеннән үзгәртеп алынган.

Мисаллардан аңлашылганча, сазаган образы, димәк, һуннардагы кебек үк, кыпчак-кимакларда да яклаучы-саклаучы буларак хәтта теге дөньяга озата барган булып чыга. Безнең бу нәтиҗәбез Себердә атаклы Аржан курганын казыганда бер төрки кабереннән рун хәрефләре белән «lü» дип язылган бронза аел табылуы белән дәраслана [Кляшторный: 1975. С. 184.]. Каеш аелындагы бу сүзнең лү-сазаганның яклавына һәм саклавына исәп итеп язылганлыгы шиксез.

Борынгы төркиләрдә изгеләштерелгән ләү-сазаган образлары мифологик ышанулар, легендалар даирәсендә генә торып калмаган, ә борынгы төркиләрнең төрле сәнгать төрләренә, шаман догаларына һәм героик эпос-дастаннарына да үтеп кергән. Мәсәлән, кыргызларның атаклы «Манас» дастаны баштан алып ахырга кадәр елан – «айдагар» культы белән сугарылган (төрки телләрдәге айдагар, ажыдар, аждарһа, аждаһа – иранннарның өч башлы елан-баскак патша Ажи-Дахака исеме нигезендә ясалган сүзләр). «Бер башлы җитмеш колачлы айдагар» ул әсәрдә төрки-кыргызларны яклаучы буларак хәтта яуда катнаша [Манас: 1958. 368 б.; Манас: 1946. С. 372.]. Шулай ук кыргызлар, казакълар һәм Себер татарлары арасында билгеле булган «Йиртөшлек» дастанында да геройга теләктәшлек итүче елан-аждаһалар патшасы Ак елан образы тасвирлана. (Каюм Насыйри сүзләрен исегезгә төшерегез: «Барлык еланнар кара төстә булып, еланнар патшасы ак була. Ак елан татарны яклый, ярата, алдан хәбәр биреп, төрле файдалар китерә») [Насыйри: 1975. Т. 2. 46 б.]. Себер-Алтай шаманнарының чакыру догаларында да «алтмыш колачлы ажыдаар» шаманның ярдәмчесе-булышчысы итеп сурәтләнә. Янә килеп, борынгы «Угыз-наме» дастанының Стамбулда Топкапу китапханәсендә саклланучы күпләргә билгесез версиясендә дә үзенең сихри-магик куәте белән яхшы һәм гаепсез кешеләрне бәла-казалардан һәм гарип-горабалыктан коткаручы-савыктыручы (ә явыз һәм гөнаһлы-гаепле кешеләрне ашаучы) изге елан-сазаган тасвирлана [Фазлаллах: 1987. С. 19, 83–84.]. Әгәр боларга янә Идел буе Болгар дәүләте биләмәләрендә табылган ка-

натлы елан-сазаган сурәте төшкән мөһерләрне, бакыр акчаларны, алтын йөзекләрне [Шпилевский: 1877. С. 281.] һәм бил каешына тегелгән шундый ук сурәтле тәңкәләрне дә китереп кушсаң, әлеге мифик образ культының элек никадәр нык таралган булуы тагын да тулырак төс ала. Һәм шушы ук гамәли сәнгать ядкәрләреннән болгарларның бу образны ни өчен изгеләштергәнлекләрен, нинди максатта кулланганлыкларын да чамаларга була.

Инде Алабугадагы «Шайтан каласы»на бәйләнешле елан-сазаган образына әйләнеп кайтыйк. Сүз барган легендаларда әлеге илаһи-мифик көч тә үзенә табынучыларга карата ярдәмчел-булышучы зат итеп тасвирлана. Тирә-яктан аңа төрле үтенеч-сораулар белән туктаусыз кеше агылып тора, хәтта әсирләр исәбеннән аңа корбаннар да китерәләр. Канатлы елан-сазаган аларга сихри-илаһи көче белән ярдәм итә: чир-авырулардан котылдыра, Кама елгасы кискен борылыш ясаган куркыныч-бусагалы урыннан көймә-корабларын исән-имин үткәреп җибәрә, күрәзәлек итеп, киләчәк язмышларының нинди булачагы турында җаваплар бирә. Үзе белән исәпләшмәүчеләрне һәм ризалатмыйча үтеп китәргә теләүчеләрне исә һәлак итә, көймәләрен капландыра [Казанская история: 1954. С. 91–92.]. Иң мөһиме – болгар мифологиясендә һәм аңа барып тоташучы татар хикәятләрендә елан-сазаган Болгар дәүләтенең һәм соңрак Казан ханлыгының чикләрен саклаучы һәм яклаучы көч булып күз алдына баса [Заринский: 1880. С. 73–74; Халиков: 1976. С. 13–14 б.].

Менә монда инде без сазаган образының тагын бер функциясенә – дәүләт иминлеген, чик буйларын саклау вазыйфасына барып чыгабыз. Заманында канатлы елан образының чик буйларын саклау функциясенә күренекле фольклорчы В. Я. Пропп игътибар иткән булган [Пропп: 1986. С. 219.]. Археолог А. Х. Халиков үзенең хезмәтендә «Шайтан каласы»ндагы сазаганга менә шул сыйфатның да хас булуына басым ясый. Һәм шунысы характерлы: ил чиген саклаучы әлеге мифологик образ традицион ышану, дәвамлылык рәвешендә Болгар чорыннан Казан ханлыгы дәверенә дә күчә. Аерым алганда, «Казанская история»дә теркәлгән һәм Н. П. Рычков, Ф. Эрдман язып алган легендаларда Болгар дәүләтенең «мәлиге»/«илтәбәр»е дә, шулай ук Казан ханлыгының ханы да (бер легендада әлеге идарәче Сөембикә итеп бирелә) монголлар яки руслар яу белән килер алдыннан: «Кем җиңәчәк – монголлармы (соңрак варианты: руслармы), әллә безме?» – дип сорарга Алабугадагы елан-сазаган янына үзләренең вәзирләрен җибәрәләр. Һәр ике очракта да әлеге елан: «Минем инде сезне сакларга көчем бетте, бу җирләр басып алучылар кулына калачак», – дип җавап бирә һәм, һавага күтәрелеп, юкка чыга.

«Казанская история»дәге легендада янә бер мәгълүмат игътибарны җәлеп итә. Ачыклап әйткәндә, анда «Шайтан каласы»нда яшәүче елан-сазаган руслар килер алдыннан мәҗүси таш гыйбадәтханәдән түгел, ә мәчеттән очып чыгып киткән итеп тасвирлана. Безгә шулай ук исеме билгесез урта гасыр рәссамының әлеге фактны Казан яулап алынуга бәйләп ясаган рәсеме дә билгеле. Белүебезчә, анда да мәчеттән очып чыгып китүче канатлы елан сурәте төшерелгән. Бу мисалларны кайбер галимнәр гадәттә бабаларыбыз тоткан ислам динен мыскыллау өчен руслар уйлап чыгарган ялган итеп карыйлар. Әмма, әгәр елан-сазаганны мәчет белән бәйләп күрсәтү, чыннан да, мыскыллау һәм ялган икән, ул чагында Төрекмәнстанның башкаласы Ашхабадтагы атаклы Анау мәчете (XIV йөз) порталының як-ягына канатлы ике сары елан-сазаган сурәте ясалган булуын ничек аңлатырга?! [БСЭ. Т. 1. С. 578; Пугаченкова: 1959. С. 58.]. Я булмаса Кытайдагы мәчетләрнең стеналарына төшерелгән канатлы елан сурәтләренә ничек карарга?! [Решетов: 1981. С. 87.]. Үзеннән-үзе соралып торган җавап бер: мәҗүси ышанулар калдыгы булган һәм безнең көннәргә килеп җиткән әлеге образлар элек-электән үк аерым объектларны, шул исәптән дини храмны-мәчетне саклаучы, мифологик зат итеп тә күзалланганнар. Моннан тыш, этнографларның һәм архитекторларның ачыклавынча, Татарстан территориясендә тәрәзә өслекләренә агачтан кырып өй саклаучы елан-сазаган сурәтләре эшләү традициясенең яшәп килгәнлеге дә билгеле [Бусыгин, Зорин, Токсубаева: 1986. С. 82–83.]. Бу, әлбәттә, Болгар чорыннан ук башлангыч ала торган традициянең дәвамы.

«Шайтан каласы»ндагы елан-сазаганның заманында нәкъ менә мәчетне һәм үзе яшәгән тирәлекне саклаучы итеп күз алдына китерелгәнлеге турындагы караш А. Халиковның археологик тикшеренүләре белән дә раслана. Ул «Шайтан каласы»ндагы борынгы бина нигезенең кыйбла ягына яраштырып төзелгән булуын һәм шунда ук михраб эзе дә саклануын ачыклап, әлеге корылма элек, чыннан да, мәчет булган, шул ук вакытта ул Болгар дәүләте чиген саклаучы кальга-ныгытма вазыйфасын да үтәгән дигән нәтиҗәгә килде [Халиков, Шарифуллин: 1979. С. 27–28; Халиков: 1997. С. 32.]. Бу нәтиҗә көньяк гарәп илләрендә элек берьюлы мәчет тә, кальга да булып хезмәт иткән корылмалар салыну традициясе булганлыгы белән дә туры килә һәм раслана.

Борынгы Урта Идел-Кама буе легендаларында елан-сазаган образының әнә шулай дәүләт һәм дин иминлегенә бәйләп сурәтләнүе уңае белән монда урынлы нәтиҗә соралып тора: безнең бабаларыбыз болгарлар һәм кимак-кыпчаклар, димәк, үзләренең яклаучысы һәм саклаучысы итеп гади җанварны түгел, ә борынгы ышануларыннан килә торган иң куәтле һәм

дәһшәтле итеп күз алдына китерелүче мифологик затны сайлаганнар. Илаһи һәм һәлакәтле куәткә ия булган әлеге образ аларның дошманнарында, сугышып яшәгән күршеләрендә һәм, гомумән, явыз ниятле рухларда яки каршы көчләрдә курку-өркү тойгысы тудырырга тиеш булган. Елан-сазаганның ачуыннан һәм зыян китерүеннән хәтта бабаларыбыз үзләре дә курка, шикләнә торган булганнар һәм табыну, корбан бирү исәбенә аның күңелен табарга, ризалатырга һәм үзләренә хезмәт иттерергә тырышканнар. Болгар-кыпчак һәм соңрак өлешчә татар мифологиясендә канатлы елан-сазаганның аерым объектларны, кеше аягы басмаган җирләрне һәм чик буйларын саклаучы илаһи көч булып чыгыш ясавы һәм дә Болгар дәүләте илә Казан ханлыгының этник тамга һәм герб рәвешендәге билгеләре булып китүе [Валеев: 1975. С. 101.] менә шуның белән аңлатыла да.

Янә килеп, заманында елан-сазаган сурәтләре төшерелгән һәм шамаил кебек гарәп хәрефләре белән чигеп-нәкышләп язылган ефәк-тукыма байраклар, шулай ук уртасына канатлы елан уелган бакыр һәм тимер штандарт-флаглар булганлыгы да, һичшиксез, әлеге образның дәһшәтле һәм куркытучы-саклаучы табигате белән бәйләнгән. Мондый байраклар, флаглар турындагы мәгълүматларга без Мәскәү Кремлендәге кораллар палатасының һәм Россия кораллар музееның элекке архив материаллары исемлеге белән танышканда юлыктык [Опись: 1884. Ч. III. Кн. I. С. 130.]. Күңелдә табигый рәвештә «Болар Казан ханлыгының А. Курбский язмасында телгә алынган трофей-ганимәт «патша байраклары» түгел микән?» дигән сорау туды. Үзенең истәлек-мемуарларында Курбский Казан байлыгын талаулары турында менә ничек язып калдырган бит: «И приказал (Государь) воеводам во граде огни гасити, и многие сокровища казанские велел всему воинству имети. На себя же Государь велел имети ...царя Едигерь Магмета и знамена царские, да пушки» [Курбский: 1902. С. 104.]. Аерым чыганакларга караганда, сазаган сурәте төшерелгән байраклар үз заманында хазарларда һәм Анатолияны яулап алган сәлҗүкләрдә дә булган. Кем белә, архив материаллары исемлегендә күрсәтелгән һәм бабаларыбыздан калуы ихтимал булган андый байраклар бәлки бүген дә Мәскәүдәге алда телгә алынган музейларның саклагыч подвалларында беркемне дә кызыксындырмыйча ята торганнардыр...

Бу урында төрки халыкларның хәтта ислам диненә күчкәннән соң да традицион мәҗүси ышануларыннан тәмам баш тарту юлына басмауларын, ә кушма-синкретик төстә дәвам итүләрен угызлар мисалында да анализлап китү кызыклы. Билгеле булуынча, Сыр-дәрья буйларында һәм Каспий диңгезеннән төньяк-көнчыгышта яшәгән угызларның бер өлеше VIII йөздә үк ислам динен кабул итә. 1040 елда Сыр-дәрья угызлары мөселман ыруы-династиясе сәлҗүкләр җитәкчелегендә Төрекмәнстан

(элекке Төрекманстан ССР) җирләрен яулап ала, ә сәлҗүкләр гаскәрендә хәрби җитәкчеләр булып хезмәт итүче Артуклар «йортының» кабилә тотемы һәм нәсел гербы сазаган була [Пугаченкова: 1959. С. 46.]. 1071 елда сәлҗүкләр Кече Азиягә үтеп керәләр һәм Византия императоры Роман IV нең армиясен тар-мар итәләр. Безнең өчен иң игътибарга лаеклысы – алар үзләре белән бергә Византия территориясенә сазаган культын да алып киләләр [Гордлевский: 1947. Вып. 4. С. 326–337.]. XII йөздә инде Диярбакер каласының Алеп капкасы түбәсендә сазаган сурәте пәйда була, дөресрәге, 1183 елда язмада андый сын-сурәт булганлыгы теркәлә [Гордлевский: 1960. Т. 1 С. 164.]. (Бер уңайдан, Ашхабад янындагы Анау мәчетенең порталына-алгы өлешенә угыз-төрекмәннәр тарафыннан ясалган канатлы сазаган сурәтләрен дә кабат искә төшерик). Госманлы төрекләре арасында саклланган Ахи Эврен (эврен – зур елан) турындагы борынгы легендада да геройның исеменнән һәм әсәрнең эчтәлегеннән елан-сазаган культы беленеп тора һәм хәтта (кызыкның да кызыгы!) сазаганга тиңләштерелүче каһарман Эврен Мөхәммәд пәйгамбәрнең көрәшчесе итеп бирелә. Аерым алганда, легендада герой болай тасвирлана: «В одной руке держал он знамя, подаренное пророком Мухамедом, а в другой меч и поражал врагов, как дракон» [Гордлевский: 1960. Т. 1. С. 203.]. (Сүз уңаенда татар дастаны «Идегәй»дән дә бер тәңгәл мисал китерик: «Шаң-шаң иткән шам кылыч – Идегәйнең кылычы... Аждаһадай сулаган ул кылычның сулышы») [Идегәй: 1988. 153 б.]. Моннан тыш, сәлҗүкләрнең аерым байракларында сазаган сурәте булуы һәм төрекләрнең элек басу-кырларны саклаучы елан («тарла-бекчиси») образын изгеләштергәнлекләре дә [Мифы народов мира: 1987. Т. I. С. 449.] угызларда елан-сазаган культының, болгарларда һәм кыпчаклардагы кебек үк, заманында шактый нык таралганлыгы һәм хәтта этнос һәм этнокультура билгесе буларак кулланылганы турында сөйли.

Һинд-европа халыкларына, шул исәптән руслар-славяннарга килгәндә исә, алар, киресенчә, тарихта билгеле була башлаган чорларыннан ук елан-сазаганга һәм үзләре җирлегендә туган аждаһага дошман мөнәсәбәттә булганнар [История Европы: 1999. Т. 1. С. 109; Миллер: 1876. Т. 1. С. 161.]. Алай гына да түгел, моннан берничә мең ел элек үк инде аларда елан-аждаһага каршы көрәшүче алла образы (соңрак алмашчысы – изге патша һәм мифоэпик герой) барлыкка килгән. Ул һинд-европалыларга бәйләнешле барлык этник культураларда да түбәндә, җир-суда яшәүче елан-аждаһаны утлы уклары яки утлы ташлар белән ээзәрлекләүче, аңа каршы көрәшүче яшен алласы итеп күзалланган [Мифы народов мира: 1987. Т. 1. С. 529–530.]. Күпчелек Европа халыклары тота торган христиан динендәге «Сатана» / «Дьявол» да, Библиядә тасвирланганча, коточ-

кыч елан-аждаһа итеп күз алдына китерелгән [Толковая Библия: 1904–1907. С. 24–27; Мифы народов мира: 1987. Т. 2. С. 159.].

Һинд-европалылар һәм славяннар-руслар антихрист-дәһриләрне, мифик кара көчләрне генә түгел, ә үзләренең реаль дошманнарын, шул исәптән күчмә яки утрак тормыш белән яшәүче борынгы төрки кабиләләрне һәм татарларны да, елан-аждаһа белән тиңләштергәннәр [Рыбаков: 1987. С. 544–545.]. Моңа, билгеле, аталган халыкларның елан-сазаганны изгеләштерүләре дә сәбәп булгандыр. Мәсәлән, Владимир Мономах XII йөз башында кат-кат яу белән килеп Дон буе кыпчакларын кыйраткач, «бог избавил нас от врагов наших и сокрушил им головы змеиные», дип белдергән [Полное собрание русских летописей: 1841. Т. 1. С. 279.]. Русларның «Казан елъязмасы»нда исә татар ханлыгының, бабаларыбызның мәркәзе булган Казан, «гнездо змиево» – дип исемләнә [Адрианова-Перетц: 1947. С. 94.] һәм, Казанга килгәч, шушы ук атаманы татарларга карата Петр Беренче дә куллана. Хәтта үзләренең союздашы булган Касыйм ханы Ибраһимны да руслар үзләренең бер риваятендә «Змий Горыныч» дигән кушамат белән атыйлар [Адоньева: 1989. С. 104.].

Белүебезчә, татар легенда-риваятьләре арасында Казанның еланлы урынга һәм Елан-тауга салынуы, моның өчен ул җирләрнең башта яндырылуы, еланнардан чистартылуы турындагылары да бар. Шуларның берсе 1774 елда сәяхәтче И. Г. Георги соравы буенча борынгы татар кулъязмасыннан тәрҗемә иттерелеп немец телендә теркәлгән, икенче шуңа охшаган риваять исә Сәид Вахитов тарафыннан Татарстанның Спасс кантонында язып алынган [Татар халык иҗаты: 1987. 50–53, 302–303 б.]. Платон Заринский әлеге еланнарның патшасы ике башлы «аждаһа» да үзе яшәгән төбәкне (бу очракта «кеше аягы басмаган искиткеч гүзәл» Кабан буйларын) саклаучы мифик зат итеп күзалланган дип карый һәм, янгында исән калгач, шәһәр коручылардан үз оясын туздырганнары, рәнҗеткәннәре өчен үч ала башлаган дип исәпли [Заринский: 1870. С. 83–84]. Әмма миңа калса, әлеге легендаларны реаль чынбарлык белән бәйләргә дә нигез бар. Аерым фактлардан аңлашылуынча, яңа җирләрне үзләштергәндә элек кешегә күп еланлы урыннарга да килеп төпләнергә һәм еланнарны төрле юллар белән юк итәргә туры килгән. Һичшиксез, бабаларыбыз килеп утырган Елан-тау һәм Кабан буйлары да шундый урыннарның берсе булган булса кирәк.

П. С. Паллас та үзенең юлъязмаларында Иртыш белән Обь елгалары арасында «Елан-тау» дип атала торган тау булуы турында яза һәм аның ни өчен шулай аталуының сәбәбен болай аңлата: «Сия гора получила название свое от множества змеев, которые здесь находили как прежде, так и первые годы построения заводов» [Паллас: 1786. Ч. II. Кн. II. С. 330.]. Казан корыла

башлаган җирнең дә еланнар кайнашып торган таулы һәм урман-суга бай урын булуы халык фантазиясендә аның нәкъ менә аждаһа саклаган серле төбәк итеп күзаллануына китергән булса кирәк. Ләкин легендаларда Казан халкының котын алып торучы әлеге җыелма образ борынгы болгарлар һәм кыпчаклар изгеләштергән сазаган кебек бер башлы итеп түгел, ә тискәре, явыз елан-аждаһа сыман ике башлы итеп тасвирлана. Ричард Фрейның һәм А.Х. Халиковның бик дөрес ачыклавынча, мондый төр аждаһа һәм аңа каршы көрәш сюжеты төрки халыкларга һәм татарларга иран телле халыклардан кергән [Халиков: 1976. С. 17–18.]. Шулай ук безнең әкиятләрдә каһарманның корбан таләп итүче күп башлы явыз аждаһаны үтереп патша кызын коткаруы турындагы сюжетны да (сюжетлар типологиясе буенча АТ 301 мотивы), һичшиксез, һинд-европа халыкларының, бигрәк тә иранлыларның йогынтысы нәтиҗәсе итеп карарга кирәк.

Күп башлы аждаһа турында сүз чыккач, монда елан-сазаган образына бәйләнешле янә бер мөһим аерманы күрсәтергә кирәк. Тарихи мәгълүматларга караганда, һуннар, борынгы төркиләр һәм болгар-кыпчаклар изгеләштергән бер башлы елан-сазаган/ләү образы һинд-европалылар, ираннар аша кергән күп башлы аждаһадан тышкы кыяфәте белән дә шактый аерылган. Безнең бабаларыбыз мифологиясендә һәм гамәли-кулланма сәнгатендә әлеге илаһи образ кош яки бүрегә охшаган бер башлы һәм кош кебек канатлы, боҗра рәвешендә бөгәрләнеп-уралып торган гәүдәле һәм балыкныкы кебек икегә аерылып яки чукланып тора торган койрыклы гибрид зат итеп күз алдына китерелгән, димәк, өч тирәлектә: күктә, җирдә һәм суда яши ала торган тереклек иясе итеп күзалланган. Шул ук вакытта сазаганның канатлы зур ак елан (варианты – сары елан) рәвешендә фараз ителгәне дә булган. Монда, билгеле, рус һәм сарай геральдистлары татарны һәм аның ата-бабалардан килгән тарихи символикасын мыскыл итеп ясаган әтәч, каз һәм личинка-суалчан кыяфәтле мәхлүк «аждаһалар» керми. Әтәч кыяфәтле һәм елан койрыклы «аждаһа» образында, мәсәлән, әтәч салган йомыркадан яралган дип фараз ителүче һәм үзенең ачуы, хәтта карашы, сулышы белән бар нәрсәгә һәлакәт, үлем китерүче Василиск дигән коточкыч явыз елан күздә тотылган [Большой энциклопедический словарь: 1998. С. 116.].

Ахыр килеп, тагын бер мөһим искәрмә: изгеләштерелгән бер башлы елан-сазаганнан аермалы буларак, күп башлы явыз елан затын, бабаларыбыз «сазаган», «ак елан» яки кытайлардан кергән алынма сүз белән «ләү» дип түгел, ә иараннардан кергән һәм күбесенчә кире мәгънә белдергән атама белән «аждаһа» дип йөрткәннәр. Һәм кайбер очракларда (мәсәлән, кыргызларда һәм казакъларда) хәтта уңай образ булган канатлы һәм бер башлы елан-сазаганны «айдагар», «аджидаар» дип атаган тәкъ-

дирдә дә, бабаларыбыз аны һинд-европалылар, ираннар йогынтысы аша килгән күп башлы дошман аждаһа белән бутамаганнар. Бу инде канатлы елан образлары, бигрәк тә аларның аталышы иран тәэсирендә күпмедер дәрәҗәдә каршылыклы төс алуына карамастан, төркиләр, шул исәптән кыпчак тел семьялыгына керүче халыклар һәм татарлар хәтерендә яклаучы һәм саклаучы елан-сазаган образы барыбер сакланып калган дигән сүз.

Ләкин йогынты, һичшиксез, ике яклы булган. Аерым алганда, русларга болгарлар һәм кыпчаклар йогынтысы аша, шулай ук Казан ханлыгы юк ителгәндә кулларына төшкән трофей-ганимәтләр сыйфатында елан-сазаганга бәйләнешле сәнгать ядкәрләре, төрле мифологик образлар һәм мотивлар үтеп кергән. Тарихчы В.Н. Татищев борынгы елъязмаларга таянып, 1219–1230 елларда Владимир-Суздаль кенәзлегендә ак ташлардан салынган Георгий храмының авторы-архитекторы турында мондый мәгълүмат китерә: «Князь Святослав церковь построил новую, вельми дивную резаным камнем; мастер был болгарский» [Татищев: 1877. Т.3. С.226.]. Б.А. Рыбаковның тикшереп ачыклавынча, бу оста храмның таштан кырып эшләнгән рәсем-бизәкләренә Идел болгарларының мәҗүси ышануларын һәм мифологик образларын да кертеп җибәргән икән. Томшыгына «шарик», дөресрәге бер чеметем җир капкан үрдәк образын галим шуларның бер үрнәге итеп карый [Рыбаков: 1987. С.629]. Утызынчы елларда храм диварлары архитектурасын өйрәнү белән шөгыльләнгән Австрия галиме Ф. Халле Идел-Кама болгарларының мифология элементларын 1194–1197 елларда Владимирда төзелгән Дмитрий соборы бизәкләрендә һәм кабарынкы-рельефлы итеп эшләнгән аерым хайван сурәтләрендә дә күрә [Вагнер: 1969. С.27–28.]. Ләкин сүз бара торган Георгий һәм Дмитрий соборлары фасадындагы һәм диварларындагы барс, бүре һәм башка образларны эченә алучы сурәтләр-бизәкләр арасында әлеге галимнәрнең игътибарыннан читтә калган сазаган образлары да бар. Без рус-славяннар өчен чит, дошман булган әлеге образларны да болгардан килгән дип исәплибез. Бу инде, димәк, болгарлар ата-бабаларыннан ук дәвам итүче елан-сазаган сынын, башка образлары белән бергә, үзләренең кул тамгалары һәм этник мөһерләре рәвешендә рус храмнары диварларына да уеп калдырганнар дигән сүз.

*(Дәвамы бар)*

**Әдәбият**

1. Аджи Мурад. Полынь половецкого поля. – М.: ТОД «Пик-контакт», 1994.

2. Адоньева С.Б. Особенности структуры и семантики змееборческого сюжета в фольклоре и письменной традиции // Русский фольклор. – Л.: Наука, 1989.
3. Адрианова-Перетц В.П. Очерки поэтического стиля древней Руси. – М.-Л., Изд. АН СССР, 1947.
4. Арсланова Ф.Х., Кляшторный С.Г. Руническая надпись на зеркале из верхнего Прииртышья // Тюркологический сборник. – 1972. – М.: Наука, 1973.
5. Большой энциклопедический словарь. Мифология. – М.: Большая Российская энциклопедия, 1998.
6. БСЭ. Т. 1. – Москва. 1970.
7. Бусыгин Е.П., Зорин Н.В., Токсубаева Л.С. Декоративное оформление сельского жилища в казанском Поволжье. – Казань: Тат. кн. изд., 1986.
8. Вагнер Г.К. Скульптура Древней Руси. Москва: Искусство, 1969.
9. Валеев Ф.Х. Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. – Йошкар-Ола: Мар. кн. изд., 1975.
10. Восточный Туркестан в древности и раннем Средневековыье – М.: Наука, 1992.
11. Гадло А.В. Этническая история Северного Кавказа IV–X вв. – Л.: Изд. ЛГУ, 1979.
12. Гордлевский В.А. Что такое «босый волк»? // Известия АН СССР. Отд. лит-ры и языка. – М., 1947. – Вып. 4.
13. Гордлевский В.А. Избранные сочинения. – М.: Изд. вост. лит-ры, 1960. – Т. 1.
14. Заринский Платон. Сборник исторических и археологических исследований о Казанском крае. – Казань, 1880.
15. Идегәй. Казан: Тат. кит. нәшр., 1988.
16. История Европы. – М.: Наука, 1999. – Т. 1.
17. Каланкатуци Мовсэс. История страны Алуанк. – Ереван: Изд. АН Арм. ССР, 1984.
18. Казанская история. Историческая повесть XV в. – М.-Л.: Изд. АН СССР, 1954.
19. Кляшторный С.Г. Рунические надписи из Кургана Аржан II // Первобытная археология Сибири. – Л.: Наука, 1975.
20. Курбский А.М. Сказание о покорении Казани. – М., 1902.
21. Манас. Киргизский героический эпос. Великий поход. – М.: Гос. изд. художест. лит-ры, 1946.
22. Манас. Фрунзе: Гилем, 1958.

23. Мелиоранский С. П. Об орхонских и енисейских надгробных памятниках с надписями // Журнал министерства народного просвещения. – СПб., 1898. – Ч. 317.
24. Миллер В. Ф. Очерки в связи с древнейшей культурой. – М., 1876. – Т. 1.
25. Мифы народов мира. Энциклопедия. – М.: Советская энциклопедия, 1987. – Т. I.
26. Мифы народов мира. Энциклопедия. – М.: Советская энциклопедия, 1987. – Т. 2.
27. Насыйри Каюм. Сайланма әсәрләр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1975. – Т. 2.
28. Опись Московской оружейной палаты. Знамени, прапоры, значки, флаги и штандарты. – Спб., 1884. – Ч. III. Кн. I.
29. Паллас П. С. Путешествие по разным местам Российского государства. – Спб., 1786. – Ч. II. Кн. II.
30. Полное собрание русских летописей. – Спб., 1841. – Т. 1.
31. Пропп В. Я. Исторические корни волшебной сказки. – Л.: Изд. ЛГУ, 1986.
32. Пугаченкова Г. А. Мечет Анау. – Ашхабад, 1959.
33. Решетов А. М. Дракон в культурной традиции китайцев // Материальная культура и мифология. – Л.: Наука, 1981.
34. Руденко С. И. Культура хуннов и Ноинулинские курганы. – М., Изд. АН СССР, 1962.
35. Рыбаков Б. А. Язычество древней Руси. – М.: Наука, 1987.
36. Рычков П. П. Опыт Казанской истории древнейших и средних времен. – Спб., 1767.
37. Рычков Н. П. Журнал и дневные записки путешествия по разным провинциям Российского государства 1769 и 1770 годов. – Спб., 1870. – Ч. I.
38. Салихова Фирдаус. Родословная дракона // Идель. – Казань, 1990. – № 9.
39. Соколова В. К. Русские исторические предания. – М.: Наука, 1971.
40. Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Төзүчесе С. М. Гыйләҗетдинов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1987.
41. Татищев В. Н. История Российская. – Спб., 1877. – Т. 3.
42. Толковая Библия. – Пб., 1904–1907.
43. Толстова Л. С. Исторические предания Южного Приуралья. – М.: Наука, 1984.
44. Усманов М. А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. – Казань: Изд. КГУ, 1972.

45. Фазлаллах Рашид ад-дин. Огуз-наме. – Баку: Элм, 1987.
46. Халиков А.Х. О времени, месте возникновения и названии города Казани // Из истории культуры и быта татарского народа и его предков. – Казань: Тат. гос. изд., 1976.
47. Халиков А.Х., Шарифуллин Р.Ф. Исследование комплекса мечети // Новое в археологии Поволжья. – Казань, 1979.
48. Халиков А.Х. Алабуга – Елабуга. – Елабуга, 1997.
49. Шпилевский С.М. Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губерне. – Казань, 1877.

***Р.Ф. Гатауллин***

## СУЩНОСТЬ И ГРАНИЦЫ ЭТНОПРОСТРАНСТВА*

Определению сущности этнопространства наиболее близкое понятие – территориальная организация населения (ТОН) – «это сочетание функционирующих территориальных структур населения, производства, природопользования, объединяемых структурами управления; совокупность процессов или действий по размещению населения и производства, природопользованию с учетом их отношений, связей, соподчиненности и взаимозависимости с целью ускорения социально-экономических территориальных общностей» [Цуканова: 2008.].

В качестве территориальной общности населения можно рассматривать и определенное национальное сообщество, проживающее в ее пределах. В этом случае можно говорить о территориальной организации татар, башкир, чувашей, русских и других наций. Такой показатель, как доля татар, проживающих в пределах Республики Татарстан, безусловно, характеризует территориальную организацию нации. Далее можно говорить о доле татар, проживающих в Башкортостане, Оренбургской области и т.д.

Эти показатели, к сожалению, не дают качественную характеристику какой-либо территории как пространства для развития нации. Для этого мы предлагаем использовать категорию этнопространства, под которым нами понимается определенная территория, где происходит процесс развития этнонаций, согласование их интересов и формируются общие для всех представителей этноса конкретные условия для социально-культурного развития.

В.И. Ленин одним из признаков нации считал общность территории. Другими признаками признавались: общность экономики, общность языка, культуры и обычаев [Ленин: Т. 23. С. 314–315.]. В данном случае экономический и территориальный факторы как бы стали превалирующими. Поскольку экономика весьма изменчива и в своем развитии переживает взлеты, кризисы, вплоть до дефолта, получается производное от нее понятие этноса также не может быть устойчивым явлением.

Люди одной нации живут в разных странах, меняют места жительства, при этом следует признать, что они, территориально перемещаясь, как бы могут временно выйти из состава нации и войти в её состав. Получается: русские в России – это нация, а русские во Франции представляются не совсем русскими. Также татары, живущие в Татарстане – это

---

* В рамках научной темы ИСЭИ УФИЦ РАН.

нация, а татары Башкортостана не обладают всеми признаками татарской нации (территориальная и экономическая общность), т.е. их принадлежность к нации в этом случае как бы остается под вопросом. Это касается и русских, проживающих в Казахстане, Украине и т.д.

Представляется, что места проживания татар, русских, чувашей и других народов в зависимости от административного устройства страны получают неравнозначный статус.

Данное противоречие может быть решено путем сселения народов в резервации, как это произошло в отношении к индейцам в США или в ЮАР при апартеиде. Возможен вариант создания автономных территориальных образований различного ранга, границы которых как бы отражают расселение данной нации. Так, в 1920-е гг.наряду с Башкирской АССР существовал Аргаяшский национальной округ. До последнего времени наряду с Бурятской АССР имелись Агинский Бурятский и Усть-Ордынский Бурятский автономные округа. В КНР для национальных меньшинств созданы автономные районы, префектуры, уезды и волости – вся эта чересполосица была направлена на обеспечение концентрации в автономных территориях большей части национальных меньшинств. Получается, что национальные права гарантируются, прежде всего, территориальным размежеванием. На наш взгляд, такой подход был обусловлен отсутствием демократии. В.И. Ленин в своих тезисах по национальному вопросу права наций на самоопределение прямо связывал с отсутствием демократии. Для татар и других народов, расселение которых имеет дисперсный характер, проблемы территориального обустройства и укрепления демократии в стране имеют фундаментальный характер.

С категорией этнопространства связано также понятие этнической территории. Существует такое определение: этническая территория – это территория преимущественного размещения данного этноса, обычно включающая ареал его формирования и компактного расселения, смешения с другими народами. Академик В.А. Тишков в энциклопедии «Народы и религии мира» дает такое же определение этнической территории, добавив, что данное понятие является крайне условным и прежде всего, привязано к сельским населенным пунктам [Тишков: 1998.].

С учетом вышеизложенного попытаемся дать общие контуры границ этнической территории татар. Это прежде всего Республика Татарстан, в Башкортстане – территории прежней Уфимской губернии, западная половина Оренбургской области, преимущественно заволжские территории Самарской, Саратовской и Волгоградской областей, Астраханская область, часть Ульяновской области, юг Пермского края. В виде анклавов выделяются земли татар-мишарей в Пензенской и Нижегородской обла-

стях. В Зауралье этническая территория сибирских татар объединяет земли Тюменской, Томской, Омской и Новосибирской областей. В качестве самостоятельных анклавов могут быть выделены татарские села в Челябинской области, Прибайкалья и т.д.

Как видно, этнические территории нами определены с учетом наличия татарских сел. При этом не учитывается политико-административный статус данных территорий.

При оценке территориальных условий для развития татарской нации более продуктивной, на наш взгляд, является предлагаемая нами категория «этнопространство». По критерию качества нами выделяются 6 типов татарского этнопространства:

1. Республика Татарстан, где существует юридическая база для защиты прав татар на развитие собственной культуры и языка, а также условия для подготовки национальных кадров по данному направлению.

2. Национальные республики Российской Федерации, такие как Республика Башкортостан, Мордовия, Чувашия, Марий Эл, Удмуртия, в которых размещены множество татарских сел, образующие зачастую обширные зоны компактного расселения татар, когда представители данной этнонации составляют существенную часть населения этих республик. При этом в некоторых республиках существует искусственное противопоставление так называемых «титульных» наций к татарам. В результате интересы татарского народа в этих республиках достаточно серьезно ущемлены.

3. Области Российской Федерации, в которых имеются значительные татарские анклавы. Это Нижегородская, Пензенская, Ульяновская, Саратовская, Астраханская, Оренбургская, Челябинская, Свердловская, Курганская, Томская, Новосибирская, Тюменская, Иркутская области, Красноярский край, в которых решение татарских проблем наименее политизировано, но наталкивается на дефицит ресурсов и отсутствие квалифицированных специалистов.

4. Города Центральной России, прежде всего Москва и Санкт-Петербург, города-новостройки Сибири и Дальнего Востока, в которых имеется значительное татарское население, которое в настоящее время не имеет необходимой инфраструктуры и близко расположенных зон компактного расселения для решения национально-культурных проблем.

5. Государства, образованные после распада СССР, в наследство получившие значительное татарское население. Не имея необходимой инфраструктуры для национально-культурного развития, многочисленное татарское население республик Средней Азии и Казахстана в настоящее время находится под угрозой ассимиляции.

6. Диаспоры в странах дальнего Зарубежья, за исключением Финляндии и далекой Австралии, кажется, не совсем ясно осознают важность создания необходимых институтов для развития национальной культуры.

Татары Афганистана и Ирана, являющиеся потомками средневековых татар, в период формирования татарской нации оказались наиболее оторванными от основной территории. Для них в настоящее время остается актуальной проблема интеграции данных этнических групп в состав татарской этнонации.

В итоге получается: единственным более или менее полноценным этнопространством для развития татарской нации является РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН.

## Литература

1. Ленин В.И. Тезисы по национальному вопросу//Полн. собр. соч. Т. 23. – С. 314–315.
2. Тишков В.А. Народы и религии мира. – М.: Большая Российская энциклопедия, 1998. – 930 с.
3. Цуканова Т.Г. Территориальная организация населения: учеб. пособие / Т.Г. Цуканова, М.Н. Мишнин. – Рязань: Акад. права и упр. Федер. службы исполнения наказаний, 2008. – 191 с.

***Ф. Ә. Бәйрәмова***

# САМАР ЯРЫМУТРАВЫНДА ТАТАР ТАРИХЫ

*(Дәвамы. Башын карагыз: № 2, 2019)*

Хәзер Жигули шәһәре урнашкан урында Моркваши авылы булган, Паллас хезмәтләрендә ул Маркуаш, дип атала. Галимнәр фикеренчә, бу торак урыны да болгар чорыннан калган, Моркваши исеме белән XVII гасырдан билгеле. «По преданиям Моркваши основаны булгарами еще в XIII в., – дип яза Емельянов. – Исторические данные подтверждают, что село Моркваши известно под этим названием с XVII в.» [Емельянов: 1938. С. 175.].

Бу беренче китабында Емельянов Самар ярымутравында «Хан овраги» булуын, анда «Хан суы» чыгуын да язып калдырган [Емельянов: 1938. С. 35.], димәк, биредә ханнар да булган, дигән сүз? Ә тирән чокыр төбендә автор өч метр озынлыктагы үсемлекләрне күргән, алар «короставник татарский» дип атала икән [Емельянов: 1938. С. 48.]. Хәер, Самар ярымутравында бик күп үсемлекләрнең татар атамасы белән бәйле булуын Лепехин һәм Паллас хезмәтләреннән дә укып белгән идек инде... Ә узган гасырлар фольклорчысы Д. Н. Садовниковның хезмәтләрендә бу тирәләрдә каракүл имәне – «каракульский дуб» үсүе, анда тере һәм үле суы (живая и мертвая вода) саклануы әйтелгән [Садовников: 1993. С. 42. Бу китап 1884 елгы нөсхәдән күчереп бастырылган]. Ә Пушкин әкиятләренә Самар ярымутравы Буян утравы буларак кереп калган, танылган рәссам Репин исә биредә булып, үзенең «Бурлаки на Волге» дигән мәшһүр картинасын ясаган... XIX гасыр башында Иделдә 300 мең бурлак черәшеп су көймәләрен өстерәгән, аларның күпчелеге татарлар булган... Бу бурлаклар Түбән Новгород белән Әстерхан арасын 75 көндә урап килә торган булганнар.

М. А. Емельяновның икенче китабы да Самар ярымутравына багышланган, ул 17 елдан соң шактый тулыландырып баслып чыккан, анда да татар тарихына кагылышлы мәгълүматлар бар. Автор әле IX гасырдан ук бөтен Самар ярымутравының тулысынча Болгар патшалыгы составында

булуын бу китабының башында ук билгеләп үтә. «В IX–XIII вв. Самарская Лука входила в Болгарское царство, что подтверждается открытием археологической экспедиции под руководством профессора В.В. Гольмстена в 1923, 1928 и 1929 гг. остатков ряда поселений, относящихся к этому периоду: на Лысой горе – у села Морквашей; на Белой горе – у с. Подгор; на горе Ош Панда Нерь – у села Шелехмети» [Емельянов: 1955. С. 3–4.].

Беренче китабыннан аермалы буларак, Емельянов монысында Муромский городок атамасының тарихын аңлатырга тырыша, аны урысларның мифик герое Илья Муромец исеме белән бәйли. «В период Болгарского царства самым крупным центральным поселением на Самарской Луке был Муромский городок, – дип яза ул. – ... Легенда, рассказываемая местным населением о том, что русский богатырь Илья Муромец в битвах уничтожил здесь целый татарский город, видимо, и послужила основанием к наименованию городка» [Емельянов: 1955. С. 4.].

Игътибар итегез – биредә сүз урыс баһадирының ТАТАР шәһәрен юк итүе турында бара, монда инде болгарлар да, монголлар да юк! Халык хәтерендә урысларның татар шәһәрен юк итүе кереп калган икән, моның нигезендә тарихи чынбарлык булуы мөмкин. Әмма соңга таба галимнәр бу легендадан Илья Муромецның татар шәһәрен юк итү тарихын төшереп калдыралар, имеш, биредә нindидер «муром» халкы яшәвен язалар. «С XVIII в. это урочище местные жители называют «Муромским городком», связывая с ним легенду о якобы жившем здесь некогда народе – муромце» [Муромский городок: 2002. С. 7.].

Тагы Емельяновның икенче китабына әйләнеп кайтыйк. Беренче китабыннан аермалы буларак, ул биредә Муромский городокка шактый киң туктала, аның Лепехин һәм Поливанов хезмәтләреннән тыш, шәһәрлек турында башка чыганаклардан да мәгълүмат алганлыгы сизелә. Ә ул чорда Муромский городок буенча яңарак мәгълүматлар 1920-нче елларда биредә археологик казу эшләре алып барган Гольмстен архивында гына булырга мөмкин. Димәк, Емельянов ул хезмәт белән таныш булган? Бүгенге көндә исә Гольмстенның Муромский городок буенча архивы юкка чыккан, дип баралар. Кемгә ышанырга?

«Площадь городка по окружности была около восьми километров, – дип дәвам итә Емельянов. – На плане он имел форму овала, длинная ось которого превышала три километра... В центре городка находилась крепость – кремль с внутренним валом. Во время своего рассвета городок имел каменные здания довольно сложной архитектуры, постройки общественного значения» [Емельянов: 1955. С. 5.]. Алга таба автор биредән нәрсәләр табылганын бик җентекләп яза, кала халкының утрак тормышта яхшы яшәүләрен хәбәр итә. Һәм, әлбәттә инде, бу бәхетле тормышны

юкка чыгаручы итеп... татар-монголларны күрсәтә. «Случилось это в 1236 году, – дип яза ул. – Огромные орды татаро-монгольских племен под предводительством внука Чингизхана Батыя двигались из Азии в Европу. На своем пути они опустошали земли, грабили и сжигали города и села. Мужчин уничтожали, женщин и детей забирали в плен. Это было страшное нашествие. Все Болгарское цартсво подверглось разорению и опустошению. После разгрома Болгарии татаро-монголы напали на Русь. Образовали в Восточной Европе так называемую Золотую Орду. Двести сорок лет длилось ненавистное татаро-монгольское иго» [Емельянов: 1955. С. 7.].

Самар ярымутравында һәм бөтен төбәктә татар тарихы менә шул рәвешле өйрәнелә – биредә мең ел элек болгарлар яшәгән, явыз татар-монголар килеп аларны басып алганнар, шуннан соң биредә болгарларның үзләре дә, шәһәрләре дә юкка чыккан. Алайса, сорау туа – бүгенге көндә Самара өлкәсендә яшәп ятучы татарлар кемнәр булалар соң инде – соңыннан килгән килмешәкләрме? Әмма алар үзләрен болгар бабаларның дәвамчылары, диләр бит, дәвамчы икән, димәк болгарлар ул чакта юкка чыкмаган, татар исеме астында сакланып, яшәп калган? Хәер, биредә аны урыска да, үзләрен болгар дип йөргән татарга да аңлату мөмкин түгел, аларның икесенең дә тарихи татар-монголларга карата нәфрәтләре хәттин ашкан... Менә шуңа күрә алар урыслар белән бер сүздә булып, һаман әллә кайчан булып үткән татар-монгол яуларын куерталар, Самар ярымутравының да, Муромский городокның да Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чоры бөтенләй өйрәнелми, тарихи татар бары тик начар яктан гына искә алына... Бик җайлы юл бит – әгәр Болгар шәһәрләрен, шул исәптән, Муромский городокны да явыз татар-монголлар җимергән, дисәң, син урыска охшыйсың, ул бу версияне рәхәтләнеп яклый һәм күтәрә. Әгәр син Болгар шәһәрләрен, шул исәптән, Муромский городокны да Казан ханлыгы юкка чыкканда явыз урыслар җимергән, дисәң, син урыс дошманына әйләнәсең, сиңа фәндә юллар ябыла... Менә шуңа күрә Самараның кайбер татарлары, болгарны күтәрәбез, дигән булып, урыслар белән берләшеп, татар тарихын түбәнәйтү юлына басканнар инде.

Тагы Емельяновның «Самарская Лука и Жигули» китабына әйләнеп кайтыйк. Муромский городок хәрәбәләре янындагы Валы авылы турында язганда, Емельянов яңарак мәгълүматлар да кертеп җибәргән. Әйтик, ул Д. Н. Садовниковның 1872-нче елда чыккан китабына мөрәҗәгать итә: «В своих путевых очерках 1872 года «Жигули и Усолье на Волге» Д. Н. Садовников так описывает эти места: «Окружность татарского укрепления, лежащего вправо от большой дороги (если ехать из Валов в Жигулиху) – в несколько верст… В народе прежними обитателями слывут и татары и разбойники…» [Емельянов: 1955. С. 175–176.].

Ягъни, әле XIX гасыр азагында, Садовников бу китабын язган чагында да, Валы авылы янындагы борынгы хәрәбәләрне «татарское укрепление» дип атаганнар, биредә элек татарлар яшәгән, дип барганнар. Болгар версиясе соңрак, нигездә, совет чорында килеп кергән, шулай итеп, шәһәрлектән генә түгел, бөтен Самар ярымутравыннан татар тарихы һәм татар атамасы сызып ташланган.

Емельяновның икенче китабында бер риваять-легенда бар, ул Уса елгасының Иделгә коя торган тамагында торган тау-курган белән бәйле. Поливанов бу тауны «Девичья Курган гора» дип атый, «Девичьи Курган» дип тә яза [Поливанов:1900. С. 28.]. Ә Емельянов ул исемнәрне төшереп калдырып, «Усинский курган» дип кенә атый, әмма курганның тарихын барыбер кызлар белән бәйли. Аның язуынча, биредә 12 баһадир кыз яшәгән, аларны беркем җиңә алмаган, әмма беркөнне урыс җиреннән бер гарип карт килеп, батыр кызларны җиңгән. Һәм ул урыс җирендә чын баһадирлар яшәгәнен әйткән. Автор фикеренчә, бу легенда XVI гасырларда, урыс дәүләтенең көчәйгән вакытында барлыкка килгән. Емельянов 12 батыр кызның кайсы милләттән икәнлеген язмаган, әмма безнең уебызча, бу кызлар татар милләтеннән булган, чөнки XVI гасырда, Казан ханлыгы җимерелгәнче, бу җирләр татар дәүләте составында булган. Хәзер Емельяновның үзенә сүз бирик һәм озынрак булса да, батыр кызлар турында риваять белән укучыларны да таныштырып үтик.

«Про Усинский курган есть старая легенда о живших на нем двенадцати сестрах-богатыршах. Не было на Волге в то давнее время витязей сильнее и храбрее, чем эти сестры. Всех они побеждали – так говорит эта легенда.

Но вот однажды пришел к ним калика убогий из далекой русской земли. После короткого боя сестры были побеждены старцем. И стали они спрашивать победителя, кто он такой. Старец ответил, что он не витязь, а всего лишь слабосильный старец. Но там, на Руси, есть и настоящие витязи. Призадумались сестры. Поняли они:

Что не сладить им с русской землею,
Не осилить им русский народ,
Когда стройною ратною силой
Он на матушку-Волгу придет.

Предание относится к тому времени, когда в XVI в. Российское государство крепло, его могущество возрастало. В 1552 г. произошло большое историческое событие: пало Казанское цартсво, а через четыре года пало и Астраханское. С 1556 г. р. Волга, от истоков и до устья, полностью вошла в границы Российского государства. С того времени происходи-

ло заселение берегов Волги русскими поселенцами» [Емельянов: 1955. С. 190–191.].

Батыр татар кызларын гарип бер урыс картының җиңүе – ул символик мәгънәгә ия күренеш.* Риваятьләрдә, гадәттә, батырны батыр җиңә, халык мескеннәрне иделлаштырмый, кызгана гына, ә монда – киресенчә. Мин бу легенданы башка авторларда очратмадым, шуңа күрә, чагыштыру мөмкинлегем юк, әмма архивлардан булса да табып укырга кирәк, дигән фикергә килдем.




Патша Курганы (Царев Курган)

Краевед Емельянов үзенең хезмәтләрендә Самар ярымутравы белән генә чикләнеп калмый, бу тирәдәге башка тарихи ядкәрләргә дә бәя бирә. Әйтик, биредән ерак булмаган Патша Курганы (Царев Курган) турында язганда ул 1669-нчы елда Идел буенча Әстерханга барган голландлы Стрюйс сүзләрен мисал итеп китерә: «Гора Сариол-Курган (Царев Курган)... если верить преданиям москвитян, образовалась очень странным образом. Это место представляло когда-то обширную равнину, куда явился один татарский повелитель с 70 князьми и бесчисленным войском для того, чтобы овладеть Московией; он был разбит и умерщвлен вместе со своими соучастниками; из их костей, говорят, и образовалась эта гора». Это же предание подтверждает и другой путешественник Корнилий де-Бруин, современник Петра I (1703 г.)» [Емельянов: 1938. С. 208.].

* Чынлыкта бу риваять – татарларныкы, «гарип урыс» ул – Аксак-Тимер образын чагылдыра булса кирәк. Ә «Девичья Курган-гора» – «Кызлар тавы» дигәннән калька(Редакция).

Бу урында ел фасылларының исемнәренең мәгънәләрен әйтеп үтик. Ябылган, кысылган, капланган, бөрешкән вә гайре шундый хәләтендә булган нәрсәләрне ачып, җәеп, киңәйтеп бирүгә төрки телдә «йазмак» диеләдер. Инде көн озаеп, дөнья җылынып, җир уянып, мал балалап, галәмдә, табигатьтә һәр нәрсә ябылган вә кысылган хәленнән киңәю вакты – шөбһәсез, март, апрель, май айларыдыр. Шуның мөнәсәбәтендә бу мизгел – фасылга «яз»диеләдер. Иске төркидә елның башы язның беренче аенда саналыр икән.

Төркиләр иске заманнан бирле кыр-далада күчеп, мал үстергән халык иде. Малны үзенең утлаган ягына иркененчә җибәрү төрки телдә «җәю» диеләдер. Һәм дә эшсез тик йөрүгә *җай йөрү*, дияләр. Июнь, июль, август айлары җай йөрелә торган вакыттыр. Хосусан, борынгы заманнарда шул мөнәсәбәттә «җәй» диеләдер. Үзбәк, казак һәм казанлы шивәләрендә «җәй» диелгән хәлдә, госманлы, мишәр, башкорт шивәләрендә «йай», диеләдер.

Куйларның йонын май эчендәге алуга – кырку, августның азагында һәм сентябрьнең башларында алуга – күзәү диләр. Инде күзәм ягындагы фасылга да «көз»дию бик туры киләдер.

Октябрь вә ноябрь айларыннан соң, үткән мизгелләрдәге иркенлекләр, киңлекләр бу мизгелләрдә бары да кимидер, дөнья табигый буларак һәр

җәһәттән кысыладыр. Шул мөнәсәбәткә бәйле декабрь, январь, февраль айларына иске төркиләр «кыс» дигәнләр, «с» урынына «ш» килеп, хәзер «кыш» диләр. Яз, җәй, көз, кыш мизгелләреннән кинәя буларак тамызыстан, бустан, зимстан сүзләре дә фарсы белән катыштырылып, кайбер төркиләрдә кулланыладыр.

Охшашлык кагыйдәсе буларак алты ай – яз, алты ай – кыш диелеп йөртеләдер. Мәкаль: яз языл, кыш-кысыл.

Иске төркиләр фәкать табигать тарафыннан бирелгән байлык белән генә көн күреп торган чакта, югарыдагы икътисади мәкальне сөйләп калдырганнар: «Барында – бүредәй, югында – шүредәй» мәкале икәве дә бер мәгънәдәдер.

«Шура»ның тышында төркичә көн атлары хакында бер сорау бар иде. Шуны буш калдырмаска теләдем. Төркичә көн атлары җомгадан саналып, шушылай: *атна көн, атнарасы көн, базар көн, баш көн, буш көн, бишен көн, кечатна көн*. Шул көн исемнәре хакында кыскача белдерик. Җиде көннән гыйбәрәт булган бер дәвергә «атна» диеләдер. Көннәрнең эченнән берсен шул дәвергә бәйләгәннәр, ия кылганнар. Бәйләнгән булганы мөнәсәбәтендә «җомга» көнгә «атна», «атна көн» дигәннәр. Атнаның шул иясе көне мәгънәсендә буладыр. Боларның һәммәсе «көн» сүзе белән кушылып йөртелгәннән, җиде көнне алган дәвер урынында йөргән «атна «белән җомга көне урынында килгән «атна» арасында аерма булмыйдыр.

Әһел насраннар (христиан динендәге кеше) өчен тәүбә көн – базар көндер. Шуның өчен икесенең уртасында булган шимбә көнгә атнарасы көн диеләдер. Ике атна көннең арасындагы көн куәсендә буладыр.

Иске заманнарда төркиләр атнадан бер көнне эш башлауга уңай көн итеп сайлап куйганлар да шуңа «баш» көн дигәннәр.

Борынгылар атнадан бер көнне каһәрләп, яманга чыгарып куйганнар. Ул көн эш башламас булганнар. Шул мөнәсәбәт белән «буш» көн диелгән булса кирәк.

Чәһәршәнбә көннең төркичә атын һич бер кешедән белә алмадым. Фәкать үзлегемнән шуны тәкъдим итәр идем. Атна көн үтеп, эш көннәре; беренчесе – атнарасы көн, икенчесе – базар көн, өченчесе – баш көн, дүртенчесе – буш көндер. Инде эш көннәренең бишенчесе булуга бәйле «бишен» көн диелсә ярамасмы иде? Бәлки моның төркичәсе дә бардыр. Авылларда йөргән кешеләр картлар белән карчыкларның сүзенә дикъкать итәргә тиешледер. Моның исеме табылмас идеме? Хәзергә Болгар хөкүмәте заманында чуаш вә чирмеш халыкларына бик күп сүзләребез кереп калганнар. Шуларның күбесе үзебездә онытылып, аларда сәламәт саклануы ихтималы бардыр. Шуның өчен ул халыклар арасында йөрүчеләрнең дә дикъкатен җәлеп итеп каламын.

Туачак атна көндә эш эшләнми, бәйрәм саналадыр, аңа әзерләнү өчен алдагы көннең соңгы яртысына янә буштанчылык (вакыт) биреләдер. Шуның белән анда атна көнгә охшашлык табыладыр. Шул мөнәсәбәттән «пәнҗешәмбә» көнгә «кичатна» көн диелгән, асылы кече атнадыр.

Көннәрнең исеме хәзерге вакытта төрки кавемнәр арасында башкача йөртеләдер, һәрвакыт «шәнбә» сүзе белән кушылып кулланыладыр. Матбугатыбызда, гомумән, шулай язалар, ләкин төркилек ноктасыннан караганда, ул «шәнбә»ләрне телебездән себереп ташлап, яңадан үз исемнәребезгә уйдыру, бору кирәктер. Мәсәлән, «шимбә», «якшәмбе» урынына мишәрләр «чәршәмбе»дән башка көн атамаларының төркичәсен йөртәләр. Кәлиндәрчеләр газета һәм журналчылар да үзләренең язуларында көн исемнәрен төркичә куллансалар, мөгалимнәр мәктәпләрдә балаларга төркичә өйрәтсәләр, елле елдан соң гомуми булып китәр иде. Каңгырган ят сүзләр телебездән чыгып, үзебезнеке кунсын иде.

**Әдәбият**

ح عالى شورا ايلار ييللار و كو نلار 1912 № 8, № 9, № 13.

*Язманы басмага әзерләүче: Ф.Ш. Нуриева,*
*филология фәннәре докторы*

***А.И. Бугарчёв,***
***О.В. Степанов***

# НУМИЗМАТИЧЕСКИЕ МАТЕРИАЛЫ ИЗ АЛЬКЕЕВСКОГО РАЙОНА РТ

***Аннотация:*** *Данная работа состоит из трёх небольших статей, посвящённых разным вопросам булгарской джучидской нумизматики. В первой статье рассмотрены крупные серебряные монеты, чеканившиеся в 1266–1273 гг. Их вес достигает трёх грамм. Монеты типа С/45 очень редкие, поэтому каждый новый экземпляр необходимо вводить в научный оборот. Во второй статье авторы рассматривают метрологию медных динаров с именем ан-Насира, найденных в окрестностях с. Старые Салманы. С учётом нового материала установлено, что большинство динаров, обращавшихся на местном рынке, весило в пределах 2,1–2,9 г. Третья статья посвящена монетам XIV в., найденным в окрестностях с. Каргополь. Общее количество комплекса насчитывает 13 медных монет середины XIV в. Тем не менее, по мнению публикаторов, даже такое небольшое число экземпляров является важным для анализа средневекового денежного обращения на территории Татарстана.*

***Ключевые слова:*** *пул, динар, дирхам, Булгарский регион, Улус Джучидов, XIII–XIV в., денежное обращение.*

**I.** В 1266–1267 г. (в 665 г. хиджры) в Улусе Джучидов к власти пришёл хан Менгу-Тимур. К этому-же времени относится денежная реформа, проведённая в новом государстве. В Хорезме и Крыму она проявилась в чеканке новых монет с именем Менгу-Тимура, его тамгой, указанием монетного двора и датой 665 г. хиджры (1266–1267 г.). В Булгарском регионе денежная реформа выразилась в чеканке сразу 8 разновесных типов серебряных монет. Самой крупной монетой являлись дирхамы С/45 весом около трёх грамм (типология булгарских монет XIII в. – С/45 означает монету, приведённую в каталоге А.З. Сингатуллиной под №45) [Сингатуллина: 2003]. Из всех информационных единиц – имя эмитента, место чеканки, год выпуска, тамга – на подобных экземплярах проставлены только название монетного двора – Булгар и помещена тамга Менгу-Тимура. Впервые данный номинал был издан в 1832 г. в книге Х.М. Френа [Френ: 1832. Таб. XII, №4, С. 36, №370]. В 1880 г. в Болгаре был найден клад, в состав которого входили и два экземпляра указанного типа [Бугарчев, Петров: 2018]. Сейчас они хранятся в фондах Национального музея Татарстана.

Несколько лет назад в один из художественных магазинов Москвы был сдан на комиссию булгарский дирхам весом 2,17 г. Нам удалось установить происхождение этой монеты. Выяснилось, что она была найдена в Алькеевском районе, в окрестностях с. Салманы. Экземпляр имеет повреждение (отломана часть монеты), поэтому можно предположить, что первоначальный его вес приближался к трём граммам.

Из монографии А.З. Сингатуллиной следует, что монеты данного типа чеканились в трёх весовых группах – весом 1,26–1,58 г, 0,59–0,76 г и 1,98–3,04 г. В каталоге они представлены под номерами С/43, С/44 и С/45 [Сингатуллина: 2003]. Самыми распространёнными являются монеты с указным весом 1,56 г, это тип С/43. Хотя на монетах не проставлена дата чеканки, по материалам последних исследований выяснилось, что данный тип «серебра» чеканился в самом начале правления первого золотоордынского хана Менгу-Тимура – в 1266–1273 гг. Экземпляры самого маленького и самого крупного веса встречаются очень редко. И если монеты с фактическим весом 0,75 г (или указного веса 0,78 г – половина от дирхама весом 1,56 г) в дальнейшем продолжали использоваться (например, тип С/14 начала 1270-х гг.) [Сингатуллина: 2003]), то крупные монеты оказались невостребованными на рынках Булгарского вилайета и больше не чеканились. Самыми распространёнными оказались фракции с указным весом 1,39 г и 1,56 г.

**II.** В 2016 г. была опубликована статья, посвящённая монетам монгольского и ранне-золотоордынского периодов, найденным в окрестностях села Старые Салманы Алькеевского района [Степанов, Купцов, Нисифоров: 2016]. Среди прочих, в статье рассматривались медные монеты с именами багдадского халифа ан-Насир ли-дин Аллаха (выпускались с конца 1230-х гг. и в 1240-е гг.) и каана Мунке (выпускались в 1250-е гг.), которых насчитывалось 30 экземпляров – по 15 динаров каждого типа. У 20 монет – по 10 экземпляров каждого эмитента – сохранились метрологические характеристики, то есть вес.

За время, прошедшее с момента публикации статьи, нумизматический фонд с. С. Салманы пополнился новой информацией. Были обнаружены медные монеты вышеуказанных типов со следующим весом – 0,9 г, 1,6 г, 1,9 г, 2,1 г–2, 2,6 г, 2,7 г. Таким образом, общее число «салмановских» медных монет, чеканенных на монетном дворе Булгар и у которых сохранилась информация о весе, теперь составляет 27 экземпляров. В статье 2016 г. основное внимание авторы уделили анализу серебряного состава комплекса. В данной статье мы разберём особенности метрологии «меди», чеканенной в середине XIII в.

Как известно, булгарские медные монеты с именем Мунке в подавляющем числе – это перечеканенные медные динары с именем ан-Насира,

что позволяет проводить метрологический анализ обеих групп вместе. Количество в 27 экземпляров позволяет построить гистограмму.

**Зависимость количества медных монет ан-Насира и Мунке от значения их веса. Салманы. Учтено 27 экз. Ось *X* – вес в г, ось *Y* – количество в экземплярах. Гистограмма**




Наибольшее количество монет приходится на значение веса 2,7±0,1 г, 8 экз., (29,6 % от всех учтённых монет). Средний вес 25 монет – 2,55 г (без учёта одной самой лёгкой и одной самой тяжёлой монеты), или, округлённо, 2,6 г, что соответствует допуску моды из гистограммы.

Ранее уже было установлено, что медные монеты XIII в. с именем ан-Насира чеканились по системе «эль-марко», то есть без выверки точного веса каждого экземпляра. Разброс значений веса «салмановских» монет достигает 4,1 г – от 0,9 до 5,0 г. Тем не менее, из гистограммы следует, что большинство динаров, обращавшихся на местном рынке, имели вес в пределах 2,1–2,9 г. Об этом же свидетельствует установленный средний вес 25 динаров. Мы сейчас не можем сказать, стихийно сложилось такое соотношение или в результате каких-то законодательных мероприятий. По нашим представлениям, изучаемые монеты чеканились с конца 1230-х до 1259 г., или около 20 лет. Ранее на более массовом материале (комплекс медных монет ан-Насира и Мунке с Болгарского городища в количестве 765 экземпляров, хранящийся в фондах Болгарского музея-заповедника) нами были установлены 4 шага понижения расчётного веса за указанный промежуток времени:

-3,1±0,2 г,

-2,7±0,2 г,

-2,1±0,2 г,

-1,5±0,2 г.

К сожалению, пока не удаётся установить даты снижения веса «меди».

Следуя из показаний гистограммы, на Салмановском памятнике фиксируется преобладание монет второго этапа – 2,7 г. Обращает на себя внимание тот факт, что динары весом менее 1,4 г представлены всего од-

ним экземпляром. Для сравнения можно привести метрологию аналогичных медных монет из находок на Старонохратском археологическом комплексе [Степанов, Купцов, Нисифоров: 2016]. Максимум гистограммы, в которой было учтено 147 экземпляров, пришёлся на значение 2,0±0,2 г, а одна из второстепенных мод – на значение 2,5±0,2 г, что соответствует моде 2,7 г на гистограмме салмановских монет.




Фототаблица монет к статье А.И. Бургачёва и О.В. Степанова

Безусловно, данные расчёты имеют предварительный характер, так как для метрологического анализа информационная база в 27 экземпляров маловата. Тем не менее, установленные значения моды и среднего веса позволяют сделать определённые выводы об особенностях денежного обращения на территории данного археологического памятника. Возможно, в дальнейшем, с увеличением количества находок, наши выводы будут скорректированы. Что касается местонахождения памятника, то мы можем сослаться на информацию Д.Г. Мухаметшина, научного сотрудника Болгарского музея-заповедника. В своей статье за 2015 г. он упоминает шесть археологических объектов с топонимом «Салманы»: Нижнесалмановское селище (№ 54), Салмановское местонахождение (№ 55), Новосалмановское местонахождение (№ 56), Старосалмановское местонахождение (№ 57), Абдулсалмановское селище (№ 58) и Анино-салмановское местонахождение (№ 59) [Мухаметшин: 2015]. Не исклю-

чено, что весь монетный комплекс может происходить с местечка «Иске Юрт», находящемся в полукилометре от кладбища с. Старые Салманы.

**III.** В истории Волжской Булгарии известны несколько крупных городских центров, функционировавших в XIII–первой половине XV в. Кроме главного города этого времени – Булгара, можно назвать Джукетау, Иски-Казань и некоторые другие. К числу таких крупных городских центров можно причислить и археологический комплекс, находящийся в окрестностях современного села Салманы. Судя по нумизматическому материалу, в XIII–первой половине XIV в. здесь находилось большое поселение, название которого нам пока не известно. Как у любого средневекового города, в окрестностях «Салмановского» городища можно встретить небольшие поселения, составлявшие округу регионального центра. Одним из таких поселений являются Каргопольские I и II селища. На одном из них были обнаружены золотоордынские пулы середины XIV в. Ниже приводится опись находок.

**Таблица золотоордынских пулов, найденных у с. Каргополь**

| № | Эмитент | МД | Год чеканки, х. | Вес, г | Тип |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Анонимный (Узбек) | Сарай | (737–743) | 1,25 | «Лев направо и солнце» |
| 2 | Анонимный (Узбек) | Сарай | (737–743) | 1,22 | «Лев направо и солнце» |
| 3 | Анонимный (Узбек) | Сарай | 737 | 1,58 | «Лев направо и солнце» |
| 4 | Анонимный (Узбек) | Сарай | (737–743) | 1,45 | «Лев направо и солнце» |
| 5 | Анонимный (Узбек) | Булгар | (736–740) | 1,30 | Булгарская решётка |
| 6 | Анонимный (Джанибек) | Сарай ал-Джадид | (743–750) | 0,86 | «Двуглавый орёл» |
| 7 | Анонимный (Джанибек) | Сарай ал-Джадид | (743–750) | 0,98 | «Двуглавый орёл» |
| 8 | Анонимный (Джанибек) | Сарай ал-Джадид | (743–750) | 1,23 | «Двуглавый орёл» |
| 9 | Анонимный (Джанибек) | Сарай ал-Джадид | (743–750) | 1,30 | «Двуглавый орёл» |
| 10 | Хызр | Сарай ал-Джадид | (762) | 2,89 | |

№№ 11–13. Неатрибутируемые пулы – 3 экземпляра (вес 1,29; 1,15; 0,71).

Всего выявлено 13 монет. Десять из них представляют известные типы, чеканившиеся с конца 1330-х гг.до начала 1360-х гг., то есть около 20 лет. Девять монет имеют вес от 0,86 до 1,58 г – скорее всего, они представляют один самый мелкий номинал медных монет с фактическим весом 1,4 г. Пул с именем Хызр-хана принадлежит другой весовой группе, другому номиналу.

Трудно делать далекоидущие выводы по такому скудному составу нумизматического комплекса, тем не менее, подобная информация необходима для дальнейшего анализа средневекового денежного обращения на территории Татарстана.

Село Каргополь находится в 11 км севернее райцентра Базарные Матаки. Из археологической литературы известны два Каргопольских селища [Свод: 2007]. Первое селище находится в 5 км к юго-востоку от современного села Каргополь, второе расположено в противоположной стороне, в 1 км северо-западнее села. Оба селища открыты в 1946 г., на них зафиксирован похожий материал – булгарская керамика домонгольского времени. Выявленный нумизматический материал свидетельствует о существовании денежного обращения в середине XIV в. Возможно, что археологическое изучение обоих памятников позволит обнаружить новый материал для характеристики экономической жизни в округе «Салмановского» города.

## Литература

1. Бугарчев А.И., Петров П.Н. Монетные клады Булгарского вилайата XIII–первой четверти XIV вв. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2018. 336 с., илл.
2. Бугарчёв А.И., Степанов О.В. О метрологии болгарских медных монет середины XIII в. Находки Старонохратского археологического комплекса // Человек и природа в Восточном Татарстане. Исчезнувшие и исторические села: изучение, сохранение и возрождение. Материалы Всероссийской конференции // Серия «Восток – Запад: диалог культур и цивилизаций Евразии». Вып. 16. Под ред. А.А. Бурханова. – Казань: Отечество, 2017. С. 43–46.
3. Мухаметшин Д.Г. Новые археологические памятники Западного Закамья / Материалы научно-практического семинара «Болгарский музей-заповедник – хранитель культурного наследия, посвященного пятилетию создания Республиканского Фонда возрождения памятников истории и культуры Республики Татарстан. – Болгар, 2015. С. 126–196.
4. Свод памятников археологии Республики Татарстан. Т. 3 / Отв. ред. А.Г. Ситдиков, Ф.Ш. Хузин. – Казань, 2007. С. 123, №№ 927–928.

5. Степанов О. В., Купцов А. Е., Нисифоров А. Н. Находки джучидских монет из окрестностей с. Старые Салманы Алькеевского района Татарстана // Нумизматика Золотой Орды. № 6. – Казань, 2016. С. 33–37.
6. Сингатуллина А. З. Джучидские монеты поволжских городов XIII в. – Казань: «Заман», 2003. 192 с.
7. Френ Х. М. Монеты ханов Улуса Джучиева или Золотой Орды с монетами разных иных мухаммеданских династий в прибавлении. – СПб., 1832. 80 с.: XVII табл. ил.

*Номера монет в фототаблице соответствуют номерам Таблицы пулов.*

*Приложение.* Вес медных динаров с именами ан-Насира и Мунке, найденных в окрестностях с. Салманы (в граммах): 0,9, 1,4, 1,6–2, 1,7, 1,9–2, 2,1–2, 2,3–2, 2,5, 2,6–5, 2,7–2, 2,8, 2,9, 3,3, 3,5, 3,6, 3,7, 4,1, 5,0. Всего 27 монет.

Краеведение в научно-популярных публикациях

*Нурулла Гариф*

# НӘСЕЛ ТАМЫРЫҢНЫ БАРЛЫЙМ ДИСӘҢ...

***Аннотация:*** *Нами исследованы известные архивные источники для составления родословной. Интересными представляются возможность исследования и составления шеджере на основе многочисленных документов, хранящихся в различных архивах. Для их комплексного изучения необходимо привлечение и других категорий источников – фольклорных, эпиграфических, топонимических.*

*Полученные материалы могут быть использованы при изучении истории деревень, расположенных в Республике Татарстан и за его пределами. Материалы и результаты работ планируется представить к обсуждению на конференциях, опубликовать в научной и популярной литературе.*

***Ключевые слова:*** *ревизские сказки, метрика, эпиграфичекие памятники.*

«Атасына карап улын, анасына карап кызын коч», – ди халык мәкале. Сүзем шәҗәрләр, халкыбызның элек-электән нәсел тамырларына булган карашы турында.

Бүгенге көндә терлек малын үрчетеп, артым, үрчем, майлылыгы югары булган сөт, яисә яхшы йон алыр өчен аларның нәселен барлап, яңа токымнар чыгаралар. Тормышта төрле вакыйгалар белән очрашкан саен, мал-туары өчен тырышучы халык үз токымы – нәсел-нәсәбе турында борчыламы икән дип тә уйланырга туры килә. Халыкта бик еш, «Алар нәселләре белән шундый!», «Аларга кыз бирергә, алардан кыз алырга язмасын...», яисә, «Болар затлы нәсел!» – дигән кебек гыйбәрләрне еш ишетергә туры килә. Хәер, хәзер элеккедән калган яучы әбиләрнең кирәклеге дә калмады бугай, «Чиләгенә күрә капкачы» дигән әйтемнәр дә эшләми инде. Бүгенге яшьләргә «Күрше авылыныкы күркә булып күренү» генә җитми. Хәзер башка ил, башка халыклар белән дә кавышалар. Дин, тел аермалыгына карата булган тискәре караш та юкка чыкты диярлек.

Без әлегә боларның нәтиҗәсе турында уйланмыйбыз, генетика фәненә дә җитди карамыйбыз. Медицина нәтиҗәләре күп чирләрнең нәселдән күчүен, кайбер чирләрнең хатын-кыз, яисә ир ягыннан килүче авыруларга, аларның буын аша сикереш ясауларына да ихтибарыбызны бирмибез. Нәселләре белән урыслашып баручы милләттәшләребез өчен дә борчылмыйбыз сыман. Сүзебез әлегә киләчәктән бигрәк үткәндәгеләрне барлау, нәсел шәҗәрәләребезне булдыру турында. Фикере булганнар аңлар...

Бүгенге көндә нәсел-шәҗәрәләре белән кызыксынучылар да юк түгел. Күпләр әби-бабаларын, туганнарын барлый. Моның өчен архивларда сакланучы документлар ярдәмгә килә. Тарихыбызны барлаганда без үткән чорлардан башласак, нәсел тарихын барлаганда үзебез, әти-әниләребез, алар ягыннан барып тоташкан әби-бабаларыбыз шәҗәрәсен ачыклаудан башлыйбыз. Әби-бабаларыбызны, аларның әти-әниләрен, алардан, олырак яшьтәге туганнарыбыздан барлап, белешеп була.

Ниндидер сәбәпләргә бәйле әби-бабаларын белмәгәннәргә, белешмәне Татарстан районнарының гражданлык хәленә бәйле актлары аркылы Республика ЗАГС архивыннан соратырга була. Алардагы мәгълумат 1922-нче елдан алып, бүгенге көнгәчә тупланган (Адресы: Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 179 нчы йорт).

Совет чорына чаклы булган мәгълуматны муллалар тарафыннан алып барылган метрикә кенәгәләреннән барлыйбыз (ТР МА. Фонд 4. Тасв. 177 һ.б.). Әлеге кенәгәләр гарәп графикасында, татар телендә язылган. Аларда әби-бабаларыбыз, нәселдәшләребезнең туу, вафат булу һәм никахлашу (аерылышу) таныклыклары (документлары) бар. Метрикаларда яңа туган баланың, никахлашучы яшьләрнең ике яктан да ата-аналарының исем-шәрефләре, никахлашучыларга таныклык бирүчеләрнең исем-шәрефләре, вафат булучы кешенең нинди авырудан үлгәнлеге һ.б. төр мәгълумат бирелә.

Метрика кенәгәләрен тутыру эше 1829-нчы елдан – 1917-нче елгача, кайбер авылларга бәйле рәвештә 1936-нчы елга чаклы алып барылган. Әлеге документарның 1829–1865-нче елгача тутырылганнары Башкортстан Республикасы үзәк архивында (ЦГИА РБ. Фонд И-295. Тасв. 9; Адресы. Уфа шәһәре, Карл Маркс урамы, 4), икенче өлеше Уфа шәһәрендәге Республика ЗАГСы архивында саклана. 1865–1917-нче елларга караганы Татарстан Республикасының милли архивында саклана (ТР МА. Фонд 3. Тасв. 2; Адресы: Казан, Кави Нәҗми урамы, 7). 1916–1936-нчы еллар арасындагысы Казанда «8 март тукталышы»нда урнашкан архивта саклана.

Шәҗәрләрне барлаганда, архивта сакланучы башка фондлар да ярдәмгә килә. Мәсәлән, Казанда, Милли архивта сакланучы 81 нче фонд-

ның 2 нче тасвирламасындагы эш кенәгәләрендә авылларның төзелеш планы бирелгән. Авыллар планында һәр йорт номерланган һәм аларда яшәүче йорт хуҗаларының исемнәре теркәлгән. Бу чыганак, бабаларыбызның шәҗәрәсен тулылындырудан тыш, аларның авылда яшәгән нигез-йорт урыннарына да ачыклык кертә.

Авылларыбыз яшәешендә төп рольне дини эшчәнлек – мәчет-мәдрәсә, авыл мәхәлләсенең яшәеше уйнаган (ТР МА. Ф.2. Тасв. 2, 7, 4, 14, һ.б.). Аларда мәчет төзелешенә бәйле вакыйгалар, мәчет-мәдрәсәләрнең планнары, муллаларга кагылышлы документлар җыелмасы, авыл җыеннары һәм анда кабул ителгән төрле карарлар да чагылыш таба. Әлеге карарларда мәхәллә халкының исемлеге, аларның гаилә саны да теркәлгән. Нәсел шәҗәрәсен төзегәндә әлеге документлар да ярдәмгә килә.

Авыл халкының тагын да борынгырак чорларга караган шәҗәрәсен ревизия кенәгәләре (ТР МА. Ф.3. 2 Тасв. (1818–1858 еллар); ЦГИА РБ. Ф.И-138. Тасв.1, (1797–1867 еллар; Тасв. 2, 1795–1863 еллар); РГАДА. Ф.350. 1–3 Тасв. (1710–1763 еллар. Адресы: Мәскәү, Б.Пироговская, 17) аша ачыкларга була. Ревизия кенәгеләреннән тыш, 1710–1716-нчы елларга караган Ландрат кенәгәләре дә бар. Аларда кеше исемнәреннән тыш, әби-бабаларыбыз яшәешенә бәйле башка төр мәгълүматлар да бирелә.

Нәселебез шәҗәрәсен ачыклаучы документларны барлаганда күз алдына ерак әби-бабаларыбыз, авылдашларыбызның шәҗәрә агачы тулаем барлыкка килә. Җиде-сигез буын эчендә авыл халкы бөтенләе белән диярлек туганлашып бетә. Бу туганлык, рухи якынлык, бүгенге көндә дә авылда яшәүчеләрне үзара якынайта ала. Безнең халыкка җиде буын бабасын белү дә фарыз бит әле.

***Ф.М.Гыйльманов***

# ЧУРАКАЙНЫҢ ПЕНЗА ТАТАРЛАРЫ

## Әлшәй төбәгендәге борынгы башкорт авылы татар мөһаҗирләренең берничә буынына сыену урыны биргән

Тарихи әдәбиятта «Халыкларның Бөек күченеше» дигән төшенчә бар. Гомумкешелек әһәмиятендәге бу хәрәкәт Европада икенче йөзьеллыкта башланып, Рим империясенең һәлакәтеннән соң җиденче гасырда тәмамлана. Биш дулкында үткән күченешнең икенчесендә әйдәүче көч булып Азия тарафларыннан килгән хун (гун) кабиләләре тора, алар арасында болгарлар да була.

Аларның дәвамчылары саналган татар (халкы) өчен Бөек күченеш дәвере Казан алынгач, уналтынчы гасырда башлана, христианлаштыру сәясәтенә бәйле күченү XVIII-нче гасырда янә дә көчәя. Татарларның зур гына өлеше Урал алды төбәкләренә килә. Бу очракта «күченү» төшенчәсен шартлы итеп алабыз, чөнки Урал алды, Кама буе төбәкләренә хәзерге мәгънәдә йөргән татарларның күченеше Бөек Болгар чорыннан ук башлана, соңрак әлеге биләмәләр Казан ханлыгы составына керә. Шулай ук тарихи чыганакларда татарларның XIX-нчы гасырда Көнбатыш Себергә һәм Урта Азиягә күченүе теркәлгән. Соңрак татарларның зур төркеме Русиянең Европа өлешенең сәнәгать нык үсешкән төбәкләренә, Кавказ һәм Украинага китеп утыруы билгеле. Гражданнар сугышы чорында аерым татар гаиләләре Төркия, Кытай, Япония, Австралия, Германия, Финляндия, АКШка да китә.

Татарларның Совет чорындагы мөһаҗирлек хәрәкәте 1921-нче елгы ачлыкка, шәхси хуҗалыкларны күмәкләштерүгә, Бөек Ватан сугышына, аннары чирәм җирләрне үзләштерүгә барып тоташа. Русиянең төрле төбәкләреннән татарларның зур гына өлеше Үзбәкстан һәм Казахстанга күчеп китә.

Бу урында халыклар күченешенә бәйле аңлатма биреп китү сорала. Гомумән, яшәештә күченеп, яңа урыннарда нигез кору күп милләт вәкилләренә, шул исәптән, Башкортстанда яшәүче урыслар, чуваш, мариларга һәм башкаларга да хас. Русия империясендә үткәрелгән сәясәт нәтиҗәсендә, мәсәлән, урыс крестьяннарының тарихның аерым чорларында башка төбәкләргә күченеп утыруы хәтта гомум төс алуы мәгълүм. Ни өчен дигәндә, илнең төп милләте сыйфатында аларга күченү өчен шартлар тудырыла, мәсәлән, түләүсез яки арзан хакка җир бирелә, салым түләүдә ташламалар ясала. Ә менә безнең тикшерү объекты булган та-

тарларны күченүгә башка сәбәпләр этәрә. Аларның Казан яулап алынган чордагыларын әйтеп үттек инде. Боларга өстәп туып-үскән төбәкләрне калдыруга төп сәбәп итеп милли изелү, дини җәберсетелү алына. Шул рәвешле, билгеле урынга гомерне саклап калу белән бергә милли үзенчәлекне югалтмауга омтылыш та чыга. Монда инде чукындыру янаган дини фактор алгы планда тора. Татар мөһаҗирләрен урыс күченүчеләреннән аеручы төп сыйфат шушы.

Гомумән, күченешнең сәбәпләре гаять күп төрле, алар югарыда искә алынганнар белән генә чикләнми. Күченүне тарихи яссылыкта аерым авыл һәм бер гаилә мисалында аеруча ачык төсмерләргә мөмкин. Бу җәһәттән Башкортстан татарларының үткәне гыйбрәтле.

### Башкорт вотчинниклары төбәге

Хәзерге вакытта Шафран авыл биләмәсенә кергән Чуракай – Әлшәй төбәгендә иң борынгы башкорт авылларының берсе. Тарихы 1745-нче елда башланган авылның нигез ташларын салучылар булып башкорт вотчинниклары исәпләнә. Тарихи чыганаклардан аларның шулай ук бу төбәктә киң билгеле Ташлы авылыннан күченеп утыруы билгеле. 1795-нче елгы җанисәп материалларыннан күренүенчә, Чуракайда 16 йорт-и-хатада 85 башкот-вотчинник гомер кичергән. Авыл зурайганнан-зурая, анда яшәүчеләр саны да арта. Җанисәп мәгълүматларында 1816-нчы елда биредә ике җенестәге 132, 1834-нче елда – 186, 1859-нчы елда 250 кеше теркәлгән. 1917-нче елдагы халык исәбен алу барышында Әлшәй волосте Чуракай авылында 707 башкорт, 27 урыс, 13 типтәр, 8 чуваш, 6 немец исәпкә алынган.

Совет власте елларында күп милләтле Чуракайда халык санының кискен артуы күзәтелә. Моңа 1930-нчы елларда авылга хәзерге Туймазы районының Чокадыбаш һәм Имән Күпер авылларыннан күченеп килүчеләр дә зур гына йогынты ясый. Бүгенге вакытта Чуракай авылы халкының төп вәкиле саналучы Фаил Әмир улы Солтанов әнә шул күченеп утыручыларның нәселен дәвам итүчеләрдән. Ул 1963-нче елда Чуракайда туган. Хәзер инде 60 яшь үрен куган Фаил Әмир улы бай тормыш юлы үтә. Ул күрше Шафран поселогында мәктәп тәмамлагач, Дәүләкән һөнәри училищесында укып, «водитель» белгечлеге ала. 1981–1983-нче елларда Варшава килешүе илләренең Көньяк төркеме гаскәрләре составында хәрби хезмәтне Венгрия Халык Республикасында үтү дә насыйп була аңа. Әйткәндәй, хәрби хезмәт чорында водитель Солтанов Венгриядән Советлар Союзына урып-җыю эшләренә җибәрелә һәм фидакарь хезмәт күрсәтеп, ул чорда абруйлы саналган «Алтын башак» медаленә лаек була.

Солдат бурычын үтәгәч, Фаил Солтанов шофер сыйфатында хезмәт юлын туган авылындагы Куйбышев исемендәге колхозда дәвам итә. Читтән торып Бәләбәй авыл хуҗалыгын механикалаштыру техникумын тәмамлый һәм җитәкче вазифаларга күтәрелә. Атап әйткәндә, 8 ел дәвамында колхозда инженер, бу өлкәдә баш белгеч йөген тарта, аннары яңа оештырылган «Башкортстан» авыл хуҗалыгы кооперативы рәисе итеп сайлана һәм бу урында 6 ел эшли. 2002-нче елда крестьян-фермер хуҗалыгы оештырып, туган төбәгендәге халыкны эш белән тәэмин итүгә лаеклы өлеш кертә. Әйтергә кирәк, Солтанов КФХсы тердәшләре арасында Әлшәй төбәгендә тотрыклы хуҗалык санала, ул ярыйсы гына зур җитештерү куәтләренә ия. Эшчәнлеген уңышлы алып баручы хуҗалык җитәкчесе Башкортстан Республикасы Президентының һәм Русия авыл хуҗалыгы министрлыгының Мактау грамоталары белән бүләкләнгән. Җәмәгате Зәлия Хәбир кызы белән бер кыз үстергәннәр. Әлинә Уфа нефть университетын тәмамлап, «Роснефть» челтәрендә хезмәт сала. Аның җәмәгате, һөнәре буенча юрист, Линар Халиков Дәүләкән районының Корьятмас авылы егете.

## Юллар Дим буена илтә

Нәсел тамырларын 7 буынга кадәр тикшереп, шәҗәресе буенча Фаил Солтанов әтисе һәм әнисе ягыннан ата-бабаларының хәзерге Туймазы районының Имән Күпер авылыннан булуын ачыклаган. Әмир Юныс улы, мәсәлән, 1928-нче елда туган, аның туу урыны итеп Чуракай авылы күрсәтелгән. Ә бит Солтановлар чыгышы белән Туймазы районыннан.

1917-нче елгы Авыл хуҗалыгы исәбен алу материалларынан күренүенчә, бу чорда Имән Күпердә яшәүче Юныcның әтисе Солтангәрәй Сөләйманов авылда хәлле крестьяннардан була. Төп эшчәнлеге «умартачы» итеп күрсәтелсә дә, аның йорт-ихатасында 26 баш терлек теркәлгән, шулардан алтысы – эш атлары. Җир биләмәсе 20 дисәтинә тәшкил итә. Исәп алу барышында Солтангәрәйнең йорт-ихатасында ике авыл хуҗалыгы хезмәткәре (батрак) тотуы да язылган. Аның улы Юныс Солтанов Имән Күпердә 1926-нчы елгы Бөтенсоюз халык исәбен алу материалларында теркәлгән. Бу чорда аңа 39 яшь була. Имән Күпердә Юныс турында истәлекләр бүген дә саклана. 1930-нчы елгы Хавил Хәбибуллин, мәсәлән, Юныс турында үзенең әтисе сөйләгәннәрдән белә икән, чөнки алар ерак булса да, туган саналганнар. Юныс Солтановның хуҗалыгы ныклы була, атасы кебек үк ишле мал асрый. Бер сүз белән әйткәндә, авыл бае саналмаса да, социаль хәле белән Совет чорындагы «кулак»ка туры килә. Әйтергә кирәк, вакыйгалар агышыннан үз көче белән мал табып, тырышлыгы белән алдырган крестьяннарга яңа властьның мөнәсәбәтен тоемла-

гандыр ул. Шуңа да шәхси хуҗалыкларны күмәкләштерү турында хәбәр таралу белән, малларының бер өлешен авыл ярлыларына таратып биргән. Шул рәвешле, Совет власте куштаннарына гаеп табарга урын калмасын, дип уйлагандыр. Әмма авылдагы хәл-вакыйгалар икенче юнәлеш алган булса кирәк. 1920-нче еллар азагында, ягъни, күмәкләшүгә юнәлеш алынып, авыл хуҗалыгы артеле оештырыла башлау белән, Имән Күпердән егермеләп гаилә Дәүләкән тарафларына күченергә карар итә.

Элекке биредәге Чуенчы авылы төбәгендәге «Ярманчы» дигән урынга килеп урнашалар. Ул хәзерге Чуенчы авыл биләмәсендәге Яскаен авылы эргәсендә. Шушы авылда туып-үскән, төбәк тарихы белән кызыксынучы 72 яшьлек Салават Хөснетдинов әйтүенчә, Ярманчы авыл булып та оешып китә алмый, чөнки бу төбәккә күченеп килүчеләрне урнаштырганга, «пересыльный пункт» буларак кына таныла ул. Ике еллап биредә җан асрагач, Имән Күпер кешеләре Әлшәй районының Чуракай авылына килеп төпләнә. Әйтергә кирәк, бу вакытта инде егерме гаиләле төркем шактый кечерәя, чөнки авылдашларның бер өлеше күченү мәшәкатьләренә бирешеп, киредән Имән Күпергә кайтып китә.

Ә менә Солтановларның соңгы буыннары өчен Чуракай чын мәгънәсендә туган төбәккә әверелә. Әмир Солтановның тугач ук рәсми рәвештә шушы авылда теркәлүен язган идек. Биредә ул нәсел вәкиле тамырлары Туймазы районының Чокадыбаш авылына илткән Зәйтүнә Фаризун кызы Дилмөхәмәтова белән гаилә кора. Әмир Юныс улы Чуракай авылы, биредәге Куйбышев исемендәге колхоз тарихында якты эз калдырган шәхесләрнең берсе. Эшче – Крестьян Кызыл Армия сафларына ул Әлшәй районы хәрби комиссариатыннан чакырыла, рәсми рәвештә теркәлмәгән, әмма ил тормышының аерылгысыз өлеше булган Совет-Корея сугышын үтә. Хәрби хезмәттән исән-имин кайткан солдат Солтанов тынычлыкта да сынатмый. Хезмәт юлын Ташлы МТСында башлый, озак еллар дәвамында Куйбышев исемендәге колхозда шофер булып хезмәт сала. Эшендә алдынгы булып санала, 1970-нче елларда колхозга кайткан яңа йөк автомобиленең нәкъ менә Әмир Солтановка бирелүе дә дә моңа ачык дәлил. Ул колхоз производствосында фидакарь хезмәте өчен «Мактау билгесе» ордены, РСФСР Югары Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнгән.

Солтановлар гаиләсендә дүрт ул үсә, шулардан Фаил турында мәгълүмат биреп үткән идек. Солтановларның иң өлкәне Рәфис язмышын Бәләбәй районындагы элекке Карл Маркс исемендәге колхоз белән бәйли, озак еллар биредә зоотехник булып эшли. Гаилә кора, җәмәгате Флидә – Кушнарен районының Рәсмәкәй авылыннан. Ни аяныч, Рәфиснең гомере кыска була. Гаиләдәге өченче бала Наил дә туганының язмышын

кабатлый – Яр Чаллы шәһәрендә 60 яшен дә тутыра алмыйча бакыйлыкка күчә. Төпчек малай Камил гомеренең зур өлешен Себер тарафларында эшләп үткәрә, хәзерге вакытта туган авылында яши.

Солтановлар арасында фидакарь хезмәтләре, намуслы тормыш рәвеше белән Әлшәй районында матур истәлек калдырганнар байтак. Әйтик, Имән Күпердән күченеп килгән Юныс Солтанов җәмәгате Фәрдия белән, Әмирдән тыш, янә ике ул һәм дүрт кызга гомер бүләк итәләр. Болар: Йосып, Әвис, Хашия, Шәмсия, Разия һәм Хәмдия. Үсеп җиткәч, алар барысы да Әлшәй районы авылларында төпләнеп кала. Бөек Ватан сугышы яугире, ил азатлыгы өчен көрәштәге батырлыгы өчен «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнгән Әвис Юныс улы Солтанов, мәсәлән, Түбәнге Әврездә урнаша, биредә мәктәптә укыта, авыл Советы башкарма комитеты рәисе булып эшли. Тормыш иптәше Җәүһәр Галикарам кызы белән алар 7 бала тәрбияләп үстерәләр.

Тоташ алганда исә Юныс Солтанов балаларының дәвамчылары районда гына 50 кешегә якын.

## Күперләре имәннән

Билгеле башкорт тарихчысы Әнвәр Әсфәндияров хәзерге Әлшәй районы авыллары тарихын барлаганда төбәккә татар-мишәрләрнең беренче төркеменең 1738-нче елда ук күченеп килүләрен билгели. Аларның җир хуҗаларының рөхсәтеннән башка гына урнашуы теркәлгән. Җир мөнәсәбәтләре көйләнгәч исә, Әврез, Әбдрәшит, Слак, Трунтаиш, Нигъмәтулла кебек авылларга ясаклы һәм йомышлы (служилые) татарлар, мишәрләр күпләп күчеп утыра башлый. Бу җәһәттән шуны билегеләп китү урынлы: милли атама буларак, мәкаләдә «мишәр» исеме очраклы кулланылмый, чөнки Русия империясе чорындагы халык исәбе алу материалларында (Ревизская сказка) мишәр авылларында яшәүчеләр үзләрен «мишәр»(мещеряки), «мишәрдән башкорт»(мещеряки из башкир, башкирцы из мещеряков) дип күрсәткән.

Бәләбәй өязе Чокадытамак волостендагы Имән Күпер авылына да кагыла бу. Тарихи чыганакларда ул рәсми рәвештә авыл буларак 1895-нче елда телгә алына. Тарихчы Ә.Әсфәндияров күрсәтүенчә, нәкъ шушы вакытта биредә 70 йортта 466 кеше яшәве мәгълүм. Әмма, авыл байтак элегрәк барлыкка килгән. Аның оеша башлавы исә хәзерге Бүздәк районындагы Батырша Кобау авылы белән бәйле. Имән Күпер халкында сакланган риваятьләрдә авылга нигез салучыларның иң башлап нәкъ менә Батырша Кобауга күченүләре турында фаразлар сакланган. Хәзерге вакытта алар тарихи документлар нигезендә раслана. Батырша Кобау авылында 1834-нче елда үткәрелгән халык исәбе алу материалларында бу авылга 1829-нчы елда Пенза губернасы Краснослободский өязе Кагу-

шинская волосте Матвеево авылыннан «морзалардан булган йомышлы татарлар»дан 39 ир һәм 46 хатын-кызның күченеп килүе турында әйтелә. Күченеп килүчеләрнең һәммәсе дә «казенный поселенец»дип язылган. Димәк, алар дәүләт крестьяннары сословиясендә торган, шуңа да күченү дәүләт тарафыннан хөкүмәт исәбенә башкарылган.

Халык исәбен алу документында «казенный поселенец»лар арасында Чуракайдагы Солтановлар нәселенең вәкиле дә теркәлгән. Ул – морза, йомышлы татар Габделсәлим Әлимбәков, 1834-нче елда аңа 47 яшь була. Мәгълүматларда йорт хуҗасының әнисе 70 яшьлек Ханифә, хатыны 40 яшьлек Халимә дә урын алган, Габделсәлимнең улларыннан Сөләйман, Йосып, Кормый, Фәткулла теркәлгән.

Бу җәһәттән шуны да билгеләп үтик: Имән Күпер авылына нигез салучылар турындагы 1829–1870-нче еллардагы тарихи чыганакларны, мәсәлән, метрика кенәгәләрен – «Метрические книги Оренбургского магометанского духовного управления», Башкортстан Дәүләт тарих архивында фәкать Батырша Кобау авылына караган фондлардан гына табарга мөмкин.

Пенза губернасыннан килгән «казенный поселенец»лар рәсми теркәлү үтсә дә, Батырша Кобау халкы, җир биләмәләре азлыгын сәбәп итеп алып, аларны авылга кертмәгән. Риваятьләрдә мөһаҗирләрнең авыл эргәсендә землянкалар казып, анда ким дигәндә 30 ел дәвамында, ягъни, якынча бер буын, гомер кичерүе тасвирлана.

Әйткәндәй, Батырша Кобау авылында ул чорда яшәүчеләр арасында нәкъ менә Пенза губернасыннан элегрәк күченеп килүчеләрнең байтак булуы да тарихи чыганакларда теркәлгән. Бу урында татарның үз милләттәшләренә карата электән билгеле, әмма әһлакый кагыйдәләргә сыймаган тискәре мөнәсәбәтен билгеләргә мөмкин. Ләкин ул чорда Батырша Кобау халкының хәлен вә мохтаҗлыкларын да исәптән чыгарып булмый. Яшәү белән үлем арасы, кем әйтмешли, бер totам җиргә бәйле чор бит бу. Моңа өстәп, тарихи чыганаклардан ул чорда Батырша Кобауда халык исәбе материалларында башкортлар, типтәрләр, мишәрләрнең барысы бер мең кешедән артыграк булуы теркәлгән. Хәзерге вакытта «Кыдаш» хуҗалыгының Батырша Кобау төбәгендәге сөренте җирләр бер мең ярым гектар тирәсе тәшкил итә. Шуңа да җир бүлешү мәсьәләсендә нәтиҗәләр ясарга ашыкмау хәерле.

Авыл читендә гомер кичерү мөһаҗирләргә авырга туры килә, әлбәттә. Шуңа да морзаларның бер өлеше тамак ялына эшләп йөрүче батраклыкка басарга мәҗбүр була. Бу чорда, ягъни, XIX-нчы гасырның ахырында, Чокадытамак волостенда урыс җирбиләүчеләре бертуган Сафронов боярлар сабын заводлары корып җибәрә. Шуларның берсе Туймазы төбә-

генең хәзерге Алексеевское авылы тирәсендә урнашкан була. Сабынише әйберләр чыгаруда чимал сыйфатында утын көле дә кулланыла. Пензадан килүчеләрнең күпчелеге өчен Сафронов заводлары ихтыяҗларына көл җыю, бүгенгечә әйткәндә, яшәү чыганагына әверелә.

Риваятьләрдә Сафроновларның күченеп килүчеләрне кызганып аларга җир бирүләре турында әйтелә. Бу фикер белән килешергә мөмкин, чөнки завод тотучыларның төбәктә эшче куллар тупларга омтылышы табигый. Ничек кенә булмасын, яңа авылның барлыкка килүендә Сафроновларның да өлеше бар.

Авылның иң өлкән кешеләренең берсе Тәскирә Галиуллина (1920-нче елгы) истәлекләрендә күченеп килүчеләрнең беренче эш итеп бу төбәктәге елга аша имән агачларыннан күпер корулары турында әйтелә. Имән Күпер атамасының килеп чыгышы да шуңа бәйле. Авылның кайсы елларда барлыкка килүен ачыклаганда да истәлекләр ярдәмгә килә. Мәсәлән, туган тиешле Фәкинә (1938) һәм Риза (1932 елгы) Гыйбадуллиннар сөйләвенә караганда, күченеп килүчеләр хәзерге Имән Күпер нигезен корганда аларның кардәше Гыйбадулла 8 айлык сабый була. Авыл зиратында аның кабере табылды. Ташта Гыйбадулланың туган елы язылган – 1873-нче ел. Димәк, Имән Күпер тарихын шушы вакыттан башлый.

«Уфа губернасы Бәләбәй өязе буенча 1896-нчы елга статистика белешмәләре җыентыгы»нда Имән Күпер турында мондый мәгълүмат бирелә: Имән Күпер һәм Корган елгалары эргәсендәге калкулыкларда урнашкан, елгаларда су тегерменнәре корылган. «Уфа губернасы волостьлары һәм авылларының 1902 елга алфавит буенча исемлеге»: Имән Күпер – Чокадытамак волостенда яшәүчеләр: припущеник-дәүләт крестьяннары. Барлыгы 31 йорт-ихата, ир җенесеннән 212 кеше. Җирләре – 870 дисәтинә.

1906-нчы елгы статистика мәгълүматларында Имән Күпердә 70 йортта ирләрдән 236, хатын-кызлардан 230 кеше яшәве язылган. 1917 елгы «Авыл хуҗалыгы исәбен алуда» авылдагы 99 йортта 654 кеше теркәлгән, халыкның милләте татар итеп күрсәтелгән.

1929-нчы елда Имән Күпердә колхоз оештырыла, аңа «Кызыл маяк» дип исем бирелә. Әйтергә кирәк, сугыш алды елларында «Кызыл маяк» Туймазы районында гына түгел, СССР күләмендә дә танылу ала. Колхоз төзелешендә зур уңышлары өчен алдынгы хуҗалык Хезмәт Кызыл байрагы ордены белән бүләкләнә. Хәзерге вакытта Алексеевское авыл биләмәсе составындагы Имән Күпер пенсионерлар авылына әверелеп бара, биредә 120 кеше генә яши.

## Чокадыбаш Дилмөхәммәтовлары

1930-нчы елларда Әлшәйнең Чуракай авылына күченеп килүчеләр арасында Чокадыбаштан да бер төркем була. Чокады елгасының югары

агымында урнашкан бу авыл шулай ук Бәләбәй өязенең Кобау волостена карый. 1756-нчы елгы килешү буенча башкорт вотчинниклары авылга типтәр һәм ясаклы татарларны кертә. Авыл тиз арада үсә, 1895-нче елгы белешмәләр буенча биредә 1326 кеше яшәве билгеле. Төбәктә иң эре татар авылы саналган Чокадыбашта 1905-нче елга кадәр шул исемдәге волость идарәсе тора, авылда ике мәчет була.

Дилмөхәммәтовлар 1917-нче ел инкыйлабына кадәр авылда матди яктан иң бай һәм киң таралган кавем буларак билгеле була. Хуҗалыкларны күмәкләштерүдән качып, Дилмөхәтовларның берише, әйткәнебезчә, Әлшәй тарафларына юл алса, калганнары Туймазы районындагы башка авылларга, атап әйткәндә, Кәлшәлегә, Тукайга, Урман Астына, Миякә районының Илчегул авылына күченеп китә. Шуңа бәйле, хәзерге вакытта Чокадыбашта Дилмөхәммәтов фамилияле кешеләр юк.

1897-нче елда туган Фаризун Дилмөхәммәтов 1929-нчы елда хатыны Фәтхия белән югарыда телгә алынган Ярманчы авылына барып урнаша. 1930-нчы елның 2 февралендә кыз балалары туа, аңа Зәйтүнә дип исем кушалар. Аның туу турындагы таныклыгы Дәүләкән районының Чуенчы авыл Советының ЗАГС бүлегендә тутырылган, сабыйның туган урыны итеп Ярманчы күрсәтелә. Алгарак китеп шуны да әйтик: байтак гомер үтеп, Дилмөхәммәтовлар да Чуракайда төпләнгәч, Зәйтүнә Имән Күпердән килгән Солтановлардан Әмиргә кияүгә чыга.

Гомумән, бу ике гаиләне электән күп нәрсә бәйли, ни өчен дигәндә, Чокадыбаш белән Имән Күпер янәшәдә диярлек урнашкан авыллар. Моңа өстәп, Фаризунның хатыны Фәтхия Гыйләҗетдин кызы – нәсел чыгышы буенча Имән Күпер авылыннан.

Чокадытамак волостеның Чокадыбаш авылы мәчетендә 1897-нче елның 3 октябрендә теркәлгән «Метрика кенәгәсендә» Фаризунның атасы итеп типтәр Динмөхәммәт күрсәтелгән. Әмма урыс телендәге чыганакларда соңрак атасының исеме һәм фамилиясе Дилмөхәммәт итеп языла башлый. Чит-тарафларда эшлеклелек сыйфатлары белән Фаризун үзен тиз таныта, төбәктә колхоз оешкач, аны хуҗалык җитәкчесе итеп сайлап куялар. Сугыш башлану белән Фаризун үз теләге белән фронтка китә һәм хәбәрсез югала. Әйтергә кирәк, аның сугыштагы язмышы соңгы елларда гына ачыкланган. Атап әйткәндә, яугир 1942-нче елның августында ук хәбәрсез югалган булган икән.

Фәтхия һәм Фаризун Дилмөхәммәтовлар гаиләсендә 10 бала үсә, алардан хәзерге вакытта да Чуракайда гомер кичерүче Рәйсә генә исән, узган елның октябрендә ул балалары һәм оныклары белән 85 яшен билгеләде. Дилмөхәммәтовларның барысы да дип әйтерлек язмышларын туган авыллары саналган Чуракай белән бәйли. Зәйтүнә Фаризун кызы Солта-

нова турында язып үттек инде. 1928-нче елда туган Әнвәр Фаризун улы, мәсәлән, чирек гасыр дәвамында шушы төбәктә колхоз рәисе вазифасын башкара. Нур хуҗалыкта баш бухгалтер, икътисадчы була. Фәрит, Рәшит һәм Мөнәфирә дә тормышта бәхетләрен туган районнары чикләрендә таба. 1918-нче елгы Кафия белән 1937-нче елгы Канитә Бәләбәй районының Брик Алга авылында төпләнәләр. 1939-нчы елда туган Нәзирә укытучы һөнәре алып, Кушнарен авылы мәктәбендә озак еллар эшли. Җәмәгате, районның кулланучылар җәмгыяте ветераны Яуис Хәйруллин белән ике кыз – хәзерге чорда малтабарлар Динара белән Гөлнараны, тәрбияләп үстерәләр.

Дилмөхәммәтовлар нәселен барлаганда Фаризунның җәмәгате, 10 бала анасы Фәтхия Гыйләҗетдин кызының язмышына аерым тукталу таләп итеlә. Тормышында башлангыч белем белән генә чикләнсә дә, Чуракайда авылдашлар арасында гаделлеге, кешеләргә игътибарлы яхшы мөнәсәбәте белән зур абруй яулап, киң танылу ала ул. Атап әйткәндә, авыр хәлдә калган авылдашларын яклап, ул чорда КПССның Башкортстан өлкә комитеты беренче секретаре Зыя Нуриевка да мөрәҗәгать итә. Әлеге вакыйгадан соң, Фәтхия Дилмөхәммәтова карата ихтирамның янә дә артуы аңлашыладыр. Әйткәндәй, Фәтхия Гыйләҗетдин кызының тумышы белән Әлшәй районының Морзагул авылыннан булган, Башкортстанның күренекле дәүләт эшлеклесе Әхнәф Дилмөхәммәтов белән эшлекле мөнәсәбәттә торуы да мәгълүм. Фәтхиянең Зыя Нуриевның туганнары белән хат алышулары билгеле, кызканычка каршы, бу язмалар сакланмаган.

Солтановлар һәм Дилмөхәммәтовларның башкорт авылы Чуракайга күченеп, нигез яңартуына 99 еллап вакыт үткән. Бер гасырга якын дәвердә алар яшәештә югалмыйча, Чуракайда да якты эзләрен калдыра алган.

*Дамир Таҗи*

# КЫЯМ ҖӘГЪФӘРЕВ: АВТОБИОГРАФИК ИСТӘЛЕКЛӘР

*(Дәвамы. Башын карагыз: №2, 3, 4, 2018; 1, 2, 2019)*

## РАНГАЗАР ТАРИХЫНА БЕР КАРАШ

Рангазар сүзе шул җирләргә урыслар килеп, дәрья суларын, авылларны, җирләрне картага ала башлагач, урысларга ишетелү шәкеле булып, чын татарча яки башкортча әйткәндә Улан (Углан) Гадар авылы дип аталган. Рангазар халкы үзләрен «башкортлар» дип йөртсәләр дә, аларның чын мәгънәсендә кем икәнен аныклау кыен. Чөнки алар татарлар белән башкортлар арасындагы, татар дисәң татар түгел, башкорт дисәң башкорт түгел бер халыкка әйләнеп, ике халыкның да гореф гадәтләрен азмы-күпме үзләштереп, үзләренә генә хас шивәлдә сөйләшеп яшәп киләләр. Күрше авылларга караганда Рангазарның дала-басу җирләре бик иркен булып, кырлары тигез, таусыз-ташсыз, авыл хуҗалыгы өчен кулай җирләр. Рангазар авылы кайчандыр калын урманнарга бай булган диләр. Талип мулла килгәндә басуда бер агач та инде булмаган. Рангазар кырларының исемнәре бик матур, чын татарча булып, аларның кайчандыр исеменә җисеме мәвафыйк булганлыгын әйтеп тора. «Имәнлек алды», «Каенлы күл», «Тал куак», «Кәҗә куагы», «Зирекле күл», «Мүк күле», «Төпләү», «Җүкәле сыза», «Карт сызасы», «Күк тәкә», «Яссы болын» дигән исемнәр күп мәгънәгә ия. Авыл халкы эчендә бердәмлек, бер план, бер тәртипкә буйсынып эш күрү булмаганга күрә, Рангазар халкы азмы-күпме булган урманнарын, куакларын кисеп, төпләп ягып бетергәннәр. Чишмәләр, инешләр, сулыклар кибеп, кечерәеп бетүгә юл тотканнар. Электә тегермән, тула килесен йөргезгән су, соңгы елларда ерганакка гына ошап кала. Кырларда урманнар бетү белән, кыш көннәрендә кар туктамастан, аларны җилләр сөреп, куып алып китәләр һәм чокыр, сызаларга тутыра. Урманның, сулыкларның кадерен белмәгән халык иген кырларының да кадерен белми. Әллә ничә чакрымнарга сузылган иген җирләрен бик иске агач кораллар, агач сука, агач тешле тырма кебек әсбаплар белән эшкәртәләр. Шул сәбәпле иген кырларын сарут, чүп үләне басып китә. Рангазарда башка күрше авыллар кебек өч басу системасыннан файдаланганнар. Бөтен җирләр халык милке булып хисаплана. Җир, басу, болын мәсъәләләрен авылның халык җыенында тикшереп хәл иткәннәр. Унике елда бер мәртәбә барлык булган җирләрне ирләр санына карап җан башына бүләләр. Хатын-кызларга җир бирелми. Үлгән ир кешеләрнең җире яз башында яңа туган ир балаларга алып бирелә. Читтән килгән

кешеләргә, кем булуына карамастан, җир бирелми. Бу канунны муллалар да боза алмый. Иген чәчәр өчен алар да җирне сатып алырга мәҗбүр. Начар эш кораллары белән эшләү түбән уңыш алуга китергән. Гадәттә, алынган хасил Рангазар халкының ихтыяҗын капламый, еш кына ашарга-эчәргә дә җитми кала. Авылда 10 ел вакыт эчендә бер тапкыр ачлык, 3 тапкыр түбән хасил, 5 тапкыр урта хасил һәм 1 мәртәбә яхшы уңыш хасил булып килә. Халкының яртысы матди яктан фәкыйрьлектә яши, 15–20 % батраклардан гыйбарәт. Ирләр хисабына алганда, җан башына 7–8 га яхшы җир туры килгән булса да, җирдән туры файдаланышны белмәгәнлекләре өчен, бай авылда фәкыйрь гаилә булып яшиләр. Кайберләре аптыраганнан урыс авылларына барып мал көтүче булып яллана. Авылда революциягә кадәр һөнәрле кеше табуы кыен булган. Балта остасы, тимерче, пыяла куючы, итек тегүче, кием тегүче, ат печүче, хәтта сөннәт бабасы кебек кешеләр дә читтән килеп эшлиләр. Егерменче гасыр башларында Уралда, Донбасста сәнәгать җитештерү үсә башлагач, шул һәм башка якларга чыгу башлана. Ләкин бу да халыкның тормышын яхшырта алмый.

Рангазарда мулла-мәэзиннәр күп була. Шулай булса да, ике мәчетнең берсе агачтан булып, ул бик искергән, такта түбәләре тишелгән, манарасына азан әйтергә чыгарга куркыныч хәлдә була. Түбән очта бер бүлмәле таштан салынган икенче мәчет берничә сыер ябар өчен салынган малханәгә охшаган. Мәчет күл янына салынган булып, күл як нигезе начар, буш эшләнүе нәтиҗәсендә кыйшайган, аңа берничә җирдән терәүләр салынган хәлдә бик хәвефле, эченә керергә куркыныч була. Мәктәп яки мәдрәсә юк. Балаларны укыту Зәйнулла мулланың мал өендә, сарык бәрәннәре торлагында оештырыла. Яшь балалар сарык бәрәннәре арасында идәндә утырып, Рәфига абыстайдан дини догаларны, хикәяләрне өйрәнү өчен берничә еллар йөри торган булалар. Ләкин бу Рангазар «академиясен» бетергән кеше кулына дәфтәр, каләм тотмаган, хат язмаган, хисап-исәп чыгармаган, күбесе укырга да өйрәнә алмаган, чөнки Рафига абыстай үзе дә хат язуны белмәгән. Талип мулла Рангазарга килгән елларда халыкның 98 % надан булып, аларның рухларын агарту, аз гына булса да мәгърифәт бирү, мәдәният кертү мәсьәләләре турында уйлаган кеше булмый. Халык үтә киткән надан, садә, төрле хорафатларга тиз ышанучан, аракы һәм ачы бал эчәргә хирыс, бернинди бозыклыктан кайтмыйча кеше үтерү, юлаучыларны талау, ут төртеп яндыру гади эшләрдән саналган. Берәүнең малын кырдан алып кайтып, яки көтүдән адашып кереп калган күршеләр сарыгын, бозауны төннә суеп җыештыру көндәлек гадәткә кергән, тотылган кешегә бик каты җәза эләгүеннән дә курыкмаганнар.

Гомумән алганда, башкортларга хас булган җир сату мәсьәләсе Рангазар башкортларына да ияргән. Алар да үзләренең җан башына тигән җир өлешләрен бер көз, бер яз сатып акчасын эчә торган булалар. Кайбер елларда, кыш авыр килгән вакытларда көздә чәчеп калдырган уҗымнарын да сатып ашый яки эчә торганнары да була. Шундый хәлләрдән оста файдаланып авылның аңлырак һәм баерак кешеләре, мулла-мунтагайлары бик арзан хакка арышка, борчакка алмаштырып җир алалар. Ярлы гаиләләрнең җирләре бай кулына күчә килгән. Җир саткан көннәрендә эчеп исереп, урамда акырып-бакырып йөрү, ачулы кешенең йорт капкасына типкәләү, начар сүзләр әйтеп сүгү, кычкыру, үткән-барганнарга бәйләнү кебек ямьсез гадәтләр тамыр җәя (*искәрмә: автор коммунистик идеологиядән чыгып булса кирәк бу эшләрдә бөтен гаепне дин әһелләренең, байларның өстенә өя. Бигрәк тә эчүчелекнең таралуына әлеге катлам сыйныфы гаепле дип саный, дәлилләр китерә. Без бу өлешен төшереп калдырдык*).

Талип мулла Рангазарга килгән чорларда авылның беренче мәхәлләсендә имам булып хезмәт иткән Зәйнетдин мулла бик картаеп, билләре бөкерәеп, сакаллары агарып, сәламәтлеге начарланып, үзе нык борчылган, өшәнгән хәлдә, хуҗалыгының да көче киткән, фәкыйрьләнгән була. Талип мулла Зәйни хәзрәтнең шундый әхвалдә ятканын ишетеп, аның өенә бара, алар яхшы танышып алалар, карт мулла моңа бик сөенә. Чөнки Зәйни мулланың авылда голәма арасыннан бер генә дә дусты, мәслихәтчесе булмыйча аптырап яткан вакыты була. Ике арада дуслык урнаша. Талип мулла аңа ярдәм күрсәтә. Карт мулла Рангазар халкы турында һәм башыннан кичергән вакыйгаларны бәйнә-бәйнә сөйли.

1880–1890-нчы елларда рангазарлылар ике төркемгә бүленеп, зур көрәш, үзара тартышу һәм дошманлык белән яшәп киләләр. Моның асылы кабиләви, сыйнфый, феодал социал көрәшләрдән гыйбарәт. Югары оч төркемендә «Сарайлы түбә» авылыннан күчеп килгән халык – кабиләләрне берләштереп, боларның башында Зәйни мулланың ярдәмчесе, үтә киткән хәйләкәр, мәкерле Хәсән мулла тора. Икенче төркемгә авылның түбән оч халкы берләшеп, алар Кама буендагы «Салагыш» авылыннан күчеп килгән, «салагыш нәселе» оештырылып, аларның башында торучы җитәкчеләре Зәйни мулла. Ул чорда Рангазарда бер генә мәхәллә булып, мәхәлләнең баш имамы Зәйни хәзрәт булса да, Хәсән мулла Зәйнетдиннең ярдәмчесе генә булуына карамастан авылда, халык арасында көн дә булып тора торган үлем-җитем, исем кую, никах уку, туй, кыз бирү, килен алу мәҗлесләрендә дә төркеменә карап мулласы чакырыла, коръәне укытыла. Югары очта Хәсән мулла, түбән очта Зәйни мулла гореф-гадәтләрне башкара. Дини садакалар: гошер, фитыр, фидия, садака кебек керемнәр ике казнага яки ике кесәгә керә.

Зәйни хәзрәт 1845–1850 елларда Минзәлә төбәгендәге Карашай саклавы дигән авылдан Рангазарга мулла булып килә. Зәйни хәзрәтнең килеп чыгышы иске татар ханнары һәм морзалары токымыннан булып, аларның соңгы буыннары дини кәсепкә күчкән. Рангазарга килгәч тә Зәйни хәзрәт үзен бик эре тота, халык белән дә бик аралашмый. Яшь чагында гайрәтле, үзенә, эшенә бик ышанган кеше була. Авылда ярты гасыр дәвамында мулла булып яшәп, аерым елларда бик нык баеган, күрше авылларга чыккан вакытта куш ат яки өч ат җигеп йөргән. Хәтта Рангазардан сигез чакырымлы Карамал базарына чыкканда да көймәле арбага өч ат кушып, ат башына кучер утыртып базарга чаба торган гадәте булган. Ул кыңгыраулар тагып тройка белән үтеп киткәндә игенчеләр юл биреп, кул кауыштырып, иелеп, озатып калганнар. Ул авылга килгәч, аңа зур юл буеннан казлар утравы дигән, ике су килеп кушылган җирдә, бик куе таллар арасындагы өчпочмак хасил иткән матур җирне бирәләр. Бу югары оч мәчетенә якын, зур яшел мәйданда, табигатьнең матур почмагында Зәйни хәзрәт үзенчә хуҗалык корып җибәрә. Аны авылның ике зур урамы арасына халыктан аерып корган тимер түбәле зур агач өйләре, буялган киң урыс капкалары, агач складлары, лапаслары, сарайлары, абзарлары, утарлары помещик йортын хәтерләткән. Хәзрәткә чәчү җире бирелмәгән булса да, ул үз ихтыяры белән ярлы игенчеләрдән арзан хакка сатып алып, бик күп дисәтинәләр икмәк чәчә. Язгы һәм җәйге эш вакытларында 10–15 хезмәтче өзлексез эшли, утарларында малның, кәҗә-сарыкның саны билгеле булмый. Бер меңләп умарта баганасы торган чаклары булган. Язгы сукага чыкканда 12–15 сука бергә чыгара, 12–15 ат, 12–15 батрак сукадан кайтып кермиләр. Амбарлары һәр вакыт иген белән тулы, ындырда кибәннәр өзелми, хәтта 10–15 ел утырып калган кибәннәре сакланган. 10–12 кеше кыш буе ашлык сугып, амбарларга тутыра торалар, икенче яктан Зәйни мулла аларны икмәк сәүдәгәрләренә сатып акчасын алып тора. Бер ел эчендә ничә мең пот арыш, бодай, солы, арпа, борчак, карабодай сата. Зәйни курыкмас бер кеше булып, сөйләгәндә дә ашыкмыйча, әкерен генә, басынкы сөйләгән. Аның батыр ихтыярлы булуы Рангазарда икенче бер шундый ук кешенең максатларына каршы төшә. Ул Хәсән мулла һәм аның дусларына каршы көрәшергә мәҗбүр була.

Хәсән мулла Рангазарның беренче мулласы Сәгъди хәзрәтнең улы булып, шул авылда туып, шунда үскән төп халык вәкиле хисаплана. Патша әби Екатерина II идарә иткән соңгы елларда булса кирәк, татар авылларына мәчет салырга, манара чыгарырга рөхсәт бирелә. Рангазарга да мәчет салынып, Казан ягыннан Сәгъдине чакырып китергәннәр дип сөйлиләр. Биредә җир-су иркен булганлыктан аны җәмгыятьнең әгъзасы итеп алалар, җир-судан файдалану хокукы бирәләр. Сәгъди Бохарада укыган. Шул

сәбәпле аны «Бохари мулла» дип йөрткәннәр. Метрика дәфтәрләре чыга башлагач үзләренә Бохарин фамилиясе алганнар. Сәгъди мулла балалары һәм аларның кардәш ыруглары Рангазар авылының мәдәни учагын үз кулларында тотып килгәннәр. Читтән килгән кешеләрнең тәэсиренә халыкны бирмәскә, гомумән, читтән мулла да чакыртмаска, кирәк булганда үзләреннән чыккан кешеләрне мулла итәргә дигән сәясәтне яклаганнар. Башка төбәктән килгән мулла-мәэзин, сәүдәгәр, игенчеләрне авылга кертмәү, килгәнен дә тотмау, аларны биздерү, мөмкин булса халык көче белән кудыру, җир бирдертмәү, печәнлек бүлгәндә аларны кушмау кебек кара фикерләр белән эш күрәләр. Аларны килмешәкләр дип мыскыллыйлар. Бу очракта, «мулла мулланы сөймәс – халык берсен дә сөймәс», дигән халык мәкале искә төшә. Сәгъди мулла балалары, кардәшләре Рангазарда күп булып, соңгы елларда алардан таралган Рангазар «ак сөякләре» авылның барлык идарә һәм мәгъмури эшләрен үз кулларына алып, шул нәсел мәнфәгате файдасына эшләтеп киләләр. Сәгъди мулланың улы Хәсән мулла вазыйфасы ягыннан Зәйни хәзрәтнең ярдәмчесе генә булып саналса да аңа буйсынмый, үзенә башка бер юл тота һәм гомере буе шул Зәйни мулланы авылдан кудырып, аның урынына үзе баш мулла булып калу өчен көрәшә. Хәсән төркемендәге югары оч халкы, аның байлары Раббани хаҗи, Сирай хаҗи һәм аларның нәселдәшләре оешып, Зәйни мулланы авылдан качыру, туры килгәндә, аннан һәр төрле юллар белән үч алу өчен сүз беркетеп куялар. Зәйни мулла белән Хәсән мулла арасындагы көрәшләр, талаш-җәнҗаллар 25–30 елга сузылып, кайбер елларда авылдагы зур һәм аяныч вакыйгаларның килеп чыгуына сәбәпче була. Бу ике мулла мәчеткә килгән җирдә мөнбәр таяклары сынганчы яки ашка барган җирдә, түрдә утырган вакытта талашып китеп, табындагы майлы бәлешләрне читекләре белән изә-изә сугышкан чаклары була. Зәйни мулланың шәп итеп эшләгән каралтылары, калай түбәле нараттан салынган өйләре билгесез кешеләр тарафыннан берничә тапкыр ут төртеп нигезенә кадәр яндырыла. Шундый янгыннарның берсендә Зәйни мулланың бердәнбер улы Шәмсимөхәммәт, куркып акылдан яза һәм бөтен гомеренә тинтәк булып кала. Аны үсеп зурайгач та «тинтәк Шәмәй» дип йөртәләр. Зәйни карт дошманнарыннан үч алмастан картаеп үлеп китүне кичермәслек хата дип көн кичерә. Ул гына да түгел әле, Рангазар халкы сходка җыеп (авыл җыены) үлем түшәгендә яткан хәзрәтнең улы Шәмәйне Карашай Саклавына куып җибәрәләр. Җир-су бирмәү генә түгел, атасы үлгәнче үк авылдан сөрәләр.

«Ни чәчсәң шуны урырсың» дигәндәй, көзге караңгы төннәрнең берсендә Хәсән мулланы ниндидер билгесез кешеләр, аның төнлә тышка чыкканын көтеп торып, үзенең ишекалдындагы коесына башын түбән кара-

тып ташлыйлар. Җиз комганы, киеп чыккан башмакларын коесы янына матур итеп, тигезләп куйган көенчә калдыралар. Озак елларга сузылган фетнә Хәсән мулла өчен дә фаҗигале төгәлләнә. Становой пристав, урядниклар, табиблар алып киләләр. Ике көн мәетне саклаганнан соң күмәргә рөхсәт итәләр. Хәсән мулла балалары җинаятьчеләрне табу өчен зур акчалар сарыф итеп бик тырышсалар да нәтиҗәсе булмый. Вакыйга тора-бара озак елларга билгесезлек чоңгылына күмелеп кала.

Хәсән мулла урынына энесе Шәрәфетдин Бохаринны тәклиф итәләр. Бу мәсьәләдә авыл халкы икегә бүленә. Югары оч халкы Шәрәфи мулла кандидатурасына риза булып тамга җыялар, түбән оч халкы ул кандидатурага риза булмыйча, үзләренә яңа мәхәллә ачарга, яңа мулла алып килергә, хәзергә карт булса да Зәйни хәзрәт карамагында калырга риза булалар.

Талип мулла авылга килеп яши башлагач та бер фаҗига була. Сишәмбе көн Карамалы базарында агалы-энеле Галиулла белән Төхфәтулла Фәйзулиннар эчеп, исереп кайталар. Кечкенә «Мәкәй тыкырыгы» эчендәге Рангазар суына салынган күпер өстендә күршеләре Хәйрулланың базардан кайтканын көтеп торып көпә-көндез шул күпер өстендә башына казык белән сугып үтерәләр. Җинаятьчеләрне кулга алып гомерлеккә Сахалин утравына сөрәләр. Озак та үтми, Галиулласы шунда үлә. Төхфәтулласы шунда эшләп кала. Аңа авылда «Сахалин Төхфи» дип исем кушалар.

Талип мулла ишеткән һәм күргән вакыйгалардан чыгып, мондый көрәшләрнең һәр татар авылында кабатланып торганын, яшәеш көрәше булганын яхшы белгәнгә күрә үз тактикасына нигез сала. Ул күбрәк әхлакны савыктыру эшенә керешә.

## ШАТЛЫК БЕЛӘН ХӘСРӘТ БЕРГӘ ЙӨРИЛӘР

Яшь гаилә бер генә бүлмәле агач өйдә торалар. Өйнең эче дә бик гади, сәке, ипи сала торган олы мич, мич алды такталар белән бүленеп куелган, башка җиһазлары юк. Кыш көне шул өйдә абыстай кыз балалар да укыта. Суык көннәрдә сарык бәрәннәре дә шунда кунып чыга. Зур матур йортта иркенлектә яшәгән байбикәгә мондый шартларга күнегүе бик авыр була. Ике арадагы килешмәүчәнлекләр зурая гына бара. Талип крәстиян баласы, эштән һич курыкмый. Ул сыер саву, сарык бәрәннәрен карау, ипи салу, кер юуу, аш пешерү, мунча ягу, савыт-саба чистарту эшләре абыстай өстендә булырга тиеш дип исәпли. Җәй көннәрендә кырда чүп утарга, урак урырга, ашлык сугарга тормыш үзе таләп итә. Әнисе куенында эш эшләмичә иркәләнеп үскән Сәҗидә ханымга авыл хуҗалыгы хезмәтенә кереп китү өчен дәрманы җитми. Карт абыстай да кызын яклап ике арадагы мөнәсәбәтләрне бозып йөри. Өйдә тынычлык һәм хөрмәт

югала. Шулай да бер зур шатлык булып ала. 1900 елның 3 гыйнварендә мәхәббәт җимешләре – уллары туа. Берничә көннәр узып Саҗидә аякка баскач, Талип мулла Кармыштан сөекле анасын, туганнарын, Әхмәттән әбисе белән бабасын кунакка чакыртып зур бәбәй туе оештыра. Тайсуган мәдрәсәсендә укыган чагында вакытсыз мәрхүм булган дусты Кивам хәлфәне күмгәч әйткән нәзерен искә алып, ир балага якташ дустының исемен куштыра. Шәйхелислам хәзрәт баланың колагына өч мәртәбә «исемең Киваметдин булсын» дип пышылдый.

Туйлар да, суык көннәр дә үтеп китәләр. Егерменче гасыр башы, бигрәк тә яз айлары бик матур килә. Карлар эреп, сулар күңелле ташыйлар. Яңгырлар да вакытында явып тора. Рангазар суы да ташып, агып, язгы кыр эшләре башлана. Кырларда уҗымнар тигез, матур тишелеп чыга. Халыкның күңеле күтәрелә. Узган елгы икътисади авырлыклар халык һәм ил өстеннән бераз киткәнгә охшап кала. Талип быел да игенне күп чәчә. Табышка өмете ышанычлы. Ләкин аны башка мәсьәләр борчый. Рангазарга килгәндә авыл халкына дин, мәгърифәт таратырга вәгъдә биргән иде бит. Килгәненә ике ел үтеп бара. Авылда мәктәп тә, мәдрәсә дә юк, фәкать кыз балалар гына мулланың өендә Саҗидә абыстайдан дәрес тыңлыйлар. Шул хакта мәчеттә картлар белән киңәшләшә. Комиссия кору өчен шура сайлана, йорт башыннан бер сум акча туплап бу эшкә нигез салына. Ул 15 чакрым ераклыктагы бер урыс авылыннан 9 тәрәзәле, такта түбәле олы бер өйне сөйләшеп кайта һәм халыктан төзелгән комиссияне алып барып шул йортны сатып алалар. Аны мәчеттән ерак булмаган бер яшел чирәмгә китереп тә куялар. Инде авыл уртасындагы күлнең бер ягында, урам буенда таш мәчет, күлнең икенче читендә, ындырларга китә торган юл буенда бер зур бүлмәле мәдрәсә тора. Моңа яшь хәзрәт бик шатлана. Быел Рангазарның угыл балалары да урамда трай тибеп йөрмәстән, мәдрәсәдә укый башлаячаклар. Балаларга китап, дәфтәр куеп укырга, язарга кечкенә өстәлләр дә ясатыла. Әмма Талипның яшь бала булганнан бирле, өй эчендәге эшләр бөтенләй чыгырыннан чыгып китә. Саҗидә абыстай төс-башка матур гына булып, сүз мөгаләмәгә дә үткер, укымышлы. Төрле журнал-гәҗитләр укып хатын-кызның хокукы турында сүз алып бара. Рангазарда хулиган ирләр базар көннәрендә акылын югалтканча эчеп, каты исереп кайтып, усаллык белән хатын, бала-чаганы өйдән кыйнап куып чыгаручылар да очрый. Шундый вакытларда, алар балаларын күтәреп Саҗидә абыстайга йөгереп килә торган булалар. Мондый чакларда Саҗидә абыстай аларның мескен хатыннарын балалары белән өйгә алып кереп, тынычлатып, ашатып, эчертеп, бәгъзе чакларда йоклатып, төн кундырып чыгара. Исерек ирләре килеп җәнҗал кылганда куркып тормастан араларына кереп сүгеп, куып җибәрә яки тәүбә

кылдыра. Рангазарга килеп ике ел торган дәвер эчендә Саҗидә абыстай бигрәк тә хатын-кызлар арасында үзен яхшы ягы белән таныта. Аңа гадел, шәфкатьле хатын итеп карыйлар.

Ярылган ярыкны иске хәленә китереп булмаган кебек мулла гаиләсендә тынычлык урнаша алмый. Моңа еш кына Саҗидә абыстайның әнисе сәбәпче. Ул морза нәселеннән булган кызының һәр төрле физик эшләрдә катнашуын, бигерәк тә кыр хезмәтәнә баруын кичерә алмый. Ә кияү хатынының кыр эшләреннән читләшүен зур кимчелек дип таный.

Җәйге дала эшләренең кайнап торган бер чагы. Халык карты-яше, ире-хатыны тирләп-пешеп арыш урагын урып яталар, эшкә ярарлык һич бер кеше калмаган. Халык әйткәнчә «көне – ел туйдыра» торган айлар. Талип мулла эшкә киткәндә абыстайга күп кенә эшләр тапшырып киткән була. Менә мулла ат-арбада үзенең сәфәреннән кайтып керә. Аңа капка ачучы юк, өйдән каршы алырга чыгучы да күренми. Ул атын да тугармастан кулындагы чыбыркысын куймастан бөтен ишек алдын әйләнә. Бөтен җир ачык, төрле нәрсәләр тәртипсез чәчелеп ята. Ул йөгереп өйгә керә. Һәммә җирдә тынлык. Саҗидә юк. Шулай аптырап торганда Саҗидә абыстай кечкенә Кивамны күтәреп күрше Таифә карчыклар капкасыннан килеп чыга. Мулла күңелендә булган бөтен үпкәләрне ачып сала. Саҗидә абыстай да үз тормышыннан риза булмыйча каты сүзләр әйтә. Талип мулла түзеп тора алмый, өч мәртәбә миңа мондый хатын кирәк түгел дип «талак», – дип кычкыра. Талип хәзрәт Югары Әхмәттәге бабасы Шәйхелислам хәзрәткә хат язып кызлары Саҗидәне алып китүләрен сорый. Хатны алу белән үк хәзрәт һәм карт абыстай ашыгып, гаять дәрәҗәдә гаҗәпләнеп, Рангазарга килеп җитәләр. Алар килгәндә ир-хатын уртасындагы аерылу фаҗигасы Ислам дине кагыйдәләренә бинаән эшне бетереп, кайтадан ябышмаслык итеп рәсмиләштерелеп куелган була. Шәйхелислам хәзрәт белән карт абыстай эшнең бик тирәнгә киткәнен күргәч, кызлары Саҗидәне улы Киваметдин белән Әхмәткә алып китәләр. Талип мулла бердәнбер улын Кивамны җибәрәсе килми, анасы ярдәмендә тәрбия кылырга сорый. Саҗидә баланы калдырып китәргә һич риза булмый. «Мин сиңа баланың йөзен дә күрсәтмәячәкмен», – дип елый. Шулай итеп кыска вакыт эчендә Саҗидә абыстай Әхмәттән алып килгән бөтен нәрсәләрен җыештырып, атны арбага кушып, йорт җиһазларын, түшәк – ястыкларын арбага йөкләп, сарыкларны тагып, ике арба булып, арттагы ата-анлары килгән арбага бергә утырып, кулга кечкенә Киваметдинне алып, кичкырын Әхмәткә таба карап чыгып чабалар. Саҗидә абыстай өзгәләнеп елап бара. Талип хәзрәт исә, карт хәзрәт белән хәерләшеп, шундый кыска вакыт эчендә булган, акылга сыймаслык дәһшәтле хәдисәгә үзе дә хәйран калып, күзләренә ихтыярсыз килгән күз яшьләрен

кульяулыгы белән сөртеп, урам капка баганасына сөялгән хәлдә, аларның киткән юлларына карап, моңаеп озатып кала.

## ДУСЛАР КИҢӘШ БИРӘ

Хатын юк, кулдан эш тә китә. Әллә муллалыкны ташларга микән? Томск шәһәрендәге туганнан туган кардәше сәүдәгәр Гайфулла Гобәйдуллинга хат язып, аның янына бөтенләйгә күчеп барып сату-алу итәргәме? Кем туры мәслихәт бирер икән? Шундый уйлар белән башы каткан мулла беренче нәүбәттә Кармышка барып газиз әнисен алып килергә уйлый. Әмма Кармышка барырга ат та калмады. Ике аттан берсе юк. Берсен кышта кемнәрдер суеп ашадылар, икенчесен Әхмәтнекеләр алып китте. Ул үзе йоклый торган кечкенә тимер караватка утырып, йөзен кыйблага каршы юнәлдереп, нечкәргән күңеленнән Коръәндәге «хәзрәти Йосыф» сүрәсенең башыннан төшеп, моңлы Тайсуган мәкаме белән кычкырып укып җибәрә. Бүлмә артында муллага чәй әзерләп бирергә кергән күрше Латыйфа карчык савыт-сабаларны шалтыратудан туктап тынып кала. Талип мулла сүрәне аерым бер ләззәт һәм ялвару белән укый. Тыңлаган кешегә сүрә моңлы да, кызганыч та булып ишетелә. Соңыннан кулын югары күтәреп ходайга дога кыла да, күз яшьләрен сөртә. Күңеле тынычланып калгандай була.

Элек фатирында торган Габделфәттахның атын сорап алып Кәтәш-Каран авылында мулла булып хезмәт иткән, бергә укыган дусты Яхья хәзрәткә бара. Яхья Талип мулладан бер-ике ел гына алдан шунда килеп муллалык вазыйфасына керешкән. Ул яшь ягыннан Талиптан олырак. Тайсуган мәдрәсәсендә Кивам хәлфә коега төшеп үлгәннән соң, бераз вакытлар Талип шәкертнең хәлфәсе булып торды. Яхья мулла «Озын Кәшер» яки «Яңа Кәшер» авылында игенче гаиләсендә туып, үзенең тырышлыгы белән укып, хәлфә булып Тайсуган мәдрәсәсендә озак еллар мөгаллимлек итә, картая башлагач кына Каран авылына килә. Ул Зәй буендагы Мактама Тамак (Түбән Матама) авылындагы Вәгыйз хаҗиның беренче олы кызына өйләнгән һәм Тайсуган Таһир хәзрәт белән якын баҗалар. Ике дус чәй өстәле янында киләчәк хакында бик озак гапләшәләр. Шәйхелислам хәзрәтнең гаиләсендә үзгәрешләр көтелә икән. Саҗидә абыстайны Янурыс авылының Төркиядә укып кайткан Харис муллага кияүгә бирәчәкләр имеш. Харисны Югары Әхмәткә Шәйхелислам ахунның ярдәмчесе, алмаш мулла итеп алалар икән. Бу эшләрнең башында Теләнче-Тамак байларыннан Шакир Хәлфин тора. Шакир Хәлфин Мәккәгә хаҗга барган вакытта Харисны үзе белән алып, Истанбулда укырга калдырып кайткан. Ул анда берничә еллар укып, тәмам кылып ватанына кайтып килә икән. Бу хәбәрләр Талип мулла өчен әһәмиятле, чөнки Саҗидә абыстай һәм улы Киваметдиннәрнең тәкъдире турында сүз бара.

Саҗидәнең яңа никахы Талипның эчен ул кадәр көйдермәсә дә, аның яңа урынга барып урнашкач, кечкенә сабый Кивамның да тормышы үзгәрәчәге, аның ул җирдә артык булуы, шул мөнәсәбәт белән бәлки баланы үзенә кайтарып алу мөмкин булыр дигән фикер туа. Ул улын бик сагына. Әллә Әхмәткә барып, тимерче Хәйдәрга атларны дагалату сылтавы белән кереп, Хәйдәр картның карчыгы аркылы Кивамны шунда китертеп күрү яки бөтенләй алып китү теләге барлыгын сөйли. Яхья аны сабыр итәргә өнди, бары да үзеңә кайтачак, әлегә әниеңне ятим калган йортка алып килеп эшләреңне бераз җайласаң дөрес булыр дип киңәш итә, Яхшыбайга Мортаза хаҗига сугылырга да куша. «Яңа гаилә кору мәсьәләсендә дә юл бар. Әнә Мактамада өченче балдызының үсеп буйга җиткәнен әйтә. Ул да булмаса Мактама Фазылның ике сеңелесе бик гүзәл, бик матур булып җиткәннәр. Бу хакта Кармышка барышлый яки кайтышлый, әйләнчерәк юл булса да, Тайсуганга кереп Таһир мәхзүмгә кереп чыгуың зарар итмәс. Таһир хәзрәт аларны ике сөйләтми күндерәчәк. Бу яктагы Минзәлә, Игәнә, Мәллә, Ык буе кызлары да, гореф гадәтләре дә, сезгә ошамаган кебек, миңа да ошамый. Үзем әле Зәй буйларына бөтенләй күчеп кайтырга уйлыйм. Сез Рангазар башкортларыннан туйган кебек, мин дә үтә усал бу Каран башкортларыннан бик нык туйдым. Миңа үзебезнең Кәшер, Нәдер, Мактама, Әлмәт, Тайсуган яклары күңелгә якын, аларның садәләгeн, саф динле булуын монда килгәч белдем. Без сезнең белән 15–20 ел Тайсуган авылында яшәп, халык эчендә исереп, кычкырып йөргән кешене очратмадык. Шулай ук Сабантуйлары, Ураза, Корбан гаетләрендә дә аерым тәртипсезлекләр, сүгенүләр, кеше үтерү кебек вакыйгалар күрмәдек. Монда һәр бәйрәмдә кемдер кыйнала...»

Талип Яхшыбай Мортаза хаҗи Мусиннар капкасына барып тукталганда кояш яхшы ук түбән төшеп кич якынлашып килә, хуҗаларның эте бик яман кычкырып аны каршы ала. Эт тавышына карт хезмәтче ашыгып килеп капканы ача, кунакның атын – арбасын эчкәрегә алып керә. Хаҗи абзый әле генә ике катлы биек мәчеткә икенде намазына киткән. Талип хәзрәт тә ат тугарылганны да көтмәстән кулына комган алып намазга хәзерләнә. Ул капкадан чыкканда мәчет манарасыннан калын аваз белән Габдерәхим мәэзиннең азан әйтүе авыл өстенә тарала. Талип җәмәгать намазына соңга калмавына сөенеп мәчеткә керә. Алар хаҗи белән икенде һәм ахшам намазларын бергә укып караңгы төшкәч кенә кайталар. Кичке аш янында Талип үзе белән булган бөтен маҗараларны сөйләп бирә. Талип мулла сөхбәт өстендә Саҗидә ханым белән булган күңелсез вакыйгаларда үзенең гаепсез икәнлегенә һәм гаепнең зурысы Әхмәтләрдән үткәнлегенә карт хаҗины ышандыра, бу эштә аның да ризалыгын ала. Мулла Яхья белән булган киңәшләрне үтеп, хаҗиның фикерләрен һәм

мәслихәтләрен ишетәсе килеп туры Яхшыбайга карап чапканын аңлата. Мортаза хаҗи үзенең соңгы елларда күңеле тыныч булмаганлыгын, картайганлыгын, хуҗалык эшләренең зурайганлыгын, вакыт җитмәгәнлеген, дөнья малына кызыгып ахирәт өчен тиешле әһәмият бирә алмаганын, күп намазлар калдырып, күп гөнаһлы булуларын сөйләп, зарланып күңелен бушата. Тегермәннәргә, хуторларга, урманнарга, базардан-базарларга, икмәк амбарларына, тире складларына, Казанга, Мәскәүләргә йөреп бик ватылганын, арка сөякләре сызлауын сөйләп: – Әй хода! Ничә яхшы атлар аяксыз калды, ничә арбалар, тимер тарантаслар сынып, югалып китте, ә мин, Аллага шөкер, бүгенге көнгә кадәр чыдап киләм. «Адәм җаны – эт җаны» диләр, дөрестер ул мөгаен. Үзем салдырган таш мәчеткә барып, ходага егылып сәҗдә кылып, башымны намазлыктан алмый гыйбадәт кыла торган вакытым бик җиткән! Ни хәл итәсең? Эшләр без дигәнчә бармый шул. Әнә бөтен эшләрне Гыйльфанга тапшырырга кирәк иде. Әле ул күңелен биреп, эшкә җиң сызганып, кызыгып керешкәне юк. Әллә инде бер булдыксыз, кабилиятсез бала булырмы? Эшкә кулы ябышмый. Мин кушканны көтеп тора, кушкан эшне мин дигәнчә үтәми, гел мине борчуга сала. Ачулансаң, кимчелекләрен әйтсәң зур итеп үпкәли, атналар буе сөйләшмәстән йөри башлый. Шулай инде ул тормыш, мулла Талип! Бу дөньяда беркемнең дә сарае буш түгел. Синең үзеңнең хәсрәтең булса, менә минеке аннан да ашып киткән, нишләргә дип аптырап торам. Боларны сиңа сер итеп кенә сөйлим. Улымның хәлфәсе идегез бит. Бәлки аны үгетләп акылга кертерсез, сезнең нәсихәтләргә колак салмый калмас әле. Сез аңа яхшы тәрбия бирмәгәнсез дип тә әйтмим. Сезгә дә, хәзрәткә дә һич үпкәм юк. «Ана сөте белән кермәгән – тана сөте белән кермәс» шул. Авызында папирос, базарда сыра эчкәнен күргәннәрен килеп колакка пышылдыйлар. Эч пошырырга җитә бит бу! Минем күзләрем йомылу белән бөтен гомерем буе тапкан сәрмаяларымның көлен күккә очырып җибәрмәсә ярар иде дип куркам. Бүгенге көндә бөтен хуҗалыкны Хәеретдин мишәр белән Иван керәшен алып баралар. Аннан соң авырткан башка тукмак дигәндәй, Минзәләбашының теге кызыл авыз, күпкән корсак Камил мулла, шул авылның крәстияннарын миңа каршы котыртып ята икән. Кичә базарда шул хакта Ләшәү–Тамак авылы Нурулла мулла сөйләп бирде. Мин андагы тәртипсезлекләргә, чыккан янгыннарның сәбәбенә төшенмәстән йөргәнмен икән. Бу социалист, иблис баласы, аны миңа каршы, әкерен генә котыртып җибәрә икән. Әгәр дә урыс крәстияннары булса, тагын бер хәл иде, болар үзебезнең мөселманнар бит, ничек алар ходайдан курыкмыйлар? Камил мулла ике яклы фин хәнҗәре кебек. Миңа очраганда арбамның күчәр башын үбәргә, башын түбән иеп сәҗдә кылырга әзер. Мин юк та әнә нәрсәләр эшләп йөри икән.

Бу чаклы риялы, ике йөзле кеше булырмы? Әгәр син социалист икәнсең, нигә калдык ашап, михраб пычыратып йөрисең? Социалист булсаң үз юлыңда бул. Нигә халыкларның башын әйләндереп, ходa, пәйгамбәр исеменнә вәгазьләр сөйләп йөрисең. Мин Камил мулла белән Шакирҗан Хәмидиләрне үз карамагыма, үз тәрбиямә алып, кулымннан килгәнчә ярдәмнәр күрсәттем...

Бу сүзләрне зур игътибар белән тыңлап торган мулла, хаҗиның йөрәгендә ниләр ятканын төшенеп, аңа чын күңелдән кулыннан килгән ярдәмнәрне аямаска вәгъдә бирә. Шулай сөйләшеп утырып җәйге кыска төн узып, тәрәздән әтәчләрнең таң атуын хәбәр итеп кычкырулары, ике дусны сәгатькә карарга мәҗбүр итә.

*(Дәвамы бар)*

*Томас Нигаматзянов*

## КЛУБ СЕМИ МУЗ

Задолго до краха СССР, мы жили в стране, которая была крупнейшей державой и обладала великой идеологией, направленной на всестороннее развитие личности и социально-экономическую защиту человека труда. Огромной ценностью тогда было всеобъемлющее внимание к воспитанию молодежи – функционировали подростковые и молодежные клубы по интересам.

Так вот, в 1977 г. я стал инициатором создания клуба по интересам и в течение целых десяти лет, вплоть до 1987 г., ежегодно избирался президентом прославившегося в Казани «Клуба семи муз», представлявшего из себя молодежное общество любителей истории, литературы и искусства (находился в культурно-спортивном комплексе Советского района). Наш клуб, руководящим органом которого был совет из 20 человек, сочетал в своей работе различные формы: это диспуты и выступления участников заседаний на интересующиеся нас темы, встречи с известными деятелями науки и культуры. «Никаких посиделок! За активный диалог, диспут!» – таковы были основные принципы этого славного клуба.

Задача нашего клуба состояла в том, чтобы дискусировать о художественных богатствах, воспитывать хороший вкус, заниматься эстетическим самообразованием и воспитанием молодёжи. Это было отражено в программе и уставе «Клуба семи муз».

Традиционные заседания проводились в Красном уголке общежития молодых специалистов Государственного института прикладной оптики (ГИПО), где помещалось 100 человек, он всегда был битком набит участниками творческого вечера. Как правило, завершались клубные вечера танцевальной дискотекой. За 10 лет существования клуба на столах ни разу не появилось спиртное – только чай с шоколадными конфетами и печеньем. И наш неиссякаемый энтузиазм поддерживали руководство, партком, комитет ВЛКСМ, профком ГИПО, районный комитет и Обком ВЛКСМ. Потому что наша деятельность отвечала принципам тогдашней идеологии советского государства – культ труда, патриотизма и духовного развития. Что примечательно, райком комсомола Советского района г. Казани возглавлял тогда Камиль Исхаков, будущий мэр столицы Татарстана.

Интересы членов клуба были очень широки. Это поэзия и проза, фотоискусство и живопись, классическая музыка и джаз, археология и

история, театр и кино, спорт и туризм… Организаторы клуба с помощью красочно оформленных плакатов, соответствующей музыки и гостеприимства стремились создавать на этих вечерах атмосферу, способствующую непринуждённому общению. Как правило, вечера завершались дискотекой. Молодёжь, пришедшая к нам после напряжённого трудового дня, уходила из клуба прекрасно отдохнув, получив заряд положительных эмоций и новых идей.

У клуба имелись свои альбомы. Впрочем, они до сих пор сохранены. В них запечатлена история. По очеркам, заметкам, фотографиям можно узнать о каждом вечере.

***Встречи с именитыми гостями клуба – известными деятелями науки и культуры:***

***Дедюхин Е.Ф.*** – первый заместитель генерального директора НПО ГИПО, заслуженный машиностроитель Российской Федерации (поделился впечатлениями о своей поездке в США);

***Рафаэль Мустафин*** – писатель, литературовед, автор книги «Образ времени», член Союза писателей Татарии, заслуженный работник культуры Татарской АССР, лауреат Государственной премии РТ им. Габдуллы Тукая;

***Нигмедзянов М.Н*** – музыковед, заслуженный деятель искусств РТ, лауреат Государственной премии им. Габдуллы Тукая, профессор Казанского педагогического университета;

***Халиков Н.А*** – этнолог, кандидат исторических наук, лауреат Государственной премии РТ в области науки и техники, старший научный сотрудник ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФ АН СССР;

***Хисамов Н.Ш*** – литератор, член Союза писателей СССР, доктор филологических наук, автор книги «Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул Али», заслуженный деятель науки РТ, действительный член Международной тюркской академии (с 2001 – директор ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова);

***Фахрутдинов Р.Г.*** – археолог, доктор исторических наук, автор книги «Очерки по истории Волжской Булгарии», заслуженный деятель науки РТ, лауреат государственной премии РТ в области науки и техники;

***Исхаков Д.М.*** – этнограф, историк, автор книги «Проблемы становления и трансформации татарской нации», доктор исторических наук, лауреат Государственной премии РТ в области науки и техники, заведующий отделом этнографии ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, позже – главный научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани АН РТ, член национального совета «Милли шура ВКТ» (с 2018 – главный редактор журнала «Туган җир. Родной край»);

***Николаев Г.М*** – автор книги «Садык – значит друг», доктор медицинских наук, профессор, заведующий кафедрой травматологии, ортопедии и военно-полевой хирургии КГМИ им. С.В. Курашова;

***Сатонина Г.И.*** – художник и шахматист 1 разряда, 12-кратная чемпионка Республики, член шахматной федерации Татарстана, судья Республиканской категории по шахматам;

***Усманов М.А.*** – историк, автор книги «Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв.», доктор исторических наук, заслуженный деятель науки Татарской АССР, профессор, заведующий кафедрой истории татарского народа, проректор КГУ, позже – академик АН РТ;

***Халиков А.Х.*** – археолог, автор книги «Происхождение татарского народа», доктор исторических наук, заведующий отделом археологии и этнографии ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, профессор КГУ, член-корреспондент АН РТ, заслуженный деятель науки Татарской АССР, лауреат Государственной премии РТ в области науки и техники;

***Ландо Б.Х.*** – мастер спорта, кандидат технических наук, доцент КАИ, руководитель сборной Татарской АССР по туризму;

***Марат Тазетдинов*** – директор Татарской государственной филармонии, казанский бард, заслуженный деятель культуры РСФСР;

***Владимир Муравьёв*** – казанский бард и медик, доктор медицинских наук, профессор КГМИ, заслуженный врач РФ и Республики Татарстан, заведующий эндоскопическим отделением Республиканского клинического онкологического диспансера;

***Бронштейн В.С.*** – заместитель главного редактора журнала «Чаян»;

***Марсель Салимжанов*** – главный режиссёр Татарского государственного академического театра им. Г. Камала, народный артист РСФСР и СССР, заслуженный деятель искусств ТАССР и РСФСР, лауреат государственной премии им. Г. Тукая и Государственной премии РСФСР им. К.С. Станиславского, почетный член Академии наук Татарстана;

***Шаукат Биктимиров*** – ведущий актёр Татарского государственного академического театра им. Г. Камала, народный артист РСФСР и СССР, заслуженный артист Татарской АССР, лауреат государственной премии им. Г. Тукая и Государственной премии РСФСР им. К.С. Станиславского;

***Аяз Гилязев*** – писатель, автор книги «Мең чакырым юл», народный писатель Республики Татарстан, заслуженный деятель искусств ТАССР и РСФСР, лауреат Государственной премии им. Г. Тукая и Государственной премии им. М. Горького;

***Закиев М.З.*** – языковед, автор книги «Проблемы языка и происхождения волжских татар», действительный член Академии наук Республики Татарстан, доктор филологических наук, профессор, заведующий отде-

лом лексикологии и диалектологии ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, затем его директор (в 1980–1990 гг. Председатель Верховного Совета Татарской АССР);

***Тухватуллин Х. К.*** – старый большевик-ленинец, участник революционных событий в Смольном, комиссар отряда чапаевской дивизии, сын основателя, редактора и издателя первых татарских журналов и газет, а также драматурга и певца Камиля Мутыгулловича Тухватуллина;

***Дефак Рахмати*** – художник, историк-эзотерик, автор книги «Дети Атлантиды (очерки по истории тюрков)»;

***Аристов В. В.*** – книговед и краевед, автор книги «Казанские находки», заведующий отделом редких книг и рукописей Научной библиотеки им. Н. И. Лобачевского КГУ, заслуженный работник культуры Татарской АССР;

***Геннадий Пронин*** – директор музея и друг детства художника Константина Васильева;

***Яо М. К.*** – искусствовед, доцент Казанского института культуры и искусств;

***Галеев Б. М.*** – руководитель НИИ экспериментальной эстетики «Прометей», доктор философских наук, профессор КАИ им. А. Н. Туполева.

***Наиболее яркие диспуты:***

«Субъективна или объективна красота?»;

«Облагораживает ли искусство человека?»;

«Существует ли прогресс в искусстве?»;

«Кто они – татары астраханские, башкирские, казанские, крымские, сибирские и мишари?»;

«Волжские булгары – предки казанских татар или чувашей?»;

«Происхождение татар Среднего Поволжья»;

«Родина – твой язык, твой народ»;

«Истоки татарской литературы»;

«Советская самодеятельная песня»;

«Творчество художника Константина Васильева». «Что я думаю о живописи»;

«Татарский музыкальный фольклор»;

Диспут по книгам В. Чивилихина «Память» и Л. Гумилева «Поиски вымышленного царства».

***Другие наиболее интересные темы заседаний и встречи клуба:***

Татарские народные песни (исполнительница студентка Казанского медицинского училища Луиза Нуруллина);

Музыка Баха (диск-жокей Владимир Мазалов);

Ансамбль «Пинк Флойд» (диск-жокей Виктор Широков);
Джаз-рок (диск-жокей Александр Савельев);
Классическая гитара (исполнитель Николай Искачкин);
Древнерусское изобразительное искусство (ведущая Надежда Зверева);
Встреча с казанским клубом спелеологов;
Встреча с республиканским клубом кинолюбителей «Феникс»;
Вечер русского романса (ведущий Владимир Макаров);
Творчество народного художника СССР Александра Шилова (ведущий Юрий Пряхин);
Встреча с художником Ю. А. Пряхиным;
Встреча с художником, журналистом и поэтом С. А. Карпенко;
Вечер поэзии (поэты В. Б. Перель, В. Г. Игнатович, Лариса Циглер, Ирина Изотова);
Выездное заседание клуба – организация и участие в соревнованиях по спортивному ориентированию на базе отдыха «Волна» (в лесу – на левом берегу Волги);
Встреча с казанским клубом «Эсперанто»;
Встреча с клубом самодеятельной песни Казанского государственного университета им. В. И. Ульянова-Ленина;
Встреча с филокартистом А. А. Григорьевым;
Индия в слайдах и действительности;
Поэзия Николая Рубцова;
Изобразительное искусство русских художников-передвижников;
Эстрадная гитара (исполнительница Татьяна Ерёмина);
Восточная лирика;
Творчество польского композитора Чеслава Немана;
Творчество французского композитора Гектора Берлиоза;
Поэзия Николая Спорника;
Декадентство в русской поэзии (ведущая Татьяна Юдина);
Путешествие в Забайкалье (ведущий Александр Берденников);
Искусство первобытно – общинного строя (ведущий художник Сергей Карпенко);
История развития искусства танца (ведущая – танцовщица Вера Фадеева);
Музыка позднего Ренессанса и раннего барокко (диск-жокей Владимир Мазалов);
Встреча с клубом аквалангистов «Поиск» Казанского государственного медицинского института им. С. В. Курашова;
Встреча с казанским клубом парашютистов;

Выездное заседание клуба – участие в соревнованиях по спортивному ориентированию (в лесу – на правом берегу Волги) и вечер памяти Владимира Высоцкого (вокруг ночного костра);

Встреча с кандидатом в мастера спорта по водному туризму В.М. Голевым;

Встреча с исполнителями старинных русских романсов клуба «Встреча» завода КОМЗ (ведущая Элла Смолякова);

Выездное заседание клуба в светомузыкальной студии СКБ «Прометей» (ведущий Булат Галеев).

Известные деятели науки и культуры, как правило, приглашались в «Клуб семи муз» на диспуты для обсуждения проблем, отражённых в только что увидевших свет книгах именитых гостей. Скажем:

***Рафаэль Мустафин. «Образ времени». (Казань, 1981)***

В рассматриваемой книге убедительно раскрывается незаурядный талант просветителя и литературного критика Рафаэля Мустафина. Бесценны в ней «Страницы истории» о Л.Н. Гумилеве (авторе «Древних тюрков»), великом татарском поэте-гуманисте Мухаммедьяре (середина XVI в.), об истории татарского письма, рукописной и печатной книги (первый исследователь – А.Г. Каримуллин), ученом Шигабутдине Марджани, выдающемся татарском просветителе Каюме Насыри. Представляет глубокий интерес и критический анализ («Литературные портреты и эскизы») известных татарских писателей и поэтов – современников Р. Мустафина.

Любопытны переводы Р. Мустафина стихов Мухаммедьяра на русский язык.

А вот как выглядит мой перевод двустишия великого поэта, в котором Мухаммедьяр гуманизм высветил как свое жизненное кредо:

> «Аллах! В стихах моих лик светлый мой отобрази,
> В народ войти приветливою лирой помоги!»

Рафаэль Мустафин был гостем «Клуба семи муз» 18 декабря 1981 г. Тогда я писал о нем в институтской газете «Луч»:

«Рафаэль Ахметович – страстный литературный борец за национальную гордость, ярый противник национального чванства и национального эгоизма. Он – за любовь к своей Родине, народу, родному языку. Его критические работы преследуют именно эту благовидную цель. Книги Р. Мустафина о бессмертном Джалиле, «великом борце за свободу и социализм», написаны на той же «палитре» идей, теми же яркими, выразительными красками.

Рафаэль Ахметович оказался обаятельной личностью. Этот энергичный, увлеченный человек в откровенной беседе, не избегая проблемных и острых вопросов, поведал нам много полезного. Мы узнали о новых, еще неопубликованных фактах судьбы Мусы Джалиля, которые он добыл в своих поездках по ГДР, Италии, Турции».

***Аяз Гилязев. «Мең чакырым юл» (Тысячекилометровый путь»). (Казань, 1978).***

Аяз Гилязев – современный классик татарской литературы. Длинная повесть «Тысячекилометровый путь» – самое популярное произведение автора. Это трогательный рассказ о ершистом человеке – капризной судьбе заурядного деревенского мальчишки Аскара с честолюбивым характером. Аскар Моратов прожил беспокойную, тревожную жизнь и в 60 лет ослеп от глаукомы. В детстве его отец запрограммировал, что когда он вырастет, станет ученым. Вот с этой сокровенной мыслью он носился по многострадальной жизни, как солдат со знаменем полка на поле боя. Да, в конце концов, он защитил кандидатскую диссертацию. Но наука не его стезя: Аскар был бледной овцой в стае волков. Только дикое честолюбие и завистливость заставляли его быть упертым и трудиться денно и нощно на поприще псевдонаучного творчества. Слишком высокую планку он поставил для своей жизненной цели: сам мучился и других мучил. Свое собственное «я» в научной оболочке – эту тоскливую «икону» он поставил во главу угла и заставлял молиться на него свою жену – Кадрию.

Аскар юношей уехал из деревни в Казань еще до войны. Но ни после окончания войны, ни после своей женитьбы, ни после рождения ребенка, ни после защиты долгожданной диссертации – ни разу он не вернулся на свою родину, не навестил родных. Сначала умер его отец от полученных на войне ран. Потом и мать умерла в глубокой старости, так и не дождавшись приезда своего родного сына. Пожалуй, хитрость, приспособленчество, эгоизм, черствость души, отсутствие доброты только усугубляли его заурядное положение, мешали пониманию им теории и практики театра. Ведь театр несет зрителю свет. И ты, значит, если хочешь быть маститым ученым и педагогом в области театра, должен быть светлой личностью.

Аскар Моратов всегда жил в стороне: в мирное время – без связей с корнями малой родины, на войне – в глубоком тылу охранял лес от незаконной вырубки. Так и в театральную науку он пришел со стороны – после окончания филологического факультета пединститута и возвращения из армии он по знакомству устроился преподавателем в театральное училище. Для того, чтобы успешно развивать какую-то отрасль науки, надо

сначала стать высокопрофессиональным специалистом-практиком в этой области. Поэтому, великий штангист становится ученым в области тяжелой атлетики, а не гимнастики. Педагог-филолог Моратов приклеился, как ракушка к днищу морского судна, к большому, сияющему разноцветными огнями «кораблю» театра и принялся всех учить и критиковать. Но невпопад. Не было у него таланта, интуиции, да и опыта. По этой причине Аскар жил не в своей «тарелке» – истерично.

Только пройдя «тысячекилометровый путь» многострадальной жизни в 60 лет Аскар Моратов обрел душевный покой – его приголубила женщина из далекой деревни сибирских татар, которую он в студенческие годы, прожив с ней месяц, как муж и жена, обманул – уехал, сказав, что скоро вернется, но не вернулся…

Я всегда думал – что это за люди, которые годами, порой, десятилетиями не навещают своих родителей? Я не могу ответить категорически, что они непорядочные, хотя это и осуждается у нас, татар. Какие мотивы или черты характера способствуют этому? Обида на родителей? Или отсутствие доброты?

24 апреля 1987 г. Аяз Мирсаидович, отвечая на очередном заседании «Клуба семи муз» на многочисленные вопросы, поведал нам следующее:

Сидит ли во мне внутренний цензор? Да, я постоянно чего-то побаиваюсь. После смерти Сталина в печати появились стихи, утверждающие, что страхи умерли. К сожалению, нет. Это были преждевременные стихи. Мы не привыкли к откровению. За рубежом – раскованность. А вот Чингиз Айтматов не чувствует страха. Он смог заговорить о наркомании у нас. Другому давно бы заткнули рот. Конечно, ему в некоторой степени повезло… Из башкирских поэтов выделяю Ангама Атнабаева. У Мустая Карима средняя проза. Поэзия талантливая. Но очень высоко его подняли искусственно… Чингиза Айтматова я считаю великим писателем. Особенно силен роман «Буранный полустанок»… Все книги В. Астафьева я оцениваю высоко. «Печальный детектив» – его лучшая работа. Важная, человечная. Сегодняшняя правда. Грязь стала для нас обычной и привычной – вот что потрясает в книге… К Олжасу Сулейменову отношусь с уважением. «Аз и я» – очень сильное произведение…Что касается полемики на страницах «Социалистик Татарстан» вокруг постановки «Казанского полотенца» между Нуриханом Фаттахом и рядом авторов, с одной стороны, и главным режиссером Татарского академического театра М. Салимжановым – с другой, то я полностью согласен с авторами критических статей, считающих этот спектакль насмеханием над татарским народом. «Казанское полотенце» – не лучшая постановка театром пьесы Карима Тинчурина. Есть ложный смех, но нет передачи глубины

событий. Однако, в целом, в поисках нового, современного сценического решения постановки классических пьес, я поддерживаю Салимжанова. Например, «Голубую шаль» он ставит четвертый раз и повторяется. Он ищет современное прочтение. На это у режиссера есть право. Имеются претензии к костюмам актеров. Но ведь сцена всегда выше реальной жизни. По-моему, Татарский театр находится на высоте. Недавно прошла премьера моей пьесы «Три аршина земли», которую запрещали ставить в течение 15 лет. Салимжанов создал интересный спектакль.

*(Продолжение следует)*

*М.М.Гимадеев*

# ИСТОРИЯ СЕЛА СТАРОЕ ШАЙМУРЗИНО

*(Со времен приезда поселенцев во главе с Шаим-мурзой в Симбирский край)*

Старое Шаймурзино – крупное мишарское село на юго-западе Татарстана с богатой историей. Здесь родились и выросли многие знаменитые на весь Татарстан люди, такие как М.З.Азизов, долгие годы занимавший пост председателя СМ ТАССР, народный артист РТ, певец Г.Рахимкулов, Герой Социалистического Труда А.Ш.Абдреев и многие другие. В книге «Шайморза» [Бикчуров, Гимадеев: 2009. С.19] годом образования с.Старое Шаймурзино означен 1645г. За основание взят год выдачи переселенцам «владенной выписи» на землю.

По мнению известного археографа М.И.Ахметзянова, жители селений Малая Цильна, Большая Цильна, Старое Шаймурзино являются потомками выходцев-переселенцев из Темниковского уезда Тамбовской губернии. Все они были потомками мурз, живших в самом Темникове или в его окрестных деревнях [Ахметзянов, Шарифуллина: 2010. С.200]. В настоящее время выявлены новые, неизвестные доселе обстоятельства по дате основания с.Шаймурзино

В архиве Симбирского окружного суда сохранилось дело о спорной земле татар д.Чепкас с обывателями д.Тимбаево Буинского уезда [СГУАК: 1901. С.139–145]. Вопрос рассматривался Буинским уездным судом в 1810–1812гг. Стороны представили суду свои документы. Видимо, в выданных смежным деревням в разное время чиновниками документах на угодья произошло частичное наложение и из-за этого возник спор. Для истории Шаймурзино интерес представляет только «владенная выпись» чувашей из с.Тимбаево. На стр.143 вышеназванной книги по архивным материалам Буинского окружного суда следует запись: «... Били челом Цивильского уезда д.Тинбаевой черемиса (это – чуваши – М.Гимадеев) … в прошлом де в 102(1594) году… дано Тинбаю и Казынбаю Хнышеву с товарищи по речке Хирле по межам от речки Бурле в 2-х верстах до березы… на диком поле пашенной земли и сенных покосов… а от березы до столба дубового… на нем грань, а от столба по левую сторону – земля Шаймурзинская. А у того столба яма налево земля татарской деревни Тинчалей, к югу от куста по левую сторону служилых татар деревни Чепкас» [Документ основан на грамоте царя Федора Иоанновича и записан в дозорную книгу дьяком Томилой Перфильевым в 1615г.].

По заметным ориентирам местности (речкам, отдельно стоящим деревьям, столбам и ямам) тогда межевали границы земель населенных пунктов. Кадастрового межевания, естественно, не было.

Очень важным является упоминание в грамоте межевых границ д. Тинбаево. Географически и сейчас деревни Шаймурзино, Тинбаево, Ст. Тинчали соседствуют. Под д. Чепкас научные сотрудники Института Истории РТ Р.Р. Хайрутдинов и Р.Р. Салихов подразумевают д. Вольный Стан [Коллектив: 2000. С 46]. Земли Вольного Стана находятся и сейчас по соседству с Тинбаево. Ранее, названные населенные пункты относились к Буденновскому району ТАССР. При его ликвидации в 1959 г. эти деревни отнесли к Буинскому, а Ст. Шаймурзино – к Дрожжановскому районам. Река Хирла – чувашское название р. Карлы. Тинбаево и сейчас расположена вблизи р. Карлы. Карлы/Хирла слова с тюркского – «снежный». Река Бирля – нынешнее название р. Бурле (по-татарски *Бүреле*) тоже течет около д. Тинбаево. Это доказывает, что Тинбаево – деревня, располагавшаяся на землях, соседних с Шаймурзино.

Обращается внимание то, что в документе Перфилова записана не деревня, а «земля Шаймурзинская», что является исторической правдой. Поселенцы первоначально подселились в существовавшее еще тогда д. Уразбаево, а земля была отписана «Шаим-мурзе с товарищи». А деревня Шаймурзино была основана позднее, в 1645 г., на Казанском почтовом тракте, в 5 км западнее от Уразбаево. Здесь же и сейчас находится мост через р. Цильна. Поселенцы село назвали по имени своего предводителя.

Бывший Казанский почтовый тракт соединялся у с. Базарный Урень (ныне Карсунский район Ульяновской области) с Московским трактом. С этой развилки на юг начинался Пензенский этапно-почтовый тракт, соединявший центр России с Астраханью, позднее – с Крымом. Тогда не было нынешней прямой проезжей дороги между Казанью и Симбирском. А железную дорогу построили пленные немцы в последние годы Великой Отечественной войны.

Много неудобств принесла тогда дорога шаймурзинцам и жителям других придорожных сел. Беглецы и разный разбойный люд в XVII в. скопились в лесных массивах. Грабежи, убийства, насилие были нередким явлением на тракте. У шаймурзинцев до сих пор в памяти слово «беглай», т.е. «беглый», и этим прозвищем награждали плохих людей. В конце-концов помехи на тракте стали сказываться на государственных делах, и в Москве приняли специальный документ по охране дорог [Бикченин: 2001. С. 13]. Почтовый тракт разделили на участки, а за каждым участком назначили село, ответственное за охрану. За это казна выделяла дополнительно угодья (со слов старожилов, так как документы утеряны

за давностью лет). За шаймурзинскими служилыми татарами был закреплен участок тракта от чувашского села Старые Алгаши (ныне Цильнинский р-н Ульяновской обл.) до с. Старые Тинчали нынешнего Буинского р-на. От Ст. Тинчалей до г. Буинска за охрану отвечали Старостуденецкие татары (Буинский р-н). Аналогичное деление распространили на весь тракт. Порядок на дороге вскоре был восстановлен и поддерживался неукоснительно. Благодаря обязанностям по дороге шаймурзинские мурзы не подверглись конфискации поместий, избежали доли «лапотных мурз». Тогда действовал царский Указ, по которому все татарские мурзы были обязаны принять христианство, в противном случае у них отбирались поместья. В отношении выполнявших очень важные функции по охране дорог в Сибирь и Астрахань служилых татар этот Указ не применяли.

Таким образом, шаймурзинцы владели землей и осваивали Симбирский край еще в 1594 г., что на 51 год раньше принятой ныне даты образования села (1645).

## Литература


1. Ахметзянов М. И., Шарифуллина Ф. Л. Касимовские татары. Казань: Издательство «Магариф», 2010.
2. Биккенин И. Д. Татарская аристократия темниковского княжества и ее потомки. Аксеново, 2001.
3. Бикчуров С. З., Гимадеев М. М. Шәйморза (Иске Шәйморза авылы тарихи сәхифәләрдә). Казан: ОАО ПИК «Идел-Пресс», 2009.
4. Симбирская Губернская Ученая Архивная Комиссия (СГУАК). Архив Симбирского окружного суда. Выпуск первый. Гражданские дела Буинского уездного суда. Дело № 254. г. Симбирск. 1901.
5. Хайрутдинов Р., Салихов Р. Освоение Буинского края во второй половине XVI–XVII вв.. Казань: ТКИ, 2000.

***Илсөяр Закирова***
***Лилия Мөхәммәтҗанова***

## ХАЛЫК ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ САГЫНДА

*(Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге оешуга – 80 ел)*

*Милләтнең бер канаты туган тел булса, икенчесе – аның җыры, моңы, әкиятләре, ягъни хәзерге вакытта фольклор дип атала торган рухи байлыгы. Шушы ике канаты булган милләт кенә үсә, иҗат итә, матур планнар корып, киләчәген күзаллап яши ала. Халык иҗаты милли хис формалашуга этәргеч бирә, кешелекнең гасырлар дәвамында туплапган тәҗрибәсе, белеме, дөньяга карашы да фольклорда сакланып, киләчәк буынга тапшырыла. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 80 еллык юбилее уңаеннан Институтның халык иҗаты бүлеге турында аерым сүз әйтми калу дөрес булмас иде. Ни өчен дигәндә, бу бүлек Институт оешуның чишмә башыннан ук формалашкан, сигез дистә ел буена үз юлыннан тайпылмыйча, фидакарь эш башкарып килә.*

Г. Ибраһимов исемендәге ТӘСИнең халык иҗаты бүлегенең төп эшчәнлеге шушы бай мирасны туплау, фәнни яктан өйрәнү белән бәйле. Хәзерге вакытта татар фольклоры турында сүз барганда «Казан фольклор мәктәбе» дигән термин да кулланыла башлады. Бу – бүлек хезмәткәрләренең эшчәнлеген тану, татар фольклорчыларына Россия һәм башка ил галимнәре тарафыннан бирелгән зур бәя.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге (ул вакытта – фольклор секторы) рәсми рәвештә 1939-нчы елда гына барлыкка килсә дә, аның эшчәнлеге шактый алда, татар галимнәренең системалы рәвештә татар фольклорын җыя, фәнни нигездә өйрәнә башлаган вакыттан ук башланып китә. 1939-нчы елда Татар теле, әдәбияты һәм тарихы фәнни-тикшеренү институты ачылган вакытка татар фольклор фәне инде формалашып җиткән, үзенең эшчәнлеген киң колач белән башлап җибәрергә күптән әзер булган. Татар фольклористикасының барлыкка килүендә һәм үсешендә бөек әдипләр Габдулла Тукай (1886–1913), Галимҗан Ибраһимов (1887–1938), Фатих Әмирхан (1886–1926), шул чорларда ук киң танылган галимнәрдән әдәбиятчы һәм фольклорчы-теоретик Гали Рәхим (1892–1943), Хуҗа Бәдигый (1887–1940), Фазыл Туйкин (1887–1938) һәм соңыннан олы галим,

шагыйрь һәм драматург буларак танылган Нәкый Исәнбәт (1899–1992) зур роль уйныйлар.

1930-нчы еллар ахырына хәтле татар фольклор әсәрләрен халыктан җыю, аларны туплап бастырып чыгару, ягъни яңадан халыкка кайтару һәм фәнни нигездә өйрәнү, нигездә стихияле рәвештә барган. XX гасырның беренче яртысын татар фольклористикасы тарихының яңа сулыш алган икенче бер өлеше дип бәяләргә мөмкин. Бу 1939-нчы елда Татар теле, әдәбияты һәм тарихы фәнни-тикшеренү институты ачылу белән дә бәйле.

Институт ачылганга кадәр үк халык авыз иҗаты юнәлешендә эшчәнлек алып барган Габделхәмит Ярмөхәммәтов (Хәмит Ярми), үзен шунда эшкә билгеләүләрен үтенеп, ВКП(б) Обкомына мөрәҗәгать итә. Ул шул ук елның декабреннән ул институтта үзе ачкан фольклор секторының мөдире булып эшли башлый. Татар фольклор фәненең олпат галименең «Татар халкының поэтик иҗаты» дигән хезмәтендә бу вакыйга түбәндәгечә сурәтләнә: «1939 елда Казанда, Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты карамагында Татарстан тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты ачылды. Бу институт янында аерым фольклор секторының оештырылуы татар халык поэзиясен билгеле бер план нигезендә һәм системалы рәвештә өйрәнүне башлап җибәрергә мөмкинлек бирде. Институтның фольклор секторы халык авыз иҗаты өлкәсендә эшләүче кадрларны үз тирәсенә туплау эшенә кереште. Махсус экспедицияләр оештыру һәм урыннардагы культура көчләрен тарту юлы белән, институт янында махсус фольклор фондын булдыру сектор тарафыннан беренче чиратта эшләнергә тиешле бер эш итеп куелды». Хәмит Ярми, беренче эш итеп, секторның төп эш юнәлешләрен билгели: халык иҗаты әсәрләрен җыю өчен махсус экспедицияләр оештыру; аңа хәтле басылып чыккан җыентыкларда, китапханәләрдә, архивларда сакланган, бигрәк тә регуляр оештырылып килгән экспедицияләрдә җыелган фольклор текстларын басмага әзерләү һәм татар халык иҗаты белән бәйле проблемаларны фәнни өйрәнү.

Әнә шул юнәлешләрнең беренчесен тормышка ашыру максатыннан 1940-нчы елда ук сектор мөдире Х. Ярми җитәкчелегендә Себергә академик В. В. Радлов эзләреннән махсус экспедиция оештырыла. Себер экспедициясендә Вәли Хаҗиев, Мөхәммәт Садри һәм Сәит Әмиров катнаша. Экспедиция үз эшен Новосибирск якларында, Бараба далаларында башлап җибәрә. Соңыннан, Институт тарафыннан оештырылган беренче экспедиция, аның максаты турында Мөхәммәт Садри үзенең «Себер истәлекләре» дигән мәкаләсендә болай дип язган: «Экспедиция Себер татарларының җыр һәм көйләрен эзләп табу, аларны язып алу белән

генә чикләнмәде. Анда катнашкан Хәмит Ярми, С. Әмиров, В. Хаҗиев һәм мин һәркайсыбыз да үзебезнең бурычларыбызны яхшы белә идек. Х. Ярми белән Хаҗиев иптәшләр халыкның бигрәк тә әкиятләрен язып алу буенча, С. Әмиров Бараба, Тары, Усть-Ишим һәм гомумән Новосибирск, Омск өлкәсендәге татарларның тел үзенчәлекләрен өйрәнү буенча эшләделәр, ә мин халык көйләрен, җырларын өйрәндем. Шуның белән бергә без һәркайсыбыз үзебезгә йөкләтелгән эшкә генә ябышып ятмадык, җае чыкканда бер-беребезгә ярдәмләшә дә идек. Әйтик, Х. Ярми иптәш җырлар язып алса, мин үзем ишетергә туры килгән әкиятләрне яза бардым». Бу беренче экспедиция зур табышлар белән кайта. Мәсәлән мәшһүр «Идегәй» дастанының аерым вариантларын язып алуны экспедициянең иң җитди уңышы дип санарга мөмкин.

Бөек Ватан сугышы елларында тукталып торган фәнни экспедицияләр 1945-нче елның көзеннән яңадан оештырыла башлый. 1945–1955-нче елларда сектор хезмәткәрләре Татарстанның барлык районнарында фольклор экспедицияләрендә йөреп, искиткеч бай материал туплый. Шуннан соң инде экспедицияләр татарлар күпләп яши торган күрше Киров, Пенза, Рязань һ.б. өлкәләргә, Мари Эл, Чувашстан, Мордовия, Удмуртия республикаларына – җәмгысы 13 өлкәгә һәм 4 республикага оештырылып, тагын да байрак, үзенчәлеклерәк материаллар туплана. Татарстан һәм күрше өлкә-республикалардагы татар авылларын тулысынча йөреп чыкканнан соң, Хәмит Ярми сектор галимнәренең төп игътибарын Татарстаннан ераграк төбәкләрдә яшәүче татарлар иҗатын өйрәнүгә юнәлтә. Галимнең бу эше әйтеп бетергесез мөһим һәм перспективалы булып чыга. Чөнки татар халкының күпчелеге Татарстаннан читтә яши бит.

Академик В. В. Радловтан соң бер гасыр вакыт узгач, татар фольклорчылары алдында халык иҗаты әсәрләрен җыю өчен бөтенләй диярлек күтәрелмәгән һәм бик тә уңдырышлы «чирәм җирләр» ачыла: 1967-нче елдан башлап, Хәмит Ярми җитәкчелегендә киң Себер якларына фольклор экспедицияләре яңадан оештырылып, ифрат та бай материал, гаять үзенчәлекле әсәрләр язып алына.

Күпсанлы экспедицияләр нәтиҗәсендә татар фольклорчыларының татар халык иҗаты, аның байлыгы, жанр төрләре, яшәү шартлары турындагы карашлары принципиаль үзгәрешләр кичерә: татар халык эпосы (Себер татарлары), бәетләр, туй-йола җырлары (Себер татарлары, мишәрләр, керәшеннәр), тарихи җырлар (Себер татарлары һәм мишәрләр) кебек фольклорның фундаменталь жанрларына караган материал җыелып, аларны өйрәнүне яңа фәнни югарылыкка күтәрү мөмкинлеге туа. Тулаем алганда, Хәмит Ярми 1940–1972-нче еллар арасында, ягъни 32 ел дәвамында, татар халык иҗаты секторы оештырган күпсанлы

экспедицияләрнең җитәкчесе буларак, бик зур тәҗрибә туплый. Шул экспедицияләрдә катнашкан, шушы өлкәдәге хезмәтләре белән профессор дәрәҗәсен яулаган Ф.И.Урманчеев ул чорларны болай дип искә төшерә: «Хәмит Ярми оештырган экспедицияләргә әзерлек гадәттә 2–3 ай элек башланып, экспедиция үзе зур бер бәйрәм кебек оештырыла иде. Ел саен экспедицияләрдә 10–12 кеше катнашып, июнь-июль айларында, бер ай буена йөреп, халыкның көндәлек тормышын, гореф-гадәтләрен, йолаларын, бәйрәмнәрен, поэтик әсәрләрен җыеп, авыллар тормышында да актив катнашып, төрле лекция-докладлар, концертлар оештырып, авылларны шаулатып китә торган идек. Һәм әлеге экспедицияләрнең шулай матур һәм нәтиҗәле узуының төп сәбәпләреннән берсе – экспедиция җитәкчесенең әби-бабайлар, урта буын һәм яшьләр белән сөйләшә белүе һәм аларны сөйләтә алуы, һәрвакыт «кесәсендә тылсымлы тел ачкычы йөртүче», гомумән, кешелекле, мәрхәмәтле, җор һәм үткен телле Хәмит абый Ярми булуы иде».

Фольклор секторының икенче эш юнәлеше тупланган материаллардан киң катлам укучылар, мәктәпләр, студентлар өчен фольклор җыентыклары чыгару була. Мәсьәләнең тагын бер мөһим ягын истән чыгармаска кирәк: җитди фольклор җыентыгы чыгару өчен, барыннан да элек, конкрет материалны фәнни яктан тирәнтен өйрәнеп чыгу таләп ителә. Хәмит Ярми җитәкчелегендә эшләүче сектор галимнәре эшне бик тирәннән һәм зурдан башлый. Дөресен әйткәндә, академик В.В.Радлов, Габор Балинт, Хейкки Паасонен хезмәтләреннән соң, 1940-нчы елларга кадәр, татар фольклорына караган күләмле һәм чын мәгънәсендәге фәнни җыентыклар дөнья күрмәгән була әле.

1940-нчы елларда бүлек башкарган эшчәнлекнең күркәм нәтиҗәсе буларак, беренче җыентыклар чыгарыла башлый. 1940–1941-нче елларда, фольклор секторы хезмәткәрләре, Хәмит Ярми җитәкчелегендә, «Татар халык иҗаты» дип аталган 40 табак күләмендәге антология төзеп, аны нәшер итү өчен әзерли. 1940-нчы елда татар халкының мәшһүр галиме Нәкый Исәнбәт татар халык эпосының йөзек кашы булган «Идегәй» дастанының җыелма версиясен «Совет әдәбияты» журналында бастырып чыгара. Сектор галимнәре дә бу изге эштән читтә калмый: дастанны аерым китап итеп чыгару өчен Х.Ярми җитәкчелегендә махсус комиссия төзелә, аның составына Н.Исәнбәт һәм Ш.Маннур кертелә. Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле, басмага тулысынча әзерләнеп беткән әлеге китапларның берсе дә дөнья күрми кала.

1940-нчы еллар уртасында ук Х.Ярми белән Г.Бәширов ике томлык «Татар халык әкиятләре»нең беренче китабын басмага әзерләп бетерәләр. Бу китап та, сугыш беткәннән соң, 1946-нчы елда гына нәшер ителә.

1956-нчы елда шул ике томлыкның икенче китабы дөнья күрә. Әлеге басмалар татар фольклористикасында зур әһәмияткә ия, алар принципиаль яңа төр җыентыклар булып, үзләренең фәнни әһәмиятләрен әле бүген дә югалтканнары юк.

Бөек Ватан сугышыннан соң берничә ел узгач, Хәмит Ярми «Татар халык иҗаты» антологиясенә яңадан әйләнеп кайта. Бу хезмәт 1951-нче елда басылып чыга. Татар фольклоры антологиясенең дөнья күрүе татар фольклористикасы тарихында зур әһәмияткә ия вакыйга булды, әлеге антологинең әле безнең көннәрдә дә кыйммәтле. Китапта Хәмит Ярминең татар халык иҗатына багышланган зур күләмле монографик мәкаләсе урын алган. Аның беренче өлеше татар халык иҗатын өйрәнүгә – фольклористика тарихына багышлана. Аннан соң кереш мәкалә авторы татар фольклорының төп жанрларының һәркайсына: әкият, бәет, җыр, мәкаль-әйтемнәр, табышмакларга, Совет чоры фольклоры кебек катлаулы, тиешенчә өйрәнелмәгән проблемаларга туктала, тәфсилле фәнни анализ ясый. 1940-нчы елдан башлап, сектор галимнәре татар фольклорының төрле жанрларына багышланган күпсанлы җыентыкларны даими рәвештә бастыра башлыйлар, халык иҗаты әсәрләреннән торган махсус һәм саллы җыентыклар чыгару эше алга таба да эзлекле һәм нәтиҗәле дәвам итә.

Сектор эшчәнлегенең өченче юнәлеше җыелган материалларны фәнни яктан өйрәнү һәм анализлау була. Бүлек хезмәткәрләренең фәнни мәкаләләре 1939-нчы елдан вакытлы матбугат битләрендә күренә башлый. Бу мәкаләләр татар фольклорының төрле жанрларына багышланган. Мәсәлән, 1940-нчы елда гына «Идегәй» дастанына багышланган дүрт мәкалә дөнья күрә. Шул елгы Себер экспедициясе һәм нәтиҗәләре унлап фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләдә яктыртыла. 1941-нче елда фәнни кереш мәкаләләр белән бергә «Мәкальләр һәм әйтемнәр», «Табышмаклар», «Татар халкының балалар фольклоры» дигән җыентыклар да дөнья күрә, «Мең дә бер сәхәр» дигән әкиятләр җыентыгы басылып чыга. Вакытлы матбугатта халык иҗатын яктырткан мәкаләләр басыла. Бөек Ватан сугышыннан соң секторның эше тагын да җанланып китү күзәтелә, бу исә сугышка кадәрге чорда татар фольклорчы галимнәренең интенсив эшчәнлек алып барып, халыкныкын халыкка кире кайтару һәм татар фольклоры материалларын өйрәнү өлкәсендә ныклы нигез булдыра алулары белән бәйле.

1961-нче елда фольклор секторында Х.Х. Ярмөхәммәтов, И.Н. Надиров, Э.С. Касыймов, В.Ф. Павлова, Х.Х. Гатина, М.Л. Шәймөхәммәтов эшли. Музыкаль фольклорны М.Н. Нигъмәтҗанов өйрәнә. 1948–1970-нче елларда бүлектә Республикада яшәүче рус халкының фольклорын өйрәнү белән В.Ф. Павлова шөгыльләнә.

Үзенең күп гомерен татар халык иҗаты әсәрләрен даими җыю, бастыру һәм фәнни өйрәнүгә багышлаган Хәмит Ярминең фәнни яктан иң мөһим хезмәте – «Татар халкының поэтик иҗаты» дип аталган зур күләмле монографиясе – 1967-нче елда басылып чыга. Хәмит Ярми фәнни эшчәнлегенең тагын бер мөһим үзенчәлеге шунда – еллар үткән саен аның тикшеренүләренең эчтәлеге-мәгънәсе тирәнрәк ачыла бара.

1960–1970-нче елларда совет фольклор фәнендә ифрат җитди бер юнәлеш ачылып, төрле халыклар авыз иҗатының күптомлыкларын чыгару эше башлана. Казакъ, үзбәк, кыргыз, мордва һ.б. халыкларда шул юнәлештә беренче җитди адымнар ясала. Хәмит абый да әлеге идеяне күтәреп, күптомлыкның проспектын төзүне 1972-нче елдан халык иҗаты секторы мөдире итеп билгеләнгән фольклорчы-галим Илбарис Надировка тапшыра. Тиз арада татар фольклорының 12 томлык җыелмасының фәнни нигездә әзерләнгән проспекты әзерләнеп бетә һәм секторда эшләүче галимнәр күптомлыкны төзү эшенә керешәләр. Аның кыска җырларга багышланган беренче томы И. Надиров тарафыннан төзелеп, 1976-нчы елда басылып та чыга. Өч китаптан торган әкият томнарының икесен Х. Ярми һәм Х. Гатина төзиләр, өченчесе Л. Җамалетдинов тарафыннан әзерләп бастырыла.

Фольклор секторы 1990-нчы еллар башына тулысынча җитлеккән фәнни бүлек булып формалаша һәм Хәмит Ярми башлаган эшләрне уңышлы дәвам итә. Хәмит Ярминең җитәкче буларак бер күркәм сыйфатын әйтеп үтми мөмкин түгел: ул, халык иҗаты секторын җитәкли башлаган еллардан ук, фольклор фәненең киләчәге турында кайгыртучанлык күрсәтеп, секторга аспирантлар ала башлый. Галим алган аспирантларның барысы да тормышларын фән белән бәйли. Алар арасында 1972–1990-нчы елларда, ягъни 18 ел буена, сектор мөдире булган филология фәннәре кандидаты И. Надиров, танылган язучы һәм фольклорчы Э.Касыймов, фән докторлары, күренекле галимнәр Т. Галиуллин һәм Ф. Урманчеев бар.

Татар халкының танылган галиме, татар фольклористикасы тарихында беренче фән докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүлеге лауреаты, кеше буларак та киң күңелле, зыялы Хәмит Ярминең (1904–1981) фундаменталь фәнни тикшеренүләре, ул төзегән күпсанлы фольклор җыентыклары, аларда урын алган саллы-саллы фәнни мәкаләләре, комментарий-искәрмәләре бүген дә фән өчен кыйммәтләрен югалтмый. Бу хезмәтләр Хәмит Ярминең ни дәрәҗәдә киң колачлы галим булуын бик тә ачык күрсәтә.

Татар халык иҗаты бүлегенең тарихын күзәткәндә бик тә үзенчәлекле бер фактка тап буласың – 75 ел дәвамында бу бүлекне нибары алты галим

җитәкләгән: 1939–1972-нче елларда Хәмит Ярми, 1972–1990-нчы елларда Илбарис Надиров. Аннан соң бу вазыйфага Хуҗиәхмәт Мәхмүтов билгеләнә, әмма ул моңа вакытлыча эшләп тору шарты белән генә риза була. 1992–2009-нчы елларда Фатих Урманчеев. 2009–2010-нчы елларда бүлек мөдире вазыйфаларын вакытлыча К.М. Миңнуллин башкара. Һәм 2011-нче елдан бүлекне җитәкләргә яшь галим Илмир Ямалтдинов билгеләнә.

Илбарис Надиров бүлек җитәкчесе булган елларда барлык фәнни таләпләргә җавап биргән унике томлык академик басма – «Татар халык иҗаты» җыелмасы дөнья күрде. Бу – бүлек тарафыннан татар фольклористикасында беренче тапкыр башкарылган гаять җаваплы эш була. 1989-нчы елда бу фундаменталь басманы әзерләүдә турыдан-туры катнашкан бер төркем галим – Х. Ярми (үлгәннән соң), И. Надиров, Х. Мәхмүтов, Л. Жамалетдинов һәм Ф. Әхмәтова – Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. «Татар халык иҗаты» күптомлыгы бүгенге көндә дә татар милли-мәдәни мирасы өлкәсендә тиңе булмаган хәзинә, унике томлык (бераз соңрак Р.Ягъфәров тарафыннан төзелгән «Балалар фольклоры» дип исемләнгән томны да санап, унөч томлык) бүгенге көндә дә гаять әһәмиятле фәнни чыганак.

1992-нче елда бүлек җитәкчесе булып Хәмит Ярминең шәкерте, ул вакытка инде күренекле галим булып җитлеккән Фатих Урманчеев билгеләнә. Галим бүлекне җитәкләгән чор турында болай дип искә төшерә: «Мәсьәләнең иң җитдие – күп еллар буена төзелеп һәм ныгытылып килгән ышанычлы нигез булуда иде. Шул 1990-нчы еллар башында бүлек алдында торган иң мөһим проблемаларның берсе – фәнни кадрлар мәсьәләсе булып чыкты. Чөнки бүлек шактый «олыгайган». Анда нибары өч фән кандидаты эшли. Бер генә аспирант та, бер генә фән докторы да юк... Чын күңелдән эшкә керешкәч, мәсьәләнең бу ягы да шактый тиз хәл ителде: чөнки элек-электән бүлекнең фәнни потенциалы бик нык һәм зур иде».

Җитәкче буларак, Ф.И. Урманчеев бүлекнең төп фәнни юнәлешен билгели: «Татар халкының этник тарихы». Җитәкче үзенең эшчәнлеген фәнни кадрлар әзерләүдән башлап җибәрә. Бүлектә эшләүче галимнәр кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен тәмамлый. Берничә ел эчендә фольклористика белгечлеге буенча Хуҗиәхмәт Мәхмүтов – докторлык, Айсылу Садыйкова, Рәшит Ягъфәров, Ленар Җамалетдинов кандидатлык диссертацияләре яклыйлар. Бүлек фәнни яктан әзерлекле, тәҗрибәле галимнәрне туплый. Шушы ук елларда бүлеккә тагы аспирантлар кабул итү, яшь кадрлар әзерләү дә башланып китә. Халык иҗаты бүлегендә аспирантура узып, К.М. Миңнуллин 1996-нчы елны «Татар поэзиясендә җыр жанры», Л.Ә. Кариева «Татар мифологиясе: тарихи-ча-

гыштырма һәм типологик аспектта» (2000) дигән темаларга кандидатлык диссертацияләре яклыйлар. Башка регионнарда яшәгән галимнәр белән дә хезмәттәшлек башлана. Бүлектә Төмәннән килеп В.И. Хәйруллина аспирантура уза һәм 1999-нчы елда «Идегәй» эпосы һәм аның тарихи нигезләре» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. 1995-нче елдан бүлеккә аспирантлар кабул итү планлы рәвештә алып барыла, ел саен өметле яңа аспирантлар укырга килә, диссертациясен тәмамлаган яшь галимнәр яклауга чыга. Ф.И. Урманчеев бүлекне кадрлар белән тәэмин итү эшенә үтә җитди карап, бу эшне тиешле югарылыкта алып барды. 1998-нче елдан бүлектә ике яшь белгеч эшли башлый. 2000-нче елда И.Г. Закирова «Болгар чоры халык иҗаты», Л.Х. Ибраһимова (Мөхәммәтҗанова) «Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны» дигән темага Ф.И. Урманчеев җитәкчелегендә язылган кандидатлык диссертацияләрен уңышлы яклап, халык иҗаты бүлегендә яңа көч белән эшли башладылар. 2001-нче елда бүлекнең ике галиме татар фольклоры буенча докторлык диссертациясе яклый. К.М. Миңнуллин «Сүз сәнгате буларак җыр», А.Х. Садыйкова «Ислам идеологиясе һәм татар халык иҗаты» дигән темаларга язылган фәнни хезмәтләрен рәсми яклап, филология фәннәре докторы дигән фәнни дәрәҗәгә ия булалар.

Бүлектә әзерлекле докторлар саны арту Институтның Диссертация советына фольклористика белгечлегеннән кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклау мөмкинлеге булдыруга да юлны ача. Шушы чорда ел саен Фольклористика шифры (10.01.09) буенча күп санлы диссертацияләр яклана башлый.

Фатих Урманчеев үзе берничә фәнни юнәлештә эшли: татар дастаннары һәм төрки эпос, татар мифлары, әдәбият белән фольклор бәйләнешләре. Татар эпосын да беренчеләрдән булып өйрәнгән галимнең «Татар халкының героик эпосы» дигән зур хезмәте 1984-нче елда дөнья күрә. Шул көннән әлеге хезмәт татар фольклорчыларының гына түгел, азәрбәйҗан, кыргыз, казакъ, үзбәк, нугай һәм башка халык галимнәренең дә өстәл китабына әйләнә. Төрле өлкәләрдән Казанга килгән галимнәр беренче эш итеп шул китапны үзендә булдырырга омтыла. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, галимнең соңгырак чорда чыккан, татар эпосына багышланган «По следам белого волка» (1994), «Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә» (1997), «Народный эпос «Идегей» (1999) кебек монографияләре дә белгечләр тарафыннан көтеп алына торган китапларга әверелә. Галимнең «Ак Күбек», «Җир Төшлек», «Түләк», «Алпамыш», «Җик Мәргән», «Кузы Көрпәч һәм Баян-Сылу», «Алтаин Саин Сүмә» һәм башка дастаннарны тикшерүгә багышланган күп санлы фәнни мәкаләләре «Советская тюркология», «Советская этнография» журналларында басылып

чыга. Ф.И. Урманчеевның 2002-нче елда «Татар халык иҗаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек» китабы да вакытлы матбугат битләрендә югары бәя алды. Берничә елдан бу дәреслек белән эшләр өчен төзелгән хрестоматия да басылып чыга. Фатих Урманчеевның соңгы елларда дөнья күргән өч томлык «Татар мифлары» дигән энциклопедик характердагы хезмәте янәдән бер тапкыр аның татар фольклор фәнендә күренекле галим булуын исбатлый. Басмада татар эпосының аерым сюжетлары, мотивлар, эпик геройлар турында бай мәгълүмат бирелә.

Фатих Урманчеев җитәкче булып килү белән бүлек төп игътибарын татар халык иҗатын теоретик яктан өйрәнүгә юнәлтә. Бу елларда бүлек хезмәткәрләре зур һәм әлегә кадәр өйрәнелмәгән теоретик мәсьәләләрне тикшерүгә хезмәт куя. Хуҗиәхмәт Мәхмүтов татар халык паремияләрен тикшерә. Галимнең шушы өлкәгә багышланган «Борынгылар әйткән сүзләр (VIII–XVII йөз төрки-татар ядкярләрендә афоризмнар)» (2002), «Гыйбарәләр тарихыннан сәхифәләр» (2008), «Изге китаплар кайтавазы» (2012) һ.б. саллы монографияләре, күп санлы хезмәтләре дөнья күрә. Ким Миңнуллин татар халык җырларын халык авыз иҗатының әдәбият һәм тел белән бәйләнеше яссылыгында тикшерә. Аларда сүзнең сихри көче белән бәйле хасиятне ача. Галимнең халык җырларының жанр үзенчәлекләренә багышланган, аларның тылсымлы табигатен укучыга җиткерүгә корылган «Шигърият һәм җыр», «Агыйделкәй», «Җырларның шигъри табигате», «Басма сүз һәм татар җырлары», «Һәр чорның үз җыры» һәм башка монографияләрен һәм җыентыкларын галимнәр генә түгел, халык та яратып кабул итә.

Айсылу Садыйкова, әйтелгәнчә, бу чорда татар фольклор фәне өчен өр-яңа «Татар халык иҗаты һәм ислам» дигән тема өстендә эшли. Тикшеренү нәтиҗәләре буларак, аның берничә монографиясе, күп санлы фәнни мәкаләләре, фольклор җыентыклары дөнья күрә. Галимә 2001-нче елда «Татар халык иҗатында ислам идеологиясе» дигән темага докторлык диссертациясе яклый. Айсылу Садыйкованың «Ислам һәм татар халык иҗаты» (2005), «Исламская идеология и татарское народное творчество» (2000) дигән хезмәтләре дөнья күрә. 2014-нче елда галимәнең шушы теманы дәвам иткән «XII–XX гасыр татар әдәбиятында дини фольклор» дигән монографиясе дә басылды.

Бу чорда Ленар Җамалетдинов татар халык әкиятләрен, Рәшит Ягъфәров балалар фольклорын, Илбарис Надиров татар халык җырларын, Сәлим Гыйләҗетдинов риваять һәм легендаларны, Флора Әхмәтова дастаннарны тикшерү буенча зур эш башкаралар, аларның үзләре өйрәнгән жанрларны туплаган җыентыклары, фәнни монографияләре, күп санлы мәкаләләре басыла. Табигый ки, элегрәк дөнья күргән «Татар халык

иҗаты» күптомлыгының хәзер инде бер генә китабын да табып булмый. Татар халык иҗаты җыентыкларына көннән-көн арта барган ихтыяҗны истә тотып, халык иҗаты бүлеге хезмәткәрләре 2000–2005-нче елларда татар фольклорының аерым жанрларыннан торган җыентыкларын һәм «Энҗе чәчтем – энҗе җыям» дип аталган китаплар сериясен әзерләп бастыралар.

2011-нче елдан бүлек җитәкчесе вазыйфалары яшь галим Илмир Ямалтдиновка тапшырыла. Шушы бүлектә аспирантурада укыган, биредә фольклор мәктәбе узган И. Ямалтдинов та бүлекнең традицион эш юнәлешләрен белеп, татар фольклор фәненең киләчәген күреп эш итә. Бу табигый да, галимнең үзенең фәнни юнәлеше татар фольклористикасы тарихын, халык иҗаты бүлегенең эшчәнлеген өйрәнүгә багышланган.

Бүлекнең соңгы еллардагы эш юнәлешләре бүгенге фән таләпләрен истә тотып, Татарстанда һәм гомумән илебездә барган глобаль үзгәрешләр дулкынына ияреп, заман сулышын тоеп, халкыбыз, милләтебез мәнфәгатьләрен күздә тотып оештырыла. Бу – Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясенең төрле регионнарында яшәүче татар халкының халык иҗаты мирасын туплау, фәнни яктан тикшерү һәм анализлау, фольклорның этнолокаль үзенчәлекләрен, башка фәннәр белән бәйләнешләрен өйрәнү, халык иҗаты әсәрләрен бастырып чыгару, татар фольклорының милли үзенчәлекләрен, аның төрки халыклар фольклоры белән уртак якларын өйрәнү һ.б. Бүлек халык иҗатын саклап калу һәм торгызу буенча чаралар, фольклорның актуаль мәсьәләләренә багышланган фәнни конференцияләр, түгәрәк өстәлләр, семинарлар уздыра, бүлек хезмәткәрләре Россиянең төрле төбәкләренә барып һәм чит илләргә чыгып, фәни симпозиумнарда ныклы үз сүзләрен әйтәләр.

Институт җитәкчелеге тарафыннан фольклор өлкәсендә эшли торган кадрларны алга таба үстерүгә зур игътибар бирелә. 2011-нче елда И. Г. Закирова «Алтын Урда чоры халык иҗаты: мифологик һәм тарихи нигезләре», 2015-нче елда Л. Х. Мөхәммәтҗанова «Татар китаби дастаннары: жанр барлыкка килү тарихы һәм поэтикасы» дигән темага докторлык диссертацияләре яклап, бүлектә баш фәнни хезмәткәр вазыйфаларында фундаменталь тикшеренүләр алып баруларын дәвам итәләр, «фольклор» төшенчәсенә тагын да зуррак мәгънә өсти торган фәнни хезмәтләре белән таныла баралар.

2000-нче еллар азагыннан Институтта күтәрелгән фәнни дулкынга кушылып, бүлектә «Татар халык иҗаты»ның татар телендә өр-яңа академик күптомлыгы әзерләнә башлады. 25 томлык дип күзаллана торган әлеге фундаменталь җыентык татар халык иҗатының барлык жанрларын эченә алган бай чыганак булачак. Академик басма мифлар, әкиятләр,

дастаннар, китаби дастаннар, җырлар, бәетләр, мөнәҗәтләр, табышмаклар, мәкаль һәм әйтемнәр, балалар фольклоры, уен фольклоры, риваятьләр, легендалар һәм йола фольклоры томнарыннан торыр дип көтелә. Һәрбер том архив һәм соңгы елларда уздырылган экспедиция материалларыннан, әлегә кадәр киң катлау укучыга мәгълүм булмаган җыентыклардан тупланып, яңартылып төзелә. Бүлек хезмәткәрләре әлеге искиткеч зур хезмәт таләп иткән тупланмаларны киләчәккә йөз тотып, киләчәк буыннар өчен дип әзерли. Аларны бастырып чыгару халкыбыз рухи мирасына һәйкәл куюга тиң. Ата-бабаларыбыз сүзе, акылы, тәҗрибәсе булган халык иҗатының киләчәккә тапшырылуы гаять мөһим.

Татар халык иҗаты әсәрләренең русча күптомлыгын чыгару эше киң колач белән дәвам итә, 15 томлык итеп планлаштырылган әлеге күптомлыкның 8 томы инде дөнья күрде.

Халык иҗаты бүлеге хезмәткәрләренең татар фольклорының бүгенге актуаль мәсьәләләрен яктырткан фәнни хезмәтләре, вакытлы матбугат битләрендә фәнни-популяр мәкаләләре дөнья күрә тора. Хәзерге вакытта татар фольклорын дөньяга таныту юнәлешендә зур эш башкарыла. Галимнәрнең инглиз, төрек телләрендәге мәкаләләре чит илләрдә чыга торган җыентыкларда басыла, бүлек хезмәткәрләре Россия күләмендә фольклор белгечләре, башка төрки халыкларның фольклорчы галимнәре белән тыгыз элемтәдә торып, фәнни бәйләнешләрне ныгыту өстендә җитди эш алып баралар. Бүлек соңгы 10 ел эчендә халык иҗатына багышланган ике зур халыкара конференция оештырды. Бу конференцияләрдә чит илләрдән һәм Россиянең төрле өлкә һәм милли республикаларыннан килгән галимнәр чыгыш ясады. Бүлек галимнәре татар фольклорының актуаль мәсьәләләренә багышланган чыгышлары белән Төркия, Казакъстан, Кыргызстан, Азәрбәйҗан, Белоруссия һәм Россиядә узган Халыкара конгрессларда, симпозиумнарда актив катнашалар. Төрек, казакъ, алтай, якут, кыргыз, үзбәк, мордва, башкорт, чуваш, удмурт һәм башка халыкларның галимнәре белән фәнни элемтәләр булдырып, аралашып яшиләр.

Гамәли эшне фәнни-теоретик юнәлеш белән бәйләп алып баруның күркәм нәтиҗәсе булып соңгы ун ел эчендә бүлек хезмәткәрләренең дистәдән артык монографиясе басылып чыкты: И.Г. Закирова «Эпическое творчество перида Золотой Орды: мифологические и исторические основы» (2011), Л.Х. Мөхәммәтҗанова «Татарский эпос: книжные дастаны» (2014), А.Х. Садыйкова «XII–XX гасыр башы татар әдәбиятында дини фольклор (2014), Ф.И. Урманчеев «Тюркский героический эпос. Сравнительно-историческое исследование» (2015), Ф.С. Баязитова «Халык традицияләре лексикасы: соңгы туй (дини фольклор һәм җирле

сөйләш текстлары яссылыгында)» (2015), И.И. Ямалтдинов «Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX в. Собирание, публикация и научное изучение фольклора» (2016), Р.Ф. Хәкимов «Исторические песни в татарском фольклоре» (2017), И.Г. Закирова «Әүвәл башлап ни бетте» (2017), Ф.С. Баязитова «Халык традициясе һәм мифология. Им-томнар, ырымнар, тылсымлы сүзләр (җирле сөйләшләр һәм фольклор текстлары яссылыгында)» (2017), Л.Х. Мөхәммәтҗанова «Дөнья цивилизациясендә татар дастаннары» (2018), Ф.С. Баязитова «Халык традициясе лексикасы: Мифологик персонажлар, ышанулар (җирле сөйләшләр һәм фольклор текстлары яссылыгында)» (2018), М.Х. Бакиров «Пратотюрки: изначальная прародина, ранние племена и язык, история и этнокультура» (2018)).

Хәзерге вакытта бүлектә барлыгы җиде хезмәткәр (шуларның дүртесе – тулы ставкада) эшли. Аларның һәркайсының үз фәнни юнәлеше бар. Бүлек җитәкчесе ф.ф.к. И.И. Ямалтдинов татар фольклористикасы тарихын, ф.ф.д. А.Х. Садыйкова дини фольклорны, аның әдәбиятка йогынтысын, балалар фольклорын, ф.ф.д. И.Г. Закирова татар халык әкиятләренең һәм дастаннарының мифологик һәм тарихи нигезләрен, образлар системасын, ф.ф.д. Л.Х. Мөхәммәтҗанова төрки һәм татар эпосы формалашу, дастан жанры үзенчәлекләрен, эпик фольклорның мифопоэтик нигезләрен, татар халык җырларына хас нечкәлекләрне, татар әдәбияты тарихында халык иҗаты әсәрләренең борынгы тамырларын, ф.ф.к. Л.Х. Дәүләтшина татар мифологиясен, мифологик персонажлар һәм ышанулар системасын, фольклор һәм әдәбият бәйләнешләрен өйрәнәләр.

Институтның халык иҗаты бүлеген Россиянең төрле регионнарында яшәгән галимнәргә олы фән юлына чыгарга фатиха бирә торган бүлек буларак та таныйлар: аның Диссертация советына фольклористика белгечлеге буенча диссертация якларга килеп, биредә тикшерү узып, яклауга чыгучы галимнәр шактый. Биредә тикшерү узып, Новосибирскидан Н.Р. Ойноткинова, Уфадан Г.З. Имаева – докторлык, Ижевскидан Т.В. Окунева, Саранскидан С.В. Пивкина, Уфадан С.М. Кагарманова, Р.Р. Антынбаев, И.В. Имаева, Ф.Ф. Гайсина һәм башкалар үз чорында кандидатлык диссертацияләре якладылар.

Халык иҗаты бүлеге тикшереп өйрәнү өчен материалны үзе эзләп таба торган бүлек. Сүз экспедицияләр турында бара. Халык иҗаты әсәрләре бары экспедицияләр вакытында, халыктан гына язып алынырга мөмкин. Татар халкының бай рухи мирасын, шул исәптән халык иҗатын җыйнау эшендә яңа этап Институт директоры К.М. Миңнуллин инициативасы белән 2009 елдан башланды. Комплекслы итеп уздырыла торган бу экспедицияләрдә бүлек актив катнаша. Һәр экспедиция вакытында

тупланган материал аерым китап булып укучыга җиткерелә. Бу җыентыкларның һәрберсендә дә халык иҗаты бүлеге хезмәткәрләренең саллы фәнни мәкаләләре басыла. Экспедиция вакытында тупланган материал күптомлык фольклор җыентыкларын төзүдә дә файдаланыла.

Әйтеп үтелгәнчә, филология фәннәре докторы Хәмит Ярминең зур тырышлыгы, югары профессиональ әзерлеге, фидакяр фәнни эшчәнлеге нәтиҗәсендә оештырылган һәм ныклы, ышанычлы үсеш алган халык иҗаты бүлегенең фәнни хезмәткәрләре үзләренең остазларының бәрәкәтле традицияләрен бүген дә лаеклы дәвам итәләр. Быел бүлек, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты составында, үзенең 80 еллык юбилеен бәйрәм итә. Хәзерге вакытта халык иҗаты бүлеге зур булмаган, әмма тырыш, эшлекле һәм фәнни перспективалы, фәндә үзләренең ныклы сүзен әйтә торган иҗади төркем булып формалашты.

Әкиятле, дастанлы, җырлы, фәнгә хезмәт итә торган халык иҗаты бүлегенең киләчәге дәвамлы булыр дип ышанабыз.

## Мирасыбызның төбәк тарихына кагылышлысы

## Наше историко-краеведческое наследие

# ИДЕГӘ ДАСТАНЫ

*(Дәвамы. Башын карагыз: № 1, 2019).*

## IV

Сабрау килгәннән соң, йыелгалы булып таралган мәҗлес, ханның боерыгы ман тагы йыелды. Мәҗлес тайяр[1] булды. Мәҗлес тайяр булганнан соң, Сабрауны алып, Туктамыш хан да мәҗлескә керде. Бераз тамакланып алган соң, бал мәҗлесе башланды. Мәҗлес күгендә баллы йолдызлар бер туып, бер батарга, күрәгә тирәсендә әйләнергә, йемелдәшергә башлады. Кубызлар кубзарга, сорнайлар сарнарга, чалгылар[2] чалынырга башланды. Ханны күкләргә күтәреп йырлаулар китте. Мәҗлеснең күтәренкелеге халыкны канатландырып очар хәлгә йиткерде. Аяк очыннан гына басып ялгыз биюләр, күмәк биюләр китте. Биючеләрнең аяклары кубызларның кылы ман, сорнайларның теле мән тоташкандай баса башладылар. Мәҗлес гөж киләдер иде. Бу вакытларда Сабрауның кан тамырлары да яхшы гына тибәдер иде. Үзендә көч, дәрт сизенә башлаган иде.

Мәҗлесне күзәтеп барган Туктамыш аякка торды. Мәҗлес Туктамышның авызына карап тынлыкка калды. Шылт иткән тавыш та калмады. Туктамыш Сабрауга карады. Халыкның бөтен игътибарын Сабрауга юнәлдерде.

Супы[3] аяклы, супы бүрекле,
Супы арасында супы ерау,
Күпне күргән, күпне белгән
Ардаклыбыз[4] Сабрау үз янына
Өч батырны чакырды, ди.

Батырлардан өч кеше Сабрау янына киләде. Сабрау баллы сараякны кулына алып күтәрәде дә:

Кайсыгыз батыррак булса, бу балны шул алып эчсен! – ди.

Балны Кобогыл алып эчәде. Сабрау:

Афәрин, углым, батыр икәнсең! Син әгәр ханың өчен батырлык итә торган булсаң, ничек батырлык итәр идең? – диде.

Кобогыл әйтте:

Кала бозармын, казна китерермен, – диде.

Сабрау:

Әгәр ханга дошманлык итсәң, ничек батырлык итәр иденң? – диде.

Кобогыл әйтте:
Арсаеп[5] атка менәрмен,
Карчыга булып очармын,
Куып барып басармын –
Башын алып канҗагама[6] асармын.
Казнасын алып илгә,
Ханлыгын алып бигә бирермен.
Мин дигәнне кылармын,
Әгәр дигәнемне кылмасам,
Атамның хәрам углы булырмын, – диде.

Сабрау Кобогылдан бу сүзләрне ишеткәннән соң, мәҗлестәге халык алдында Туктамышка карап йырлайды:

Мин картыңмын, картыңмын,
Йөз туксанга тартыммын,
Йөз туксан яшь эчендә
Ни күрмәгән картыңмын.
Дөмбер, дөмбер, Дөмбер хан,
Аны күргән картыңмын,
Аблак хан, Азак хан,
Аны күргән картыңмын.
Колакчынлы Колга хан,
Аны күргән картыңмын.
Олы бабаң Тумбаул,
Аны да күргән картыңмын.
Унике тотам[7] ул тарткан,
Тартканда өзә аткан,
Тимер уктай Чыңгыз хан,
Аны да күргән картыңмын.
Өзәңгесе өзмә алтын,
Бер үрмәсе мең алтын
Үзбәк дигән хан үткән,
Аны күргән картыңмын.
Ябулары йәймә алтын,
Бар шайманы[8] чын алтын,
Манарасы кырык колач
Җанбәк дигән хан үткән,
..............................[9]
Аны күргән картыңмын.
Карт бабагыз Туктага,
Аның углы Туйхуҗа
..............................[10]
Аны күргән картыңмын.
Әҗәл туры килмәсә,
Азраил корок[11] салмаса,
Әле дә булса, Туктамыш
Синнән дә калыр картыңмын, –

дип, Сабрау халыкның бөтен дикъкатен үзенә тартты. Чыңгызның аталарыннан башлап, үзенең күргән ханнарын искәреп чыкты. Туктамышның озак яши алмаячагына да ишарә кылды. Сабрау боларны әйткәндә Кобогыл йыендагы халыкка күрәгә төбендә бал коеп утырадыр иде.

Сабрау сүзен Кобогылга борды:

Чыкмаган җан йөргәндә,
Йөз туксанга килгәндә,
Кобогылдай ирләрне

Һич күрмәгән картыңмын.
Артыннан килеп карасам,
Каһәрдән пәйда булгандай.
Яныннан килеп карасам,
Еланнан пәйда булгандай.
Алдыңнан килеп карасам,
Нурдан пәйда булгандай син!

– Әй, углым! Син кем угланы буларсың? Әйтсәңче карт бабаңа! – диде.

Кобогыл әйтте:

Әй, ата!
Үз атамны сорасаң,
Нәдеркая би иде,
Нәдеркая атасы
Кадиркая би иде,
Кадиркая атасы
Тирмәкая би иде,
Тирмәкая атасы
Газизкая би иде.
Газиз җәриә[12] күп газиз бар,
Барын сорап нитәсең?
Төп атамны сорасаң,
Баба Түкләс Чәчле
Газиздер иде, – диде.

Бу вакытларда Туктамыш ханга бал яхшы ук кына тәэсир иткән иде. Идегәгә булган яман караш эчтә генә сакларлыктан үтеп барадыр иде. Аның яман карашы йөзенә дә чыккан иде. Идегә һәм аның тугыз иптәше мәҗлестәге эшнең кая таба барганын күзәтеп торалар иде. Сабрауның сораулары ханның яшерен боерыгы ман барганы, Кобогылның Йантимер углы Кобогыл түгел, бәлки Котлыкая углы Идегә икәнен, атасының үчен (ачуын) алгалы тайярланганын ачуга таба барганын сизделәр. Качмаганда тиздән үлем булачагын анык белделәр. Ләкин ничек качарга, мәҗлестән ничек чыгып сызарга? Аның да хәйләсе уйлап өлгерелгән иде.

Күрәгә төбендә бал коеп утырган Кобогылга сараяклар (пыяла чынаяклар) бер-бер артлы әйләнеп килеп торалар иде, бал койдыргалы Кобогыл үзенең уң ягына карап, уңындагыларга бал коеп торганда, ханның вәзире Янбай ерау сараякны Кобогылның сул як колак төбендә генә тотып, аерым ашыгыч тавыш ман:

Кобогыл! Кой әле тиз генә! – дигәндә, Кобогыл кинәт борылып караган булып, Янбайның сараягына борынын бәреп канатып:

Һай, борыным канады, – дип, тас сорады борын канатырга. Янбай тиз генә алып килде дә борынын таска тоттырып, тас ман бергә тышка алып чыкты. Тиз качкалы көрәклегенә ишарә кылып, (Янбай):

Табаны ялпак[13] Тарлан бүз,
Төн катуга көн сиңа.
Өстендәге камка[14] тун –
Түрдә ултырган биләргә, – диде

дә, мәҗлескә кереп, Идегә урынына ултырып, бал коя башлады. Идегә һәрбер сулышын, вакыт үткәрмәстән, үзенә тайярланган Тарлан бүзгә таба атты. Бер аягы бусагага тигәндә, икенче аягы Тарлан бүзнең өзәңгесенә тиде. Артыннан чыккан буран ман күтәрелгән тузан бер сулыш эчендә кара төндә ак йеп булып сузылды. Идегәне юлда көткән иптәшләре дә кушылды. Халык әле Кобогыл койган балны эчә иде. Сабрау Кобогылның тайганын сизенгән хәлдә үзенең Кобогыл турысындагы сүзен дәвам иттерә иде:

Әй, ханым, иям, түрәм!
Әйтмәсәм мин, әйт дисең дә куймайсың,
Әйткәле авызым бармайды,
Бармаса да, әйтәем:
Кара лачын, бүз тойгын –
Икесе ике ояның кошы икән,
Аларны остауларына[15] оттырып,
Бер тур[16] агачка кундырдың.
Үзеңнең алдында ике егет бар:
Берсе аның олы угыл,
Берсе аның кече угыл.
Аргы угыл да бирге угыл,
Батыр икән олы угыл.
Куллары озын күренә,
Мәргән икән олы угыл.
Тарлан Бүзне иярләп,
Ботка тартып менәр ул,
Ике саклык турыны
Олауга йайдак[17] алыр ул.
Ач көзәндәй бөгелеп,
Ач бүредәй чыелдап,
Читәнеңдән кыйкулап[18],
Ачы сөрән салыр ул.
Ала-кола малыңа
Каулап[19] корок салыр ул,
Ансыз кузы, сансыз куй,
Күп гаскәре туйсын дип,
Суеп казан асар ул.
Алтыннан суккан урдаңны[20],
Көмештән суккан ишекне
Төсе суык чын булат
Очы ман тиз ачар ул.
Кисмә-кисмә сары алтын

Кисеп улҗа[21] итәр ул,
Кашыклап йыйган малыңны
Соскаклап чәчеп бетәр ул.
Кола чәчең агартып,
Ике күзең кызартып,
Картайганда илеңнән
Сөрән салып куар ул.
Кузыкайдай аруны,
Күзекәйдәй сылуны
Уң ягына ултыртып,
Үбә-коча сөяр ул.
Картмын, кеше таныман,
Әгәр кеше танысам,
Котлы-Кая би углы
Идегә ул – олы угыл, – диде.

Сабрау әйтеп биргән соң, моңача Кобоголның ата-бабасын яхшы белгәннәр дә белде. Кобогылның Йантимер углы Кобогыл булмаганын, бәлки Котлы-Кая углы Идегә икәнен аңлады.

Туктамыш хан сакчыларына Идегәне борын канатып торган йирдән тотып алып кергәле боерды. Халык:

Я Ходайа, ни булады инде? – дип, шул минутта зур бер вакыйга булуын көтеп, дәһшәт алдында калды.

Халыкның күзе Идегәне алып керәчәк ишеккә тегәлде. Сакчылардан берничә кеше йөгереп кереп, хан алдында тезләнеп:

Я, ханым! Бөтен йортны актардык, Идегәне тапмадык. Ни эшләгәле боерасыз? – диделәр. Туктамыш шашар хәлгә килеп:

Ни эшләргә! Ничек тә кулга төшерергә! – ди, аптырау алдында калды.

Сабрау:

Ялгыз ерак китмәстер,
Тугыз ирне йибәр дә,
Алдап-йолдап кашыңа[22] ал,
Кашыңа ал да, башын ал!
Исән-аман китсә ул,
Иделдән ары үтмәстер,
Иделдән ары үтсә ул.
Шаһтимергә китәчәк
Шаһтимерне алып килеп,
Сарайны харап итәчәк, – диде.

Туктамыш нишләгәле белмәстән:

– Кемне йибәргәле кәрәк? Кем алып кайта алыр? – диде.

Биләр:

Янбай, Янбай аның дусы! – диделәр.

Туктамыш:

Янбай, тиз булгын, син бар, син алып кайт! –диде һәм:

Әй, тугыз ир, тугыз ир,
Янбай ман тиз бара күр,
Алдап-йолдап Идегәне
Үз кашыңа ала күр.
Алдап-йолдап кашыңа ал,
Кашыңа ал да, башын ал! – диде.

Янбай бик ашыгып, тугыз ир мән Идегәне кугалы өйдән чыкса: иярләнеп саклыкта торган атларның барысының да өзәнгеләре киселгән, түшлекләре[23], аеллары[24], коешканлары[25] кыркылган табылды. Нишләптер, аерым торгангамы, Янбай атына гына тиелмәгән иде. Кугын тиз генә китә алмады. Ат иярләп тә вакыт үткәрелде.

Янбай үзенең тугыз куары белән иң яхшы аргымакларга менде дә ярым караңгы төндә бер генә күренеп калды. Атларның тезгеннәрен бушатып, бөтен чабышларына куйдылар, йиргә тимәгәндәй очтылар. Ләкин Идегәне Иделнең бу ягында күрә алмадылар. Идегәләр күптән инде, көн туган вакытларда ук Иделне чыгып, ярның башында тын алып, атларны утлатып яталар иде. Сарайдан тел алып[26] киткәле көтәләр иде.

Идегәләргә Иделнең артта калган ягыннан, ерактан төтендәй күтәрелгән тузан күренде. Тузанның Идегәләргә таба сузыла килгәне беленде. Ләкин Идегә дә, аның иптәшләре дә моннан курыкмады. Кугынның килеп йиткәнен көттеләр. Кәрәк була калса, качкалы, атышкалы да тайярланып куйдылар.

Кугын аһалга[27] төшеп, Идегәләр турысына килеп йитте, ләкин Идегәләр күптән инде Иделнең икенче ягында, аргы ягында иде. Кугынның саны да ун кеше, качкыннар саны да ун кеше, ләкин качкыннар көчлерәк булганлыктан, кугын Иделнең аръягына чыгуны уйлап та карамады. Кугын Идел аша аңлашкалы, Идел аша чакыргалы булды.

Янбай ерау Идегәне кайткалы чакырып ерлайды:

Идегә би, дусым ай,
Идегә би, дусым ай
Ханың-ияң чакырадыр,
Борылып Идел кичсәнә.
Кайтсана, Идегә, кайтсана,
Каерылып атың башын тартсана,
Иңсәсе биек Ак Урдага
Иңкәеп сәлам әйтсәнә.
Ирене юка сараяк ман
Ханияң бал бирәде,
Эчсәнә, Идегә, эчсәнә!
Колагын бездәй кадаган,
Кәгелен[28] кыздай тараган,
«Чү» дигәндә очкан кошны

Узып киткәле яраган,
Ияренең кашы алтын,
Йөгәненең башы алтын
Арабтан ат бирәде.
Менсәнә, Идегә, менсәнә!
Итәге алтын, йиңе алтын,
Бер күрүе мең алтын,
Кара кештән тун бирәде,
Кисәнә, Идегә, кисәнә!
Тотам бавы сум алтын,
Кыңгыраулы күк карчыга бирәде,
Күл кыдырып чөйсәнә!
Байталдан[29] байтал бүлеп бирәде,
Бәйләтеп кымыз эчсәнә!
Байтактан[30] байтак бүлеп бирәде,
Падишалык сөрсәнә!
Кузыкайдан артык ару бар,
Күзекәйдән артык сылу бар,
Аны да алып бирәде,
Уң тезеңә утыртып,
Битләреннән суыртып,
Аркасыннан кагып-кагып сөйсәнә!
Туктамыштай ханияң
Сиңа үпкә кылады,
Үпкә булган сүзеңне
Үз авызыңнан әйтсәнә!
Кил, Идегә, дусым-ай,
Безнең белән кайтсана! – диде.

Идегә Янбайның чакырып әйткәннәрен тыңлап торганнан соң, йаваб кылып ерлайды:

Кәмал углы Киң Янбай,
Киңәше өлкән эт Янбай!
Арырак торып сөйләче,
Бирерәк килеп тыңлачы,
Ачма күзең, тишәрмен,
Сөйләмә, телең кисәрмен.
Авыз ачма, тешеңне сындырып,
Башыңны чәйнәп изәрмен.
Атаң кара кеше иде,

Мал биргәннең колы иде,
Анаң кара кеше иде –
Аш биргәннең көңе[31] иде.
Син дә шундай кешесең:
Аш биргәннең колысың,
Мал биргәннең улысың.
Кайтман да, Янбай, кайтман да,
Каерылып атым башын тартман да,
Иңсәсе биек Ак Урдага[32]
Иңкәеп сәлам әйтмән дә.
Колагын бездәй кадаган,
Кәгелен кыздай тараган,
«Чү» дигәндә очкан кошны
Узып киткәле яраган,
Юртар атка юл бирсә,
Ходай Тәгалә уң бирсә,
Бу Идел дигән суыңны
Ияренең кашы алтын,
Йөгәненең башы алтын
Арабтан ат бирсә дә,
Менә алман, Янбай, менә алман,
Ауым[33] котсыз булганда,
Итәге алтын, йиңе алтын,
Бер күрүе мең алтын
Кара кештән тун бирсә дә,
Кия алмам, Янбай, кия алмам,
Йилкәмә мөез биткәндә[34].
Тотам бавы сум алтын
Кыңгыраулы күк карчыга бирсә дә,
Күл әйләнә чөя алмам,
Канҗагам кансыз булганда.
Байталдан байтал бүлеп бирсә дә,
Бәйләтеп кымыз эчәлмән,
Эчем котсыз булганда.
Байтактан байтак бүлеп бирсә дә,
Падишалык сөрәлмән,
Алла үземә бирмәсә.
Бу киткәннән китәрмен,
Шаһ Тимергә йитәрмен,
Шаһ Тимер миңа кул бирсә,

Кайругым[35] кылып кичәрмен,
Туктамыштай ханыңны аягыма
Бер мосахар[36] итәрмен, диде.

Янбайның чакырып әйткәннәренә җавап биреп бетергәннән соң Идегә үз сүзләрен әйткәле булды. Тиздән Ак Урданы алачагын, алган соңында ниләр эшләячәген, боларны эшләй алмаса, Идегә дигән аты корыячагын әйтеп, болай ерлады:

Бу киткәннән китмәсәм,
Киң чүлләрне үтмәсәм,
Ходай миңа юл биреп,
Шаһ Тимергә йитмәсәм,
Шаһ Тимер миңа кул биреп,
Теләгемне мул биреп,
Кырык убага[37] (түбәгә) кырык басып,
Яу булып килеп йитмәсәм;
Ач көзәндәй бөгелеп,
Ач бүредәй чыелдап,
Читәнендән кыйкулап,
Ачы сөрән салмасам,
Кирәгәсен[38] киртмәсәм,
Киртеп утын итмәсәм (кылмасам)
Алтынлап суккан Ак Урдасын,
Көмешләп суккан ак ишеген,
Төсе суык чын булат
Очы белән ачмасам,
Кузыкайдай аруын,
Күзекәйдәй сылуын
Үз түрендә шул вакыт
Түш астына салмасам,
Туксан башлы Ак Урдага
Бер генә ия булмасам,
Угланнарны сатуга
Бер чигара куймасам,
Кырык көнлек юлына,
Кырык көнлек чүленә
Кырык кое каздырып,
Кырык йорт – ям[39] салмасам,
Әйткәнемне кылмасам,
Мин үчемне алмасам,

Баба Түкләс бабам биргән
Идегә атым корысын!

Моның соңында Идегә үзенең юлдашлары ман аргымакларга атланып, бер катар булып тезелгәч, Янбайларга карап тагын да болай ерлады:

Мин миндермен, миндермен,
Юкны димәс ирдермен!
Дустым утын сүндермән,
Дошманым утын яндырман.
Үзем димәс намартка[40]
Аппак бүз ат мендермән,
Туксансыз йибә[41] салдырман,
Асылын сорамай аш бирмән,
Яралыштан асаумын[42],
Бугалак салса туктаман.
Карагайдан биекмен,
Давыл өрсә дә кайрылман,
Кайнашып беткән ботакмын
Тылтыңлаган[43] көрәнчә ат,
Кадырауны екканмын,
Ягасы алтын кирәүкә[44]
Ягалашып ерткәнмын!
Туксан баулы ак көбә[45]
Тунаган йирдә кигәнмен.
Ягалашып, уклашып,
Күпләр башын игәнмен.
Моннан ары мактанман,
Әгәр дә мин мактансам,
Унике тотам ук тарткан,
Тартканда өзә аткан,
Балталаса да аерылман,
Борындагы Чыңгызның
Үзе белән тиңдермен, дип,

аргымакларын Шаһ Тимергә таба борып, берәр тибенеп юнәлә бирделәр.

Юнәлде Идегә, юнәлде
Шаһ Тимергә баргалы,
Шаһ Тимергә барган соң,
Аннан гаскәр алгалы.
Чокыр-чакыр юлларны
Басып китеп барады,
Ашкар-ашкар тауларны
Ашып китеп барады.
Авызлыгын Тарлан бүз
Бирмәй китеп барады.
Барган саен шәбәеп,
Ярсып китеп барады.
«Чү!» дигәндә чабады,
Авызлык ман алышып,
Камчы тартмай барады,
Очкан кош ман ярышып.

Бара торгач, аннан-моннан йыелып, Идегәнең юлдашлары унжиде булды. Берничә көннәрдән соң Йаекка йиттеләр, аны да үтеп киттеләр. Йаектан алып, очы-кырые күренмәгән чүлгә (ком даласына) барып керделәр. Сусызлык, утсызлык (үләнсезлек), эсселек, юл ераклыгы атларын да, үзләрен дә каплап алды.

Идегәнең юлдашлары берничә көн барганнан соң сусызлыктан, эсселектән, ашау-эчү начарлыктан йөдәшә, күңелсезләнә башладылар. Шул чакта Идегә юлдашларына карата ерлай биреп, шуларны әйтте:

Ай, унйиде, унйиде,
Унйидебез бер кеше,
Мин кушылгач, унсигез,
Унсигезнең бер эше.
Сусадым дип карыкма,
Ачыктым дип камыкма,

Чаршадым[46] дип талыкма[47],
Юл озак дип балыкма!
Тамагың синең ачыкса,
Тамак табып бирәен,
Киемең синең ертылса,
Кием табып бирәен.
Атың үлсә, түләен.
Үзең үлсәң, нитәен?
Унйиде дуст, син үлсәң,
Җеназаңны чыгарып,
Баялычтан[48] ут ягып,
Таза-арулап күмәен.
Ирмен дигән ир егет,
Арысланга тиң егет
Утка салсаң, янмайды,
Суга салсаң, батмайды,
Барган йиренә йитмичә,
Юлда үлеп ятмайды.
Ярин әйтмә, борын әйт,
Мин исәндә үлмәссең,
Үлмәссең дә белмәссең,
Авырлыклар күрмәссең! – диде.

Идегә белән юлдашлары барысы да Шаһ Тимергә исән-сау барып йиттеләр. Бабайларның: «Ялгызга ясак, йәяүгә таяк, ачыкканга тамак булган Идегә» дигән сүзләре менә шул Идегә турысында әйтелгән.

*(Дәвамы бар)*

Алынды: Татар эпосы. Дастаннар. Казан: «Раннур», 2004 – 286–336 бб.

## Сүзлек – аңлатмалар

1. *Тайяр* – әзер.
2. *Чалгы* – музыка коралы.
3. *Супы* – «саф, олы, таза» магьнәләрендә, «собы» шәкелендә Себердә әле дә саклана. Төрки телләрдә м//б күчерешләрен искә алсак, «сум алтын», «сум көмеш», «сум агач», «сум ит» һ.б. да шушы суп. Супы белән бер тамырдан (кара: В.В. Радлов. Опыт словаря тюркских наречий. Т. IV, Ч. 1, СПб., 1911. – С. 562).
4. *Ардаклыбыз* – хөрмәтле, абруйлы.
5. *Арсаеп* – батырланып, ирәеп.
6. *Канжага* – ияргә әйбер асарга беркетелгән каеш һәм күн кап үзе.
7. *Тотам* – бер уч, яисә дүрт бармак киңлеге (7 см.) үлчәү.
8. *Шайман* – ат җигү кирәк-ярагы, дирбия.
9. Н.Х. кульязмаларында шулай күп ноктaлар куеп калдырылган.
10. Н.Х. кульязмаларында шулай күп нокталар куеп калдырылган.
11. *Корок* – элмәкле озын колга, укрук та диелә.
12. *Җәриэ* (гар.) – кыю, батыр, куркусыз.
13. *Йалпак* – йассы. Туры һәм күчерелмә мәгънәләрендә.
14. *Камка* – камчат (выдра). «Ефәк катнаш тукыма» мәгънәсе дә бар.
15. *Остау* – тотучы.
16. *Турагач* – кош кундыра торган агач.
17. *Йайдак* – җайдак, иярсез ат. «Йалаң йайтак» та диелә.

18. *Кайкулап* – һай-һулап.
19. *Каулап* – куалап.
20. *Урда* – хан торган урын, йорт, торак.
21. *Улҗа* – табыш, сугыш ганимәте, күбесенчә хатын-кыз.
22. *Кашыңа* –алдына, каршыңа.
23. *Түшлек* – атның корсак астыннан бәйләнә торган киң тасма, каеш.
24. *Аел* – ыңгырчак, иярне ат корсагы астыннан бәйли торган бау, каеш.
25. *Коешкан* – камыттан бил буйлап сузылган каешларны аркылы беркетүче тасма, шлея.
26. *Тел алу* – яшерен хәбәр алу (Н.Х.).
27. *Аһал* – биредә: эз. «Сөзәк җир» мәгънәсе дә бар.
28. *Кәгел* – маңгай чәче, ялы, хохол.
29. *Байтал* – колынламаган бия.
30. *Байтак* – гавам, масса (Н.Х.). Ил, дәүләт, ыру, мал-мөлкәткә дә туры килә.
31. *Көң* – хезмәтче, кол.
32. *Ак Урда* – Алтын Урданың бер өлеше. Бүз Урда дип тә әйтелә*.
33. *Ауым* – утыра торган җирем (Н.Х.).
34. *Биткәндә* – үскәндә.
35. *Кайругым* – кайрый торган ком (Н.Х.).
36. *Мосахар итү* – баш идерү (Н.Х.).
37. *Уба* – калку җир, таучык.
38. *Кирәгә* – тирмәне тотып тора торган колгалар.
39. *Ям* – почта тукталышы.
40. *Намарт* (фарс.) – кешелексез (Н.Х.).
41. *Йибә* – һибә, бүләк,
42. *Асау* – ярсу.
43. *Тылтыңлау* – уйнаклау.
44. *Кирәүкә* – яу киеме.
45. *Көбә* – металл божралардан ясалган кием.
46. *Чаршау* – ару.
47. *Талыгу* – хәлсезләнү.
48. *Баялыч* – төтене белән рух аруландыра торган чүл агачы.

---

* Соңгы фикер иске бер караш, хәзер ул башкача карала ала (релакция фикере).

## Исторические источники по краеведению

### ОТРЫВОК ИЗ КНИГИ П.С.ПАЛЛАСА. 5–14 ОКТЯБРЯ 1768 г.

*Как логическое продолжение рассказа о нефтяной деятельности Надыра Уразметова для нас наибольший интерес представляют результаты экспедиции под руководством 27-летнего Петра-Симона Палласа, немецкого ученого, приглашенного на работу в Россию. В 1768–1774 гг. он возглавлял академическую экспедицию, исследовавшую юго-восточную часть Российской империи. На территории Надыровской волости П.С.Паллас побывал в октябре 1768 г. Здесь он встречался с жителями края, которые, видимо, и рассказали путешественнику о старшине Надыре Уразметове, о нефтяном заводе, строившемся при р. Камышлы, нефтяных источниках при р. Сок.*

*Читатель может ознакомиться с впечатлениями П.С.Палласа во время посещения объектов нефтяного интереса Н. Уразметова в бассейне р. Сок 5–14 октября 1768 г. [П.С.Паллас. Путешествие по разным провинциям Российской империи. Ч. 1. – С.-Пб., 1773. – С. 152–156].*

*«**Усманова, 6 верст.*** Близ р. Сока при Татарской д. Усмановой переезжают чрезъ малую речку Кибит, или Акану, при которой показываются малые следы руд. Та же деревня называется еще Надырова, или Надыр-аул, по имени умершего за несколько лет старшины Надыра Урасметова, который по силе даннаго ему в 1756 г., от Оренбургской горной конторы в Уфе позволения, намерен был собирать находящейся в здешних местах асфальт, и делать из него нефть: и на такой конец начал было он действительно строить завод при вершине речки Камюшли; да и другой завод был бы построен при Сургуте: но сии разпоряжения приключившаяся оному Татарину смерть прервала и вовсе уничтожила.

***Верхняя Ермаковка, 2 версты.*** Ближайщая на моем пути Татарская деревня называется Ермак-Аул, которая так же по большой в Сок впадающей речке Байтуган именуется Байтуганова. До сего места по обеим сторонам Сока, вдоль текущих между горами речке, везде показываются следы руд, и далее оных не видно. Первый при р. Соке достойный примечания нефтяный ключ находится отсюда к северу в гористой стране, в которой речка Байтуган имеетъ свое начало. Чрез безпрерывные берез-

ником оброслые холмы дорога к оной речке была претрудная, и на силу в сумерках доехали мы до новопостроенной при одном источнике помянутой речки Чувашской деревни.




Карта Сокского бассейна составленная *П. С. Палласом.*

***Байтуганбашь, 14 верст.*** Нефтяной ключ находится оттуда версты за две при горе, которая в той стране выше всех, и лежит между источниками речки. Того же дня, переправясь чрез оную речку, продолжали мы путь свой к другой к западу стоящей Чувашской деревне, от которой идетъ к ключу хорошая дорога.

***Семеново, 4 версты.*** Уже на другой день можно мне было оной ключ осмотреть. Здесь почти кончились простирающияся вдоль р. Сока горы: ибо отсюда в северную сторону к р. Черемшану земля становится отчасу ровнее.

***Нефтяной ключ, 3 версты.*** Нефтяной ключ находится за несколько верст от Семенова в южновосточной стороне, при западном крутом скате вышепомянутой горы, на оброслом березником, и так как вся около лежащая страна, покрытом тучным черноземом месте, по которому течет западный главный источник речки Байтугана. Ключ несколько разпространили, и при горе выкопали небольшую на подобие котла яму шириною и глубиною до трех футов, в которую вода прибывает без приметного движения, и так же не приметно уходит в мимотекущую малую речку. И так хотя ключь не имеет быстрого течения, однако никогда не замерзает и в жестокие морозы; и есть ли занесет снегом, то возходящие изъ него смолистые пары, коих запах нарочито далеко чувствовать можно, очень скоро делают сквозь снег отверстие; не смотря на то, что вода не имеет теплоты до чрезвычайного градуса; ибо термометр сего утра в студеную

погоду на вольном воздухе показывал 160, а в воде только 138 градусов. В малой яме ключа покрывается поверхность воды черною весьма липкою нефтью, которая имеет цвет и существо густой смолы, и хотя часто оную счерпывают, однако она опять собирается в несколько дней. Около двух недель тому, как вычерпана была собравшаяся на поверхности воды нефть; но не смотря на студеную погоду опять собралось оной столько, что я смог снять до шести фунтов, не считая того, что сколько по липкости ея прильнуло к другим вещамъ. У самой горы вода была оною покрыта на большой палец толщиною, а в стоке сего ключа толщина ея становится отчасти тонще, по тому что вода безпрестанно уносит. Вся яма ключа покрыта нефтью, да и земляной слой, в котором она находится, и который чаятельно далеко простирается в гору, весь оною наполнен. По снятии нефти с воды виден еще чрезмерно тонкой проницательной лист крепкого горного масла поверх оныя, которое хотя в малом количестве, однако на почерпнутой воде легко загоралось. Опыты доказывали, что и сама вода набралась несколько горючих частиц, при разпущении делает синей камень красноватым, и имеет пресильный запах и вкус нефти. Около живущие Чувашане и Татара употребляют сию смолистую воду не токмо для полоскания и питья вовремя молощницы в роту и чирьевъ в горле, но и рачительно собирают самую нефть, и употребляют оную во многих случаях, как домашнее лекарство. Наипаче прикладывают оную к свежим ранам, которыя потомъ весьма скоро заживают. Еще делают из оной мазь с коровьим маслом, которая чрезвычайно целительна от всякихъ чирьевъ. Особливо примечания достойно внутреннее употребление, а именно: взяв полную ложку нефти, варят в молоке, в котором делается она густою сметаною. Сию пьют теплую во время колотья, или, когда болит живот, думая что-то приключилось от натуги и надсады, такожe и во время тайных болезней. Сказывают, что больной человекъ делается от того хмельнымъ, чувствует сильной жар, какъ то и думать можно, и сильно текущая моча имеет пронзительный нефтяной запахъ. Так же говорят, что некоторые мужики употребляют сию смолу вместо дегтю; может быть то и делают, когда имеют много оныя. Но сие редко случается, и все меня уверяли, что особливо оную берегут токмо на лекарство, и дают своим соседам. В около лежащих деревнях сам я видел, что Чувашане за неимением дегтю мазали колеса коровьим маслом, или свежим коровьим калом. В протчем здешняя нефть, не смотря на ея липкость, столь пронзительна, что у меня поставленная в холодном месте прошла сквозь толстую деревянную ступку, и чрез несколько недель напаяла толстыя в дюймъ доски. И так может она служить к полезному соблюдению дерева отъ согнития, и корабельных досок от вредных морских червей».

## 1756 ГОДА НОЯБРЯ 18. ДОНОШЕНИЕ ГЕОДЕЗИИ УЧЕНИКА ПАВЛА ЗУБРИНСКОГО В ОРЕНБУРГСКОЕ ГОРНОЕ НАЧАЛЬСТВО О НЕФТЯНЫХ МЕСТАХ В ДАЧАХ НАДЫРА УРАЗМЕТЕВА

В Оренбургское горное начальство геодезии от ученика Павла Зубринского доношение. 21-го числа августа сего года по данному из оного началства наказу велено мне ехать на обысканные Уфимской провинции Казанской дороги Надыровой волости деревни Надыровой старшиною Надыром Уразметевым и Юсупом Надыровым Осляхозямозяковыми нефтяные места, и где завод строить назначено. И по прибытии те места и где завод строить назначен осмотреть, описать и положить на чертеж в каких имянно местах во озерках ли или речках та нефть имеется и как ее доволно и анбар для варения нефти построен ли и в каком месте на их ли собственных землях или на чьих других. И по возврате то описание и чертеж подать в реченное начальство при доношении. А чтоб те нефтяные места мне показаны были о том де им, Надыру и Юсупу, ис того началства дан указ. И по силе оного наказа я тогда ж отсюда обще с помянутыми Надыром и Юсупом и отбыли. И из них Юсуп доехал толко Каршинской волости до деревни Шарыповой и из оной уехал в город Оренбург. И притом мне объявил, что он туда едет для исправления порученного ему по указам дела, а нефтяные-де места может показать отец ево помянутой Надыр. Чего ради ис той Шарыповой деревни с ним Надыром я и уехал. И приехали, во-первых, в ево деревню Надырову, где он, Надыр, стал быть одержим весьма болезнию. И за тою болезнию к показанию как нефтяных, так и того места, где завод будет строитца он, Надыр, ехать не мог. А знающих тех мест тогда в домех никого не случилось, о чем от 7-го числа сентября сего ж года и во оное нач430ство от меня репортовано с требованием на то повеления, точию указа не получил. Однако между тем по всевозможному моему принуждению он, Надыр, получил малое себе от болезни облехчение, то для показания нефтяных мест и ездил и те места мне показал. Почему мною свидетелствованы, описаны и на чертеж положены, по которому явилось. 1-е. В вершинах реки Соки в ключике значится нефти признак самое малое число. 2-е. Озерко состоящее подле реки Соки по течению оной по правую сторону и между речек Суршлы и Усаклы, токмо во оном нефти не имеется, а имеется подле оного в маленких выкопанных ямках, да и то самое ж малое число оказывается по поверхности воды. 3-е. Подле горы Сартеата имеется маленкое озерко ж называемое нефтяное, в коем никакого нефти признаку не

имеется. А 4-го нефтяного места в вершинах реки Сургута, а по-татарски Кукорты он, Надыр, мне не показал, затем, что он ево не знает, о чем он, Надыр, и в реченное горное начальство репортовал. Для варения нефти анбар строить начат подле речки Камышлы, как оной Надыр объявляет в их собственных дачах, которой построен толко до крышки, а другое строения притом никакого еще не имеется. А в каких подлинно уречищах те нефтяные места и анбар и в каком же расстоянии те нефтяные места от того анбара состоят о том значит во описании и чертеж же, которые объявляю при сем.

Ноября 18 дня 1756 года.

К сему доношению геодезии ученик Павел Зубринской руку приложил. [Источник: ГАСвО. Ф. 115. Оп. 1. Д. 6. Л. 34–35].

## Олуг татар иле

## Magna Tartaria

*Балгынай Норлан*

# ЧӘҮЧӘККӘ СӘЯХӘТ

Җәйнең матур бер көнендә мин Кытай иленең төньягында урнашкан Уйгыр автоном өлкәсендәге татарлар яши торган бик матур һәм чиста Чәүчәк шәһәрендә булдым. Бу шәһәрдә инде XIX-нчы гасырдан бирле гомер кичерүче татарлар белән очраштым. Анда әллә ни озак тормасам да, өлкәннәргә дә, балаларга да татар теле дәресләре бирдем, хәләл җефетем Базарбай Бикчәнтәев исә Казаннан өйрәнеп кайткан татар халык җырлары белән таныштырды. Очрашу моннан йөз ел элек Чанышевлар дигән татар гаиләсе төзегән ак йортта узды. Бу йорт әүвәл кызыл кирпечтән төзелеп, соңрак ак кирпеч белән тышланган. Шушы йорттан әллә ни ерак түгел кызыл кирпечтән салынган тагын бер йорт бар. Чанышевлар гаиләсенең бу йорты – ике катлы. Бүгенге көндә ул музей булып тора. Ә менә ак йортта татарлар төрле чаралар уздыра: бәйрәм көннәре, төрле бәйгеләр, һөнәри, хәтта татар ашлары пешерү, тегү-чигү эшләренә өйрәтү түгәрәкләре эшли, дини бәйрәмнәр үткәрелә. Кыскасы, бу йорт – милләттәшләребез җыелышып аралаша торган мәдәни үзәк.

Мин шушы ак йортта аның хуҗасы – Чанышевлар нәселенең турыдан-туры варисы, Рәфәт Кәримов белән очраштым һәм аның белән әңгәмә кордым.

Әссәләмәгәләйкүм, хөрмәтле карендәшләр! Сезнең белән танышуыма мин бик шатмын, – дип башлады сүзен Рәфәт ага. – Безнең гаиләбез яши торган әлеге ак йорт – 3300 квадрат метрлы. Без монда 1915-нче елда Казакъстанның Күктума дигән җиреннән күчеп килдек. Хәзер менә монда яшәвебезгә бер йөз ике ел булды. Безнең өй янындагы алма бакчасы Чәүчәк шәһәрендәге иң зур бакча. Бабаларыбыз утырткан бу алмагачлар 50–80-нче елларда картаеп китте. Өзлексез эштә булганга, аларны яңартып булмады, вакытыбыз җитешмәде. Бакчабызда хәзер каражимеш, өрек, балан, кура җиләге, җир җиләге һәм башка җиләк-җимешләр үсеп тора. Алар сакланды. Әле 100 яшәр имән агачыбыз да бар.

Чәүчәк татарларына килсәк, үзебезнең материалларда язылганча, милләттәшләребез 1851-нче елдан монда күченеп килә башлый. Беренчеләребез сәүдә белән шөгыльләнгән. Өстәвенә, дин дәресләре укыткан. Актив тормышта яшәгәннәр.

Менә сез күргән Чанышевларның шәһәр уртасындагы кызыл кирпеч йортын Рамазан Чанышев салдырган. Ә безнең бабабыз – Кәрим Чанышев. Ул, беренче булып килгән татарлар белән сәүдә эшендә катнашып, банклар ачып, мул тормышта яшәгән. Татарларның күбесе шушы шәһәрдә татар мәктәпләре ачып, шунда яшәүче бөтен милләт баласына яңача белем биргән. Казанда басылып чыккан китапларны алып кайтып, менә шушы шәһәрдә, Гөлҗада, Урумчи, көнчыгыштарак урнашкан Турфан, Кашгар дигән шәһәрләрдә дә татар мәктәпләре төзеп, шул китаплар буенча бөтен баланы белемле иткәннәр. Өлкәннәр дә укыган. Балаларга заманча тәрбия дә биргәннәр. Гөләндәм исемле абыстай, монда кызлар гимназиясе ачып, кызларыбызны милли рухта тәрбияләгән. Былтыр, бер унлап әби-бабайны җыеп, мондагы татарлар таихын яздык. Чәүчәк шәһәрендә татарлар үз акчасына 22 мәктәп төзеп, белем бирүне җайга салды, камилләштерде. Дөрес, хәзерге вакытта татарлар саны азайды: Чәүчәктә 150 гаилә яшәсә, Кытайда 3600 чамасы татар гомер кичерә. Милләтебез мөгаллимнәре казакъ, уйгур, дагурларга да төпле белем бирде. Бу хәлләр кытай тарихына да кереп калды. Татарларның белемле, тәрбияле, эшлекле булуы, башка милләт халкына да белем бирүләр шушы тарихи язмаларда да сакланды.

Безнең гаиләгә килгәндә, бабайның дүрт кызы, бер малае була. Хәзер бабайларыбыз бакыйлыкка күчеп беттеләр инде. Мин – бабайның олы кызының төпчек улы, әлеге 100 еллык тарихы булган кирпеч йортның хуҗасы. Зур өйнең 100 квадрат метрлы мәйданында гаилә музее ачтым. Анда хәтта ата –бабалардан калган тормыш кирәк-яраклары да саклана. Бу эштә хөкүмәтебез дә ярдәм итә: үз мәдәниятегезне, сәнгатегезне, җырларыгызны, телегезне онытмагыз, ди. Инде менә Сабан туен да үткәрә башладык. Соңгы вакытта – һәр елны. Бу милли бәйрәмебез дәүләт дәрәҗәсендә уздырыла торган бәйрәмнәрнең берсе булып калды. Аны уздыру өчен җирле хөкүмәттән дә, хәтта Пекиннан да махсус акча бүлеп бирелә. Шуның өчен без аңарга бик рәхмәтле.

Рәфәт аганың хатыны Чәүчәк татарлары оешмасы җитәкчесе Зәйтүнә ханым Кәримова да бу турыда үз фикерләрен әйтте:

Бу шәһәрдә Сабантуй 1988-нче елдан бирле уздырыла. Әсхәт исемле бабаебыз, 200дән артык кеше җыеп, елга буенда Сабан туен уздырды. Ул чакта әле без кечкенә идек: Сабан туеның ни икәнлеген дә белеп бетерми идек. Шушы Сабантуйдан соң мондагы бөтен татар үз мәдәния-

тен, сәнгатен белә башлады. Без инде, үсә төшкәч, аны саклау, татарлар яши торган урыннарга тарату эшләрен башлап җибәрдек. Тиз арада Татар мәдәнияте җәмгыяте оештырылды. Өлкән яшьтәге әби-апаларыбыз, яшьләрне җыеп, курслар ачып, мәдәниятебезгә, сәнгатебезгә кызыксыну уята башлады. Мин дә мөгаллимә булып киттем. 2007-нче елдан без Сабантуен яшьләр белән бергәләп уздырабыз. Шул ук елны Сабантуй бәйрәме, рәсмиләштерелеп, Кытай дәүләтендә хөкүмәт дәрәҗәсендәге бәйрәмгә әйләнде.



Рәфәт Кәримов

2009-нчы елда Татар җәмгыяте төзелде һәм мине аның җитәкчесе итеп билгеләделәр. Шул елдан башлап, Сабан туе ел саен уздырыла. Бик күп кунак килә: татарның бу күркәм бәйрәмен күрер өчен Австралия һәм башка илләрдән татар гына түгел, башка милләт вәкилләре дә җыела. Иң мөһиме: Татарстан Мәдәният министрлыгы юлламасы белән артистлар да килә башлады безнең Сабантуйга. Казан белән бәйләнешебез ныгыды. Әлеге 100 еллык йортыбыз хәзер Сабантуй йорты дип атала. Максатыбыз: яшь буынны милли рухта тәрбияләп, милли сәнгатебезгә алып кереп, татар мәдәнияте дәрәҗәсен бөтен Кытайга тарату.

## Ирек майданы: бәхәс клубы

## Площадь свободы: дискуссионный клуб

***Фанис Набиуллин***

# ТРАВМЫ НАРОДА

*(Продолжение. Начало № 2, 2019)*

Продолжая раскрывать довольно сложную, специфичную тему «Травмы народа», хочу прояснить свои побуждающие мотивы.

У каждого народа есть свои сыны, свои дети (*халыкның үз балалары*) – представители, которые имеют в различных областях определенные степени компетенции, инициированные в конкретную сферу на уровне опытного знания. Много лет изучая природу человека, среду его обитания, влияние ментальности народа на своего условного представителя, считаю себя обязанным приложить усилия для исследования всех аспектов, множества причин, повлекших состояние апатичности, растерянности у татар (читай, и у множества других, теряющих идентичность, народов), нередко и безразличия к судьбе своего народа.

Большая зависимость от обстоятельств (несомненно, это страх перед будущим, неизвестным «завтра», вечный сознательно-бессознательный поиск безопасности) может изменить, извратить сознание человека до неузнаваемости. Нарушенная иерархия ценностей, потеря истинного смысла жизни, неустойчивое мировоззрение бросает человека из крайности в крайность, лишает носителя данной ему Жизни состояния совершенного спокойствия и верного – устойчивого курса в сторону дальнейшего эволюционного развития. Метание от одной религии к другой, подверженность влиянию другой культуры, заимствование иного путём отказа от своего – это признаки потери истинного смысла, несогласия и непринятия тех условий, обстоятельств и среды, в которые нас поместила мудрая Природа по своему высокому замыслу и высокой, недоступной до сознания людей, целесообразности. Когда человек переходит во что-то другое через отказ от своего, он лишается последовательности. Потеря последовательности не позволяет ему проникать в последующие

смыслы. Сознание теряет глубину значений, человеческая жизнь начинает дрейфовать лишь по поверхности.

Конечно, обыватель, не особо стремящийся вникать в суть вещей, может сказать, что смысл жизни у всех разный: у кого-то цель завести семью, у другого – обогатиться, у третьего – выстроить карьеру, но, однако, цели, которых надо ещё достичь (некие желаемые результаты) и состояние наполненности или согласия с жизнью «здесь и теперь» – это совершенно разные состояния. Вероятно, надо в душе согласиться с тем, что этим обывателям тоже не миновать своих сетей, которые укажут им на поверхностность и внутреннюю связанность.

Если представить глобальный мир как мировую школу, где каждая отдельная жизнь или жизнь отдельной группы, будучи встроенной в общее и целое, проходит свои неизбежные уроки под влиянием сил эволюции, то напрашивается следующий шаг: необходимо разобрать, исследовать, осознать те уроки, которые стоят перед твоим народом. При этом важно отметить, что состояние жертвы, которое транслируют и проживают некоторые представители какой-либо большой или малой группы, не позволяет увидеть реальную точку отсчета, охватить и осознать территорию внешних и, прежде всего, внутренних ресурсов для дальнейшего роста. Постановка – «местом лучших и реальных изменений являюсь я сам» – во все времена и, особенно, у метафизиков, знатоков тонкого мира изменений, являлась и является самой верной. Обвинение любой другой стороны, несмотря на её возможную интервентность и невежественность, представление себя в роли жертвы, вводит обвиняющего в состояние внутреннего конфликта, что способствует истощению сил и нагнетению конфликта внешнего.

Прежде чем перейти к очень важной части этой публикации, поделюсь с читателем одним интересным феноменом (а подобных и других феноменов со мной происходило великое множество). Этой историей я не раз делился в малых кругах.

У каждого человека есть возможность вступать в личные отношения с Творцом, Создателем всех миров. Для этого не требуются посредники. В одном из своих обращений я попросил Аллаһа по Его воле сообщать мне важную информацию в 14.22, так как была у меня когда-то машина под номером 422. Спустя месяца 1,5 после обращения, один знакомый в знак благодарности решил нам показать три места в Казани, где он черпает силы. Первое место, куда он нас привёз, было местом захоронения огромного числа погибших при взятии Казани в 1552 г. татар возле Голубой мечети, в Старо-Татарской слободе. Там прочитали несколько сур из Корана и выразили своими словами наше уважение и признательность,

обозначили значимость тех порогов страдания, которые они испытали. Именно при проговаривании последних слов нас всех пронизала дрожь от головы до ног. Вторым местом посещения была сама мечеть (*Зәңгәр мәчет*). Третьим местом посещения было кладбище в Ново-Татарской слободе. Человек прекрасно знал историю всех захоронений: проводя нас по аллеям, он показывал нам места погребений многих известных татарских галимов, философов, мыслителей, богословов. Здесь и Г. Тукай, и Б. Урманче, Г. Насыйри, Максуди и многие другие. В завершение, когда мы стояли возле места захоронения Ш. Марджани, мне в 14.22 позвонил мой хороший знакомый (имя его я намеренно не обозначаю), который в определенной степени посвящён в мир тонкий, и не спрашивая ни о чём, выпалил следующее: «Меня всю ночь продержали среди мёртвых, их там очень много – тысячи. Я не знаю где ты сейчас и с кем ты, но вам от них всех зур салям!» Я сказал: «Мы в Казани на кладбище, в Ново-татарской слободе». «Вот-вот, от всех, к кому вы сегодня обращались, именно о них идёт речь. Их очень много. Я лишь выполняю их поручение».

Меня эта неожиданная информация просто ошеломила, и я поделился с ней со своими спутниками, они были поражены не меньше меня. Вот таким образом с нами на связь вышли через десятилетия и столетия те, с кем связаны боль, потери, травмы и сама жизнь татарского народа.

Это феноменальное событие натолкнуло меня на дальнейшие исследования, на малые и большие находки. Первым, напрашивался очевидный вывод: Связь с прошлым не теряется, жизнь не прерывается самим актом смерти. Но сам след травмированности может оставаться и, вне сомнений, остаётся в потомках. Конечно, далеко не в каждом представителе это проявлено. И здесь я хочу привести аналогию. Сами нервные волокна в наших телах нам служат для своевременного сообщения об опасности, об изменении условий окружающей среды в целях безопасности и, в целом, сохранения самой жизни (на организмичном уровне). Например, благодаря исправной работе функций нервных окончаний мы одергиваем руку от кипятка. Если реагирование заторможенное, то можно говорить о перегруженности функций, о травмированности и нарушении защитных механизмов. И в то же время, из-за того, что жизнь всего сущностного, множества разновеликих организмов заключает есть взаимосвязанная и взаимозависимая суть (Космос – это единый организм), нашими нервными волокнами в коммуникациях с внешним миром, является наша совесть. Если она развита лучшим образом, то мы проявляем чуткость и сострадание к другим частям «Большого организма». Если же совесть не развита, то она как бы представляет нечувствительную часть этого Большого Общего. Если наши пальцы были когда-то заморожены,

то в холодных экстремальных условиях они нас очень сильно подведут. Следуя принципу аналогий, переработанная, осмысленная и реабилитированная травма (неважно: народа или какого-либо человека) позволяет сохранить чувствительность к новому экстремуму и, в то же время, формирует новый уровень иммунитета – волю нового, ранее не достигнутого порядка. Состояние же жертвы – это знак закрытости от взаимодействия с последующими ступенями Жизни, некое капсулирование травмы. Напрашивается вывод: Необходима реабилитация травм татарского народа самими представителями народа. Бессмысленно ждать этой реабилитации от тех, кто этот народ не представляет.

Двигаясь последовательно в своих размышлениях, хочу акцентировать внимание читателя ещё на одном важном аспекте нашего бытия. Человек, являясь существом многомерным и многосложным, представляет очень совершенный живой аппарат или механизм – минимум планетарного уровня с различной степенью функциональной раскрытости. Неслучайно в древних учениях о человеке каждому энергетическому центру по позвоночному столбу (т.н. чакрам) пририсовывали разное количество лепестков-крыльев. Чем выше и совершеннее чакра, тем больше их число, указывая тем самым на большее количество взмахов-вибраций. Чем выше энергетический центр, тем выше и тоньше его частота, выше вибрации. Здесь необходимо отметить, что энергетическим центрам – чакрам человека, соответствуют определенные цвета и звуки. В индуистской философии и, прежде всего, в философии йоги, для гармонизации энергетических центров или их восстановления, издревле применялись и применяются по сей день различные соответствующие звуковые медитации-напевы. Например, такие известные, как Ра–Ма–Да–Са, Са–Та–На–Ма и многие другие. Разбирая звуковую комбинацию Са–Та–На–Ма, расшифруем значение звуков, которые раскроют нам ключ к последовательности Жизни и Смерти как в семьях, родах, так и в народах в целом. «Са» означает Бесконечное пространство, «Та» – означает Жизнь, которая вошла в это пространство, «На» – Смерть, которая венчает каждую Жизнь. Смерть многих пугает, она приносит много боли и страха. Она может блокировать тех, кто находится рядом. Поэтому сочетание Са–Та–На олицетворяет страх, падение, разрушение, дьявола. Однако «Ма» – означает Восстановление, Возрождение, поднятие Жизни на новый уровень из Смерти. Мудрые говорили: кто не боится Смерти, тот знает полноту и глубину Жизни. Травма – это последствия неготовности соприкасания, столкновения с внешней интервенцией, нередко последствие падения духа. Поднять полноценно дух во имя торжества жизни невозможно не приняв полноту, боль и тяжёлых вибраций смерти, не

осознав её значений. Надеюсь, несмотря ни на что и для моего народа наступит «Ма» – период Восстановления и Возрождения. Пусть это будет значительно меньшая по численности его часть, но она сохранится и разовьётся.

Тяжёлые периоды потерь бывали и бывают у разных народов. Одни, погружаясь, преодолевая период испытаний, проникают в глубокие смыслы преобразовательных эволюционных процессов, извлекают для себя истинные источники сил (таких – единицы), другие продолжают дрейфовать в сторону разложения, аморфной массой бессознательно вливаясь в проекты и стратегии других, потенциально более устойчивых групп, намеренно игнорирующих историю и культуру вливающихся, испытывающих удовлетворение от процессов массового поглощения.

Несомненно, нам полезен опыт первых. И я хочу обратить внимание представителей наших, теряющих идентичность народов, на опыт одного из наиболее закрытых народов – евреев. Первое, что важно отметить: таинство, как значимое и неизменное качество просто необходимо. «Таинство до сроков» важно при зачатии и вынашивании ребенка, в супружеских отношениях, при планировании дел (особенно важных), в неблагоприятных условиях, помня, что тонкое не может быть доверено более грубому.

Много лет работая с травмированными людьми, я на личном опыте, в личной практике понял, что травмы, которые они несут через всю жизнь, имеют часто очень глубокие корни. Депортации, раскулачивание, гонения по признакам религиозной и этнической принадлежности, различные формы геноцида – любое насилие – оставляют свой след в формируемом характере нынешних потомков. Как индивидуумы мы не просто члены семьи, мы также и члены огромных групп, коллективов, независимо от того, хотим мы к ним принадлежать или нет. Обращаясь к трудам Даан ван Кампенхаута о жертвах и преследователях на уровне коллективной души, мы найдём очень интересные, разносторонние и глубокие размышления этого автора о четырёх уровнях человеческой души. Каждый уровень достоин отдельного рассмотрения.

Что такое душа? Каждая культура, религия или духовная традиция используют разные определения. Люди по всему миру узнают в себе что-то такое, что они ощущают как отдельное или независимое от их физических тел, и они называют этот аспект своего существа душой. Большинство духовных традиций учат, что у каждого из нас есть своя личная душа, которая рассматривается как искра божественного света, у которой есть своё независимое сознание. Индивидуальная душа – это что-то личное, что-то связанное с нашей глубоко личной сущностью. Но личная душа

не является той единственной отдельной частью, которая могла бы быть независимой от всего сущего. Наша душа имеет связь с теми частями, к которым мы тоже принадлежим. Обозначить их можно как семейную или чуть больше – родовую. Это тоже часть нас, как и мы – часть этого большого. Однако, Кампенхаут привлекает наше внимание ещё к одному слою души. Где-то между семейно-родовой душой и Большой универсальной мы находим пласт, в котором индивидуум участвует в коллективных полях, и эти различные коллективы отделены друг от друга. Эти коллективные поля значительно объемнее и сильнее, чем семейное поле. Иногда специалисты-системники называют эти поля «коллективными душами». И это тоже часть нас. Есть одно различие: далеко не у всех эти части души развиты. Мы все без исключения находимся на разных уровнях развития, и это естественное эволюционное явление.

Так вот, любой коллектив, который определяет себя как отличный от других, имеет коллективную душу. И поскольку существует много различных видов таких коллективных полей, то каждый отдельный человек является частью нескольких коллективных душ одновременно. На уровне коллективной души мы отпускаем некоторые аспекты нашей индивидуальности. Здесь наша идентичность базируется на общности. «Я» освобождает место для чувства «мы». Коллективная душа создается, когда группа людей объединена сильными связями. Чем сильнее связи, тем дольше существуют коллективные поля (поля влияния). Коллективные души, объединенные или основанные на религиозной или этнической платформе, могут существовать тысячелетия. Мы, человеческие существа – существа социальные, коллективные. Нам важно принадлежать, идентифицироваться с чем-то большим, значимым. Родовые или этнические принадлежности являются теми коллективными группами, которые не выбирают. У нас есть право принадлежности к ним. И эта принадлежность по определению сопровождается непринадлежностью: когда мы принадлежим к какой-то определенной группе, для нас автоматически исключается возможность принадлежать к некоторым другим группам. Неизбежно создаются поля «мы» и «они».

Коллективные души тоже не статичны, они также имеют свойство развиваться. Если на ранних уровнях развития представитель коллективной души, например, определённого этноса, народа или определённой религии, из позиций безопасности рассматривает, сосредотачивается на различиях между системами, то на более поздних, более зрелых уровнях начинает видеть и ценить их сходства. Так человечество в своей эволюции движется к своей четвертой, высшей и важной части души – Универ-

сальной. Здесь венчается планетарная практика человечества. Здесь мы соединяемся с Творцом, с высшей Природой.

Коллективная душа, например, душа народа, может нам дать очень многое, обогатить нас. Иногда мы можем пережить чувство единства с коллективом, выходящем за пределы обычного переживания времени и пространства. Тогда мы, как отдельные личности, сливаемся с чем-то большим, мы участвуем в коллективном поле на уровне души. В такие моменты у нас есть прямой доступ к опыту и знаниям коллективной души. И в такие моменты коллективная сила поддерживает нас. Но, к сожалению, иногда нас ослепляют коллективные слабости и предрассудки. Это относится к каждому.

В логической цепи своего изложения я хочу привести еврейскую практику ежегодного посещения мест скорби и, в то же время, мест единения с коллективной душой. Даан ван Кампенхаут раскрывает нам свои особенности и выводы ежегодного посещения концентрационных лагерей евреями и, в частности, Освенцима – Аушвиц-Биркенау. По разным оценкам, в Освенциме было жестоко убито более миллиона евреев. Один из инициаторов ретритов в Аушвиц-Биркенау раскрывает некоторые особенности посещения подобных мест: «Большинство людей приходит сюда всего на несколько часов. Но мы остаемся. Мы приходим на следующий день, а потом на следующий и ещё на следующий. Каждое утро мы отправляемся в Биркенау и остаемся до наступления вечера. День за днем, день за днем. Мы строим отношения с этим местом и его историей. Мы не можем предсказать, что будет в этом обмене, мы просто отдаёмся этому потоку. Мы говорим: просто будьте здесь, позвольте этому месту говорить с вами. Просто будьте открыты, будьте свидетелем всему, что захочет быть познанным вами. Длинные ряды деревянных бараков, руины газовых камер и крематория. Безмолвные колодцы хранят пепел убитых людей. Я могу понять концепцию могилы одного человека. Как понять могилу как минимум полутора миллионов людей? Здесь наступил конец целому миру… Всего через несколько часов, проведенных здесь, ум начинает расшатываться. Может быть, именно поэтому большинство групп посетителей, которые заходят на территорию лагеря, пробегают по нему всего за два часа. Им надо уйти до того, как это место захватит их и прорвётся через их защиты…».

Далее: «…Здесь рушатся все ментальные конструкции. Каждая попытка охватить своим пониманием это место проваливается уже хотя бы из-за его размеров…».

Наконец: «…В психотерапевтическом формате живых просят отделиться от мертвых, но я принадлежу к ним. Когда я прекращаю интерпре-

тировать свои переживания с терапевтической позиции, сопротивление и суждение уходят. И тогда я более тонко чувствую, что происходит внутри. Это не то чтобы потерянная часть моей души нашла свой путь вернуться ко мне, но скорее я нашёл путь возвращения к той части моей души, которая ждала меня здесь… Это моё прибытие, моё соединение. Эта сила, которую оно даёт, – откуда она берётся? Я никогда не чувствовал себя более заземлённым, более присутствующим, более полным. Я не осмеливаюсь поделиться этими состояниями с не-евреями. То же испытывают мои соплеменники…». Прислушаемся: «…Мой опыт таков, что ты никогда не возвращаешься полностью после того, как побываешь там. Часть тебя остаётся в Аушвице, и эта часть становится источником исцеления, силы и покоя. Я прихожу к выводу, что, то, что я переживаю, это часть моего существа, которая находится вне пределов моей личной души или привычных областей моей личности. Я прикоснулся к пространству, где разум и логика – не главное, а реальность души шире и пространнее, чем я когда-либо испытывал ранее. Я переживаю опыт коллективной души».

От себя добавлю о тех, которые пробегают лагерь за два часа. Они боятся пропитаться запахом и вибрациями смерти, они избегают этого погружения. Несомненно, каждый имеет свой потенциал и определенную степень готовности к подобному движению вглубь себя. Однако несогласие с какими-то непростыми, сложными и даже трагичными частями своей жизни, жизни своего народа, своих близких, страх, нежелание смотреть в эту сторону, не позволяет входить в резонанс с той страницей жизни, в которой оказались твои близкие, прародители, значительная часть своего народа. Это не позволяет полноценно и достойно нести имя своего народа, право на жизнь которому предоставил Творец, Высшая Природа.

В завершение статьи, заканчивая логическую цепь размышлений о судьбе народа, выражаю твёрдое мнение, что представители каждого народа имеют право, обязаны, должны посещать, почитать места скорби, боли, территории страдания своего народа, соприкасаться со своей коллективной душой. У многих народов есть такие места. Ни одно из них не должно быть предана забвению. Это важно для каждого из всех народов нашего Мира. Такое право есть и у татар. Это не только их право, но и возможность для них обрести места их силы.

**Шәхесләребез**

**Известные личности**

***Р.Р. Минһаҗ***

## ЯЛАНТАУГА АЙ КУНГАН

*Казан урамнарында кая карама үзбәк, таҗик кафе-рестораннары. Юк, күпсенүебез түгел. Ачсыннар, эшләсеннәр. Әмма кайда соң үз милләттәшләребез ачканнары?! Ярты Казан кешесе татар була торып, пешерү-төшерү, сый-хөрмәт итү нечкәлекләрен белгән, үз эшен ачарга курыкмаган аш-су осталары арабызда калмаганмыни?!*

*Күп булмаса да бар алар, бар башкалабызда. Таш калабызда дистәләп җәмәгать туклануы ширкәтләре – кафе-рестораннар, гаилә ашханәләре тотучы Равилә Шәйдуллина – шундый уңган ханымнарыбызның берсе. Ханымнарыбызның берсе дип әйтү генә дөрес булмас. Аның шан-шәрәфле исемнәре арасында «Россиянең иң шәп аш-су остасы», «Иң шәп гаилә бизнесын оештыручы», «Татарстанның иң уңышлы эшмәкәре», 2015 елның «Ел хатын-кызы», Татарстанның атказанган сәүдә хезмәткәре дигән казанышлары бар. Эшкуар белән очрашып, үз бизнесыңны булдыру серләре турында сөйләштек. Дөрес, өстәлдә әңгәмәдәшемнең «Ялантауга ай кунган» китабы яткангамы, сүзебез үзеннән-үзе әдәби иҗатның хикмәтләрен шәрехләүдән башланды.*

– Бу китабымны өч мең данә чыгарган идем. Чыгуга аны Америкада яшәүче таныш тәрҗемәче ханым – Сурайя Гайнуллина урыс теленә тәрҗемә итте. Урысча да өч мең данә нәшер ителде инде ул. Таралып бетте диярлек. Хәзер тагын өч мең данә чыгарырмын дип торам. Халык шуны егылып укый. Ник укыйлар – белмим! Бу минем тугызынчы китабым. Хәзер менә «Карт шомырт монологы» дигән, ике кисәктән торган роман тәмамладым. Бастырырга дип Дамир Шакировка биргән идем. Тик менә кире алып кайтып «үтүклим» дә «үтүклим». Камиллекнең чиге юк. Әле менә исеме ошап бетмәде дә, җыр сүзләрен алып, «Шомырт чәчәкләре ак кына» дип үзгәрттем. Исем укучыны алып кереп китәргә тиеш дип, шомырт сүзеннән баш тартмадым. Авылдагы, бабамнарның төп йортындагы бакчада үскән карт шомырт агачын, инде үлде, бетте, дип йөри идем. Тамырлары корымаганга, үсентесе кабат килеп чыкты.

Аны бит бабамның әтисе Котдус 1901-нче елда утырткан булган. Ул үзе 1974-нче елда ахирәткә күчте. Нәселебезнең тамырлары тагын да тирәндәрәк икән. Эш яратуым, җаваплылык, үҗәтлек, тәвәккәллек, булсынга дип эшләвем, сәүдәгә хирыслык ерак бабаларымнан килә. Боларны нәселебезнең төп сыйфатлары дисәм, әлләни арттыру булмастыр.



***Тәвәккәл таш яра***

Җәмәгать туклануы тармагында илле биш ел эшлим инде. Кайбер адәм баласы моның хәтле яшәми дә. 15 яшемнән бу эштә мин. Иң беренче хыялым журналист булу иде. Беренче сыйныфта укыганда ук мәкаләләр яза башладым. Нинди татар гәҗите бар, бөтенесенә җибәрдем. Әле менә сандык төбеннән, актив язып торганым өчен, «Яшь ленинчы» газетасының кырык еллыгы уңаеннан, комсомолның өлкә комитеты җибәргән Мактау кәгазе килеп чыкты.

Казанга иртә килеп урнашуымның сәбәбе гади: туган җиремдә – Теләче районының Алан авылындагы мәктәп сигезьеллык кына иде. Укуны дәвам итү өчен күршедәге, бездән җиде чакырымдагы Янсуар авылына йөреп укыйсым килмәде. Икенче сәбәбе дә бар: әтиебез авырып пенсиягә чыкты. Әнием алган бер хезмәт хакына тору кыен булыр, гаиләгә булышыйм дидем. Әнием дә, әтием дә укытучы иде. Шунысы кызык: әтием дә, ирем дә Шамил исемле. Әнкәй – Нурания. Без биш бала үстек. Олы абыем Дамир Муратов шактый еллар «Тасма» берләшмәсендә партком секретаре, генераль директор булып эшләде. Менә шул абыем белән

1964-нче елны без икәү өйдән чыгып киттек (ул унны бетергән иде). Әниемнең җибәрәсе килмәде (кечкенә чагымда әти-әнием кебек укытучы булырга хыялланган идем; университет белемле татар теле белгече дә мин, әмма аш-су әзерләү тармагыннан аерыла алмадым, күрәсең, язмышыма шулай язылган). Акча җыя торган балчык мәчем бар иде. Шуны ваттым. Аннан биш сум да ун тиен акча чыкты.

Авылдан килдек. Торырга урын юк. Ашау ягы такы-токы. Кием дә шул чама. Бабайның энесе автовокзал янында яшәгәнен беләм, тик ничек урысча сорарга? Абый, имтихан бирергә соңга калам дип, мине озатып тормады. Көчкә-көчкә эзләп таптым. Анда минем килүемә берәү дә сөенмәгәндер дип уйлыйм. Чөнки ул вакытта Казанга килгән бөтен кеше шуларның ишеген шакый иде. Укырга керү, эшкә урнашу өчен прописка кирәк. Нишләргә? Берзаман күзем кулинария училищесына укырга керергә чакырып торган игъланга төште. Ул вакытта Хазановның, кулинар училище маҗаралары, дип сөйләп йөргән чаклары. Билгеләрем яхшы. Әмма, урыс телен белмәгәч, укуы башта бик кыен булды. Минем белән берүк вакытта документларын тапшырган кыз укый алмыйча кайтып китте. Ул чакта мин – бер тере урысны күрмәгән кеше. Бездә өч урыс – мал табибы Николай абый белән тегермәнче Михаил абый, фельдшер Нюра апа бар иде. Алары да татарча сөйләшә. Телевидение, интернет юк заман – 1960-нчы елларның башы. Казан урамнарында татарча сөйләшсәң, «Чаплашка!» дип кычкыра торган заман иде. Бу чорда училищеда урта белем бирмиләр иде. Сыйныфташларымнан калышырга ярамый дип, Восстание урамындагы Галимҗан Ибраһимов исемендәге татар мәктәбендә (хәзер татар гимназиясе) укуымны дәвам итәргә булдым. Анда кичке мәктәп эшли иде. Ике җирдә укырга ярамый дип, мәктәпкә кабул итмиләр. Әмма мин бер көн калдырмыйча киләм дә утырам. Тегеләр белән бертигез иншалар язам, мәсьәләләр чишәм. Татар теле укытучысы Мәгъмүрә ападан калганнары минем эшне тикшерми иде. Кичке мәктәптә шулай ярты ел укыгач, яңа ел бәйрәме алдыннан, ташларга булдым. Мәктәптә беркемгә кирәкмәс таш кебек утырып булмый бит инде. Бу вакытта укый торган, укырга тиешле кешеләрнең яртысы мәктәпне ташлап бетерде. Күз яшьләремне тамыза-тамыза уникe битле инша яздым. Мәгъмүрә апа моны мәктәп директорына күтәреп кергән. Шуннан соң мәктәп директоры белән Мәгъмүрә апа училищега килеп, миңа укырга рөхсәт дигән кәгазь яздырып алдылар. Шулай итеп, иптәшләрем белән бергә урта белем алдым.

Кыен яклары күп булды инде. Ике җирдә укыйм бит. Фатир хуҗасы, утны күп яндырасың дип, кичке тугызда утны сүндереп куя. Әле ашау ягы да җайланмаган. Әти-әнидән акча сорамыйм. Ике көн ашыйм, ике

көн ач торам. Чөнки ике көн практика. Анда күбрәк ашап куясың да, ике көн ачлы-туклы йөрисең. Хәзер кайбер кешеләр махсус шундый диета тота. Сырма киеп йөргәнемне кеше күрмәсен дип, таң тишегеннән училищега килеп утырам. Урысчам да шомарыр дип, китапханәдәге бөтен китапны укып чыктым.

***Адәм булам дигәндә...***

Казан җитен комбинаты ашханәсенә аш пешерүче итеп эшкә җибәрделәр. Ярты ел эшләүгә, ашчылар бригадиры итеп куйдылар. Унсигез яшь тулар-тулмас вакытым. Плитәдә бер чиләк аш кайнап утыра. Идәнгә су түгелгән булган икән. Шул чиләкне күчереп куйыйм әле дип тотынган идем. Аягым таеп китте дә, чиләкне өстемә койдым. Җитмеш процент чамасы пешкәнмен. Мине хастаханәгә җибәрмәделәр. Комбинат күрсәткечләренә «суга» бит. Медсанчастькә салдылар. Бик тәҗрибәле карт доктор бар иде анда, матур килеш кияүгә чыгасың килсә, түзәсең инде дип, тән тиремне зеленка сылап дәвалады. Ярты ел эшкә чыга алмадым. Туганнар белән сөйләштек тә, пешкәнемне әти-әнигә сиздермәдек. Аларны борчыйсым килмәде. Ул вакытта хат язышу иде бит. Билгеле, әнием, бу бала нишләп кайтмый икән дип, борчылган инде. Арка пешмәгәч, ятып тора алдым. Шул коткарды мине. Яшь кеше, сәламәтлек тә бар. Дәвалангач, кабат бу эшкә кайтмам дип уйлаган идем. Ләкин ияләшкән эшемне ташлый алмадым. Бу һөнәрне яратып та өлгергән идем инде. Авыл, нәсел тәрбиясе, кечкенәдән эшләп үсү нәтиҗәсе бу. Ул гына да түгел, булсын дип йөрү. Җаваплылык хисе дә зур. Әти-әни әйткән һәр нәрсәне үзвакытында эшләргә кирәк дип уйлый идем.

КАИның Товарищеский урамындагы бинасында ашханә булмаган икән. Яңаны төзеделәр һәм анда ашханә ачып, мөдир итеп куйдылар. Җитәкче булып эшләү тәҗрибәсе шулай башланды. Шунда эшләгәндә, кияүгә чыккан көнемдә диярлек миңа өч бүлмәле кооператив фатир бирделәр. Киңәшләшер кешем дә бар. Янәшәдә, Әбҗәлил урамында гына безнеке кебек бер ашханә бар. Анда минем апам, Роза Мәхмүт кызы Комарова бик озак еллар директор булып торды. Өч-дүрт урында эшләгәннән соң, Советлар Союзы таралыр алдыннан, мине Черек күл янындагы, чәчәк кибете каршындагы пиццерияга мөдир итеп куйдылар (хәзер утыз елдан артык минем карамакта ул). Ансын да мин ачтым дияргә була. Берничә ай элек ачып, эшләтеп караганнар. Эшләп китә алмаган. Мин матур гына эшләтеп җибәрдем. Хосусый ширкәтләр ачу мөмкинлеге ачылгач, аны үз карамагыма алдым. Дөрес, тартып алырга тырышучылар байтак булды. Әмма ничек итсәм иттем, беркемгә дә бирмәдем, саклап калдым.

Илдә таркаулык башланды. Завод-фабрикалар ябыла. Кешеләр эшсез кала. Мин авыр хәлдә калган туган-тумачаларымны, кардәш тиешле ке-

шеләрне үземә эшкә чакырдым, бөтен туганнарымны диярлек җыйдым. Туганнардан тыш, үзебезнең Теләче районы яшьләрен, сабалыларны җәлеп иттем. Якташлык җәмгыяте кебек безнең ширкәтебез. Бер мәлне, 2008-нче елда, йөз кеше эшләгән коллективта иллесе туган-тумача булган икән. Моны гаилә бизнесы дип әйтергә мөмкин. Мин теге яки бу эш килеп чыкканда туганнарыма ташлыйм да китәм, дөрес, соңрак миңа тулы хисап бирәләр.

Әле мин унсигез ел элек, бизнесымны киңәйтеп, Дәрвишләр бистәсендә «Каенлык» дигән бер мең квардрат метр мәйданлы кафе сатып алдым, аны гөрләтеп эшләттем. Анда илле кеше эшли иде. Тик ул ябылды. Чөнки кафе каршына, яшелчә, күлмәк-ыштан сатучыларны ишәйтеп, базар шикелле итеп, зур павильоннар салып куйдылар да, ул капланып бетте. Банкет та ясап булмый башлады. Шулай итеп, өч-дүрт кешелек павильон куйганга, менә дигән илле һөнәри аш-су остасын урамга чыгарып җибәрәсе булды, бинаны арендага бирергә туры килде. Көнгә 600 кило он эшкәртә, татар халык аш-суларын әзерли идек бит. Кая куясың: бөтен җиһазны металлоломга тапшырдым. Нинди генә исемнәрем, казанышларым юк?! Ике ел рәттән «Ел хатын-кызы» булып танылдым, лабаса, хакимиятләр ярдәм кулы сузса, кафены саклап калып була иде. Күпме кеше эшсез калды бит...

Хәзер менә икенче зур эшем башланырга тора. Мәрҗани урамында алты катлы кунакханә төзеттем. Көз көне аны ачып, эшләтә башларга исәп. Анда шәт утызлап кешегә эш урыны булачак. Хәзер бит күп кенә кеше кредитта утыра. Шуңа күрә мин иң әүвәл кул астымда эшләүчеләрнең бурычларын үз вакытында түләүне кайгыртам. Ничек тә фатирлы итәргә тырышканымны күргәнгә, алар тагын да яхшырак, акчалырак эш булмасмы дип баш ватмый.

### *Ни өчен «Кукан», «Дворянское гнездо»?*

«Кукан»ның эшли башлавына – 11, «Ностальгия»гә – 12, «Дворянское гнездо» га – 7, «Пиццерия»га – 34 ел. Башта ресторанны «Морзалар мәҗлесе» дип атамакчы идем. Бозып, ямьсезләп әйтүләре бар дигәч (берәү, марҗалар мәҗлесе, дип тә ычкындырды), дворяннарныкына әйләнде ул. Патша заманында анда бакча булган, хәлле ханымнар, әфәнделәр ял итәргә яраткан. «Ностальгия»не сагынып студентлар килә (дуслар очраша торган әлеге ресторан эшли башлаганчы, бу төштән 270 «КамАЗ» машинасы чүп чыгарылды), иң матур, гайрәтле, яшь чакларыбыз бу якларда узды диләр. «Кукан» әтиемнең абыйсы Гыйниятуллага бәйле. Ул Үзбәкстанда зур кәнәфи билгән. Бервакыт бабам аңа кунакка бара. Шунда Гыйниятулла абзый бабама бик яхшы гарәп аргамагы бүләк итә. Бик ерак ара бит. Күрәсең, ул атны йөк вагонында, тимер юл

буенча алып кайткан. Монда аның колыны туа. Бик шәп чабышкы була ул. Төрле өязләрдә Сабантуйларда уздырылган бәйгеләрдә гел беренчелекне ала. Бервакыт үзебездә ярышка чыккач, янәшә чаптыручы, көнчелеге чыгып, атның йөзенә камчы белән суга. Әти егылып төшеп калса да, кукан ярышны дәвам итә, беренче булып килә. Әмма аңа барыбер беренчелекне бирергә теләмиләр. «Малайсыз атка ничек инде беренче урынны бирәсең?!» – дип тавыш куптаралар. Шуннан бабай: «Без монда малайлар чаптырабызмы, атлармы? Әнә илле малай узыша. Малайга бирергә җыенсагыз, шуларның беренче булып килгәнен бирерсез», – дип әйтә. Коллективлаштыру башлангач, атны колхозга алганнар. Атны кыйный-кыйный эшләткәннәрен күреп, бабай нәрсә эшләргә белмәгән, әти буразнага ятып, ауный-ауный елаган. Бераз соңрак бабай атны рәнҗеткән теге кешене тотып алып үзе кыйнаган. Аннан атны кочаклап елаган. Шунда моны күреп торган бер кеше, карагыз әле, карагыз, ике кукан елап тора, дип әйткән дә, безнең авылдагы кушамат «Кукан» булып киткән. Шуннан соң бабай, әти, мин, балаларым – бөтенебез дә «Кукан» кушаматлы. Кукан өч яшьлек атны аңлата. Башта шундый хурлана идем. Хәзер горурланам. Бу кафе үзе дә ат лапасы кебек эшләнде. Әнием, сүтеп ташла моны, дигән иде. Юк, сүтмим. Чабышкы атыбызга бер һәйкәл кебек ул.

***Иҗат дәрте***

Миннән еш кына, эшкуарлык бик күп вакытны ала, әдәби иҗатка ничек вакыт җиткерәсең, дип сорыйлар. Шигырь китапларым да, чәчмә әсәрләрем дә нәшер ителде. Шигырь язу акылдан язу белән бер чама инде ул. Оныкларым туа башлагач, ничектер күңелдә балалар өчен шигырь язу теләге уянды. Элек язганнары да бар. Алар әле архивта ята. Дәфтәр калынлыгындагы беренче шигырь китабым «Батыр малай» дип атала. Ата каздан курыкмаган, ата казны җиңгән Мурат дигән малай турында ул. Шул китап дөнья күргәч, «Мүкләк белән сөзгәк» кебек берәм-берәм башкалары чыга башлады. Оныклар туа, арта тора бит. Инде җидегә җыелдылар. Алты малай, бер кыз! Олылар өчен язылган шигырьләремне дә җыеп бастырдым. «Ялантауга ай кунган» повесте – татар хатынын пычратып, милләтебезне каралтып язган бер әсәргә җавап ул. Мин аны ачуымнан бик тиз язып аттым. Китабым бик күпләргә ошады. Кайбер районнарда повестем буенча укучылар конференцияләре оештыралар. Күптән түгел генә шундый бер очрашу Кайбыч районында булып узды. Тегесе бик популяр булгач, хәзер яңасын чыгарырга куркам. «Шомырт чәчәкләре ак кына» дигән бу романым ике кисәктән торачак. Мин аны һаман укыйм, төзәтәм. Әле минем язылып беткән «Елан кызы Акбану» дигән әкиятләр китабым үз чиратын көтеп тора. Аның сурәт-рәсемнәрен Кәринә Әсадул-

лина дигән 15 яшьлек туганым ясады. Шактый үзенчәлекле килеп чыкты ул. Анда шигырь белән проза үрелеп бара. Үземә ошады, әле аны кешегә укытканым юк.

Бизнеска хәзер балаларым килде, шуңа күрә иҗат эшенә вакытымны күбрәк бүлә алам. Инде мин гомумирәк, зуррак мәсьәләләр белән генә шөгыльләнергә тырышам. Шәт көзен ныклап кунакханә бизнесына алынырмын дип торам. Йөз кунакка исәпләнгән ул. Җиде оныгым бар дидем. Алла боерса, аларның берсен чит илгә кулинария буенча укырга җибәрәчәкбез. Чеби чыгара, ипи дә сала, торт та пешерә торган оныгымны әйтүем. Ул, иншалла, кондитер булачак. Минем эшне шул дәвам итәр дип уйлыйм. Башка чыккан, ягъни үз бизнесын булдырган кардәшләрем дә бар. Тормыш булгач, төрле аңлашылмаучылыклар, хилафлыклар килеп чыкканы бар. Алла сакласын, судлашып, дәгъвалашып йөргәнем булмады, булмас та. Әле менә бөтен туганнарыбыз да иркенләп кайтып йөрерлек, кунарлык булсын дип, шактый зур чыгым чыгарып, төп нигезне сипләттем. Кырыена яңа йорт салдырып куйдым (еш кына кырыгышар кеше җыелабыз). Элекке өйне хәтерләтеп торсын дип, унлап бүрәнәсен генә калдырдык. Әни, анда атаңның язуы бар, бу бүрәнәләрне калдыр, дип тә әйткән иде. Туганнарым, без дә акча бирәбез, дип өлешләрен кертмәкче иде. Алмадым. Миңа акча күбрәк кирә бит. Шунысы да бар: яшь олыгая барган саен, авыл үзенә күбрәк тарта.

***Эш кагыйдәләрем***

Бизнесны алып баруның берничә кагыйдәсе бар. Эшкуар беренче чиратта үз тармагын, җитештерүнең һәр буынын биш бармагы кебек яхшы белергә тиеш. Ресторан-кафе ачасың икән, идән юу, табынга кашык-тәлинкә тезеп куюдан башлап ризык әзерләүгә кадәр һәр эшне күзалларга кирәк. Үзең эшләп карасаң, бигрәк тә яхшы. Тагын бик мөһим бер кагыйдә: кешегә авыр сүз әйтмә; иртәгә әйтермен, дип тыелып кал.

Үз эшен башлап җибәрергә теләгән яшьләргә иң элек шуны әйтер идем. Кайберәүләр үз эшен ачалар да иң элек кәттә машина, фатир өстенә фатир ала. Эшкуар иң элек тотрыклылык фонды булдырырга тиеш. Мин бер көнлек, атналык, айлык, бер еллык һәм биш еллык план язам. Кичен өйгә кайткач, тикшереп чыгам: бүген эшләмичә, иртәгәгә нидер калмаганмы? Икенче көнне шул эшләнмәгәннән башлыйм. Мәсәлән, минем план буенча быел өч китап чыгарга тиеш. Аның берсе чыгып килә инде. Бу эшем күңел өчен. Яшьләргә әйтергә теләгән сүзем шул: андый-мондый кризис килеп туса (көтелмәгән хәлләр булып тора), аннан чыгар өчен, алда әйткәнемчә, тотрыклылык фонды булырга тиеш. Мин кризисларны күп күрдем. Андый фондың юк икән, янасың. Әйтик, машина ал-

дың, ди. Алган көнне үк аның бәясе төшә башлый. Чөнки инде ул ике-өч көн файдаланылса да, тотылган булып исәпләнә.

Акча калмас дип куркып утырма, салымыңны түләп куй. Кешегә хезмәт хакын вакытында бирергә онытма. «Эш кешесенең маңгаендагы тире кибеп беткәнче үк аның хезмәте өчен түләргә кирәк», – дип әйтергә яраткан Пәйгамбәребез. Бурычы булган кешеләргә, кредит тарихы бозылмасын дип, акчасын алдан биреп куям дип әйттем инде. Бөтен коммуналь чыгымнарын вакытында түләп барам. Шуннан калганы гына минеке. Акча килмәгән икән, булыр әле, килер әле дип, кыйммәтле ризык алып ашарга ашыкма. Ипигә май ягып ашау белән канәгатьлән.

Эшкуарлыкка алынып, шактый гына ныгысак та, без әле байтак вакыт «Нива» машинасында йөрдек, чит ил машинасы алырга ашыкмадык. Иремә, Сабантуйга кеше яхшы машиналарда кайта, без дә яхшырак машина алыйкмы әллә, дим. Мин үз ватаныбызның машина ясаучыларына булышам, дип елмая. Эшләүче кешегә хезмәт хакын вакытында бирә алмыйсың икән, димәк, синең эшең бармаячак, әлләни уңышка ирешә алмаячаксың.

*Рәшит Минһаҗ язып алды.*

*И.Г. Закирова*

## ЛУИЗА СЕБЕРЛЕ

2019-нчы елның 2–4 август көннәрендә Тубылда себер татарларының тарихи-мәдәни мирасын өйрәнүгә багышланган «Искер-җыен» Халыкара фестивале уникенче тапкыр узды. Россиянең төрле төбәкләреннән килгән фестиваль кунаклары, фестиваль кысаларында уза торган «Искернең тарихи язмышы» исемле XIII Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясендә катнашучылар себер татарларының рухи мирасын барлады, төрки халыклар мәдәниятенең уртак проблемалары, актуаль мәсьәләләре турында фикер алышты.



Әлбәттә, фестивальнең йөзек кашы «Искер-җыен» булды. Искер җыены себер татарларының гына түгел, бөтен татар халкының, Себердә яшәүче күп санлы төрки халыкларның уртак бәйрәменә әйләнеп килә. Биредә төрле регионнардан килгән кунаклар арасында татарлар гына түгел, казахлар, телеутлар, алтай халкы, тывалылар, руслар һәм башка халык вәкилләре дә бар иде. Сәхнәдә үзешчән башкаручылар, профессионал җырчылар, музыкаль коллективлар бер-берсен алыштырып торды. Килгән кунаклар бу җирнең гаҗәеп энергетикасын, үзенә тартып-чакы-

рып торуын, бирегә ел саен бик теләп килүләрен сөйләделәр. «Искер-җыен» күпләргә халык тарихын, туган телне өйрәнә башларга этәргеч биргән. Фестиваль онытыла, югала башлаган рухи-мәдәни мирасны – халык җырларын, биюләрне, йолаларны саклау юнәлешендә дә әһәмиятле эш башкара. Әлбәттә, чараның тагын бер ягын әйтми калдыру дөрес булмас, ул – дуслар җыелган, очрашкан, туганлык яңарган урын.

Бу фәнни-мәдәни чараларның башында Төмән өлкәсенең «Мирас» региональ татар иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Луиза Алимчан кызы Шәмсетдинова тора. «Искер-җыен» Луиза Алимчановна оештырган* бердәнбер чара түгел. Себер татарларының һәм башка төркиләрнең тарихи-мәдәни мирас фестивале «Сүзге тора», яшьләрнең һәм балаларның «Күчем хан оныклары» форумы да аның инициативасы белән уздырыла башлаган. Бу Луиза ханымның рухи мирасны барлау, торгызу юнәлешендәге эшчәнлеге. Шушы тынгысыз, максатчан ханымның икенче эш юнәлеше – Себер ханлыгының башкаласы Искерне күтәрү. Хәзерге вакытта анда ике катлы мәчет төзелеп бетеп килә, күккә ашкан манараларга ай куяр көннәр якынлаша. Янәшә төзелгән «Ханнар йорты» бинасында Себер татарлары музее эшли башлаган, икенче ягында килгән килгән кунаклар өчен чәй йорты урнашкан. Килгән кеше теләсә кайсы вакытта кереп чәйләп чыга ала. Кунак йорты да бар.

Себер татарларына Ислам динен шәйхләр алып килә. Җирле легендалар буенча 1394 елда бу якларга Бохарадан 366 шәех килеп чыга. Ислам динен таратучыларга үзенең коралланган 1700 батыры белән Урта Азия далалары ханы Шәйбани да ярдәмгә килә. Халык ислам динен үзе теләп кабул итмәгән очракта зур канлы бәрелешләр була. Шәехләрнең өч йөзе һәлак була, ә өчесе Себердә яшәп кала. Әмма аннан соң ислам дине кабул иткән халыкны укыту-өйрәтү өчен Бохарадан шәехләр, дин белгечләре күпләп килә башлый, шунда яшәп тә кала. Менә шушы шәехләр күмелгән урыннарны «астаналар» дип атыйлар. Луиза Алимчановнаның тагын бер күркәм эше – Искер тирәсендәге шушы астаналарны барлау, бу каберләргә таш кую, аларның аллеясын булдыру.

Хатын-кыз түгел, берничә ир-ат та башкарып чыкмаслык эшләр эшләнән бу ханым. Безнең халыкта «Йорт салуның ние бар – мүклисе дә, чутлыйсы» дигән мәкаль бар. Ул эшнең никадәр авыр булуын аңламаган кешеләргә карата көлеп әйтелә торган мәкаль. Бу очракта да, эшләгән эшләрне санап кына чыгу, аларның никадәр катлаулы булуын аңлата алмый. Башта төзелеш өчен рөхсәт алу, бусагалар таптау, хокукыңны

* Редакциянең искәрмәсе: Чынлыкта бу фестивальне башлап оештыру эшләрендә тарих фәннәре кандидаты З.Ә.Тычинских та актив катнашты һәм шактый еллар аның фәнни конференцияләрен хәзерләде. Соңыннан ул «Себер татарларының тарихын һәм мәдәниятын өйрәнү үзәген» булдырып, аның кысаларында «Сибирский сборник» исемле җыентыклар чыгаруга күчте.

кат-кат исбатлау, аннары материал, төзүчеләр табу. Эшләрнең финанс ягын барлау да Луиза Шәмсетдинова җилкәсендә. Луиза ханым Искерне күтәрүдә төп авырлыкны үз җилкәсенә алган Дамир Таһир улы Ибраһимовка кат-кат рәхмәт укый. Әлеге шәхес «Уралавтоснаб» оешмасы директоры. Ул проектның төп инвесторы, халык тарихына, мәдәниятенә битараф булмаган татар кешесе.

Бераз лирик чигенеш ясамасам, Луиза Шәмсетдинованың образы тулы булмас иде. Икътисад буенча югары белем алган ханым бу юлга ничек килә соң? Сорауга җавапны язучы һәм тарихчы галим Фәүзия апа Бәйрәмованың «Себердә татар тантанасы» дигән мәкаләсендә бәян ителгән. Луиза Алимчан кызының бер төшеннән соң башлана ул. Төшнең эчтәлеге болай: Күчем хан белән Ермак сөйләшеп утыралар. Ермак әйтә: Менә икебез дә юк инде. Әмма мине зурлыйлар, исемемне күтәрәләр, һәйкәлләр куялар, ә сине искә алган кеше юк. Күчем хан җавап итеп әйтә: Алай түгел, минем исемемне дә күтәрерләр, дип. Менә шушы хатын минем исемене торгызачак, дип, Луизага төртеп күрсәтә». Шул төштән соң Луиза Алимчановна Себер татарлары, Себер ханлыгы тарихы, Күчем хан турында кызыксына башлый. Әйтергә кирәк, җирле татарларда төшләргә зур игътибар сакланып килә. Луиза ханым фикере буенча, бу төш аңа очраклы кермәгән. Үзенең дә нәсел тарихы, ханнар нәселенә барып тоташа ахрысы.

Луиза Шәмсетдинова кедр урманы эчендәге Ворошилово поселыгында туа. Үзе дә «Мин кедр урманында туган» ди. Әтисе Леспромхозда җитәкче була, әнисе ветврач. Аннары Вагай районының Күбәк авылында яши башлыйлар. Әнисе ягыннан әбисе тумышы белән Татарстанның Чистай районыннан, әтисе ягыннан әбисе дә Казан ягыннан була. Ике бабасы да ханнар нәселеннән дип уйлый Луиза ханым. Әби-бабалары укытучылар була. Луиза Татар Вагае авылына йөреп, татар мәктәбендә укый. Укытучылары аның гаҗәеп тырыш, фикерле, кыю һәм максатчан булуын искә төшерәләр. Мөстәкыйльлеккә омтылган кыз сигезенче класстан соң техникумга керә, аны тәмамлап совхозда бухгалтер булып эшли башлый. Ул арада икътисад белгечлеге буенча югары белем ала.

Луиза 25 яшендә кияүгә чыгып, гаиләдә ике бала үстерәләр. Уллары Руслан белән кызлары Алсу да әниләре юлыннан китеп, финанс-икътисад юнәлешендә эшлиләр. Луиза Алимчан кызы балаларының үз милләтебез кешеләре белән гаилә коруын горурланып сөйләде. Хәзерге вакытта ул алты оныклы әби инде. Луиза ханым балаларына да туган телне, халык тарихын өйрәтеп үстерә. «Безнең гаиләдә туган телдә, үзебезчә кәпләшәпес, балаларым да, оныкларым да татарча әйбәт белә», ди ул. Балаларның халык тарихына битараф булмавы бер вакыйгада яхшы күренә.

Улы Руслан Күбәк авылының бер урамына «Хан Күчем» исеме бирергә кирәк дигән фикергә җиде яшьләрендә килә. Хәзерге вакытта Күбәк авылының бер урамы нәкъ шулай атала да.

Луиза Алимчан кызы булганына канәгать калып, тукталып кала торган кешеләрдән түгел. Бу аның һәр адымында күренә. Бер югары белем өстенә икенчесе кушыла, ул югары юридик белем дә ала. Болар турыдан туры эшен җиренә җиткереп эшләр өчен мәҗбүрият булса, өченче белем – лингвистика буенча, соңгысы Луиза ханым өчен туган телен фәнни югарылыкта белер, тикшерер һәм фәнни яктан өйрәнер өчен кирәк була. Ул Тубыл-Иртеш татарларының тел үзенчәлекләрен фәнни яктан өйрәнә башлый. Луиза Шәмсетдинованың халык иҗатына да мәхәббәте зур. Киләчәктә ул, себер татарларының Күчем хан, Сүзге, Себер ханлыгы турындагы риваятьләрен туплап бастыру турында да уйлый башлаган.

Быел Луиза Алимчан кызы Шәмсетдинованың юбилей елы. Аның эшләре турында гына сөйләп, бу вакыйганы онытып калдырсак, дөрес булмас иде. Луиза ханымны күреп белгән бер генә кеше дә 55 санының дөреслегенә ышанмый. Луиза Алимчановна, сезне юбилеегыз белән котлыйбыз, исәнлек-саулык, яңа максатлар, зур җиңүләр телибез, озак шулай яшь калыгыз. Изге эшләрегездә Аллаһы Тәгалә үзе ярдәм итсен.

*Илсөяр Закирова*

**Татар рухы**

**Татарский дух**

*Рабит Батулла*

# ЧЫҢГЫЗ ХАН

*(вафат булуына 790 тулды)*
*(Ахыры. Башын карагыз: № 1, 2019)*

## Җиһангирның әҗәле

Кытай җирендә Чан-чунь исемле бер Даос монахының могҗизалар эшләве турында ишетеп, Чыңгыз хан табипны үзенә чакырта. Имеш, Чан-чунь үлемсезлек серен тапкан (1219). Озын-авыр юллар узып, Монголия, Уйгырстан, Колҗа тарафларын Мәвараэннәһер, Сәмәрканд аша йөреп, Чан-чунь бөек хан янына килеп җитә. Бөек монах Чан-чунь белән бөек хан Чыңгыз 1222-нче елның 28 сентябреннән 1223-нче елның 11 апреленә чаклы бергә булалар.

Чыңгыз ханның Даос дәрвише Чан-чунга әйткән сүзе:

– Артык байлык туплаганнары һәм артык мәгърур булганнары өчен Күкләр Кытайдан ваз кичте. Ә мин Котып ягындагы далаларда яшәп, бозык гадәтләргә өйрәнмәдем, пакьлекне яратам, саф әхлакъны сөямен, байлык вә зиннәтне кире кагам, мин уртача, үземә таман шартларда яшим. Чабаннар ни кисә, шуны киям, алар ни ашаса мин дә шуны ашыйм...

1223-нче елның 10 марты көнне кабан аулаган вакытта Чыңгыз хан атыннан егылып төшә, егылуы бик каты була. Чан-чун киңәшен тыңлап, хан өч ай ауга чыкмыйча дәвалана.

Бөек җиһангир Чан-чунны үлемсезлек даруы табып бирергә чакырган иде. Ләкин Чан-Чун әйтте:

– Үлемсезлек даруы юктыр, бөек хан! Ләкин гомер озайта торганын табарга була! – диде.

Әмма Чынгыз ханның гомерен дарулар гына озайта алмый иде инде. Сунар вакытында аттан егылып төшүеннән соң аның сәламәтлеге көннән көн какшый башлый. Үлеме алдыннан уллары Угәдәй, Тулуйны һәм оныгы Исунке-Аканы чакыртып алды Чыңгыз.

– Балаларым! Мин бик күп җирләрне яулап алдым... Аның бер очыннан икенчесенә барып җитәр өчен бер ел вакыт сарыф итәргә кирәк булыр иде. Мин, балакайларым, сезнең аяк астындагы җирне ныгыттым... Васыятем шулдыр ки: патшалыкта ләззәт сөрер өчен, рәхәт кичәр өчен, дусларыгызның данын арттырыр өчен, дошманнарны җиңәр өчен сез бер фикердә булыгыз, бер кеше кебек бердәм-тату булыгыз! Угедей ханны варис итеп калдырыгыз! Үлемемнән соң минем Ясакны үзгәртү катгыян тыела! Патшалыгымда талаш-ызгыш булмасын өчен...

Чыңгыз ханның әҗәле турында да уртак фикер юк.

*1) Рәшид-әт-дин:*

– Бөек хан үз үлеме белән үлмәде, – ди.

*2) Плано Карпини:*

– Чыңгызны яшен сугып үтерде, – ди.

Күрәсең, бу сүз күчермә мәгънәдә кулланылгандыр.

Чыңгыз хан үз урынына Угәдәйне калдырып китә. Угәдәй идеаль дәүләт төземәк була. Аның әйткән сүзләре:

– Безнең бөек хан атабыз Чыңгыз күп кыенлыклар аша бөек ватаныбызны корды. Хәзер инде халыкларны таламаска, аларга тынычлык вә муллык бирергә вакыт җитте!

Чыннан да, Чыңгыз хан вакытындагы кебек яулап алу сугышлары Угәдәй тәхеткә утыргач, сирәгәя. Угәдәй каһан дәүләтендә яңа бер вазифалы дәрәҗә барлыка китерә – таньмачы (тамгачы), бу шәхес илдәге салымнарны җиңеләйтергә һәм почта эшләрен камилләштерү эшен үз карамагына алырга тиеш була. Һәр 30 чакырым арада бер ям* *(ыстанса)* булырга, шул ямда юлчыларга ашау-эчү, ятак, ат алмаштыру кебек мөһим шартлар булдырырга. Һәр ямда 1000 кеше хезмәттә торырга, андагы җылкыларны, куйларны көтәргә, аларны савып, сөт, кымыз ясарга тиеш булалар. Кызганыч, Угәдәй корган теләкләрен ахырынача җиткерә алмый кала, ул хәмер эчүгә салыша һәм 1241-нче елның 11 декабрендә вафат була. Авыр туфрагы җиңел булсын!

*3) Латтиморе:*

Ерак Тунгут өлкәсендә Кояш чәһрәле гүзәл кызы белән бер мәһабәт падишаһ яши иде. Чыңгыз хан саф килеш сакланган бер кызга өйләнмәк була. Киңәшчеләре ханга Тунгут падишасының кызы турында сөйли. Чыңгыз хан теләген үтәмәгәннәргә ни буласын падишаһ бик яхшы аңлый һәм кызын Чыңгыз илчеләренә биреп җибәрергә була. Ләкин хушлашу алдыннан ата кеше кызына бик тә үткер хәнҗәр бирә: бу хәнҗәрне ал, аны киемеңә яшереп сакла һәм вакыты килеп җиткәч, аның белән ни кылачагыңны аңларсың, ди.

---

* Рус телендәге «ямщик» – шушы сүздән.

Бөек яулап алучы Чыңгыз хан падишаһның кызы белән ятагына керә. Мөһим вакыт килеп җиткәндә генә кыз яшен тизлеге белән Чыңгызның җенси әгъзасын кисеп ташлый. Чыңгыз шәрран ярып акыра, аның авазына сакчылар йөгереп керә. Ләкин Чыңгыз хан аларга: бу кызны моннан алып чыгыгыз, минем йокым килә, дип урынга ята, шундук йокыга да китә, шул йокысыннан ул уянмыйча вафат була. [Owen Lattimore: 1941].

*Риваять.*

Чыңгыз хан тарафыннан җиңелгән бер каһанның хатыны ханны пычак белән суймакчы була, ләкин сарайга кергәндә аны тентеп, пычагын алалар, хатын чарасыз кала, әмма әсир хатын бик үҗәт вә нәфрәтле булып чыга, ул ханның асыл җирен тешләп өзә дә үзе тәрәзәдән суга ташлана.

*Риваять.*

Чин императорының хатыны Гүрбәлчиннең гүзәллегенә Чыңгыз ханның һушы китә. Җиһангир императорны үтереп, аның тол хатыны Гүрбәлчинне үз ятагына ала. Хатын Чыңгызны пычак белән җәрәхәтли. Хәле китеп хан егыла, аның һаман үлмәгәнен күреп, Гүрбәлчин бөек җиңүчене буып үтерә.

*Академик Василий Бартольд:*

Бөек Чыңгыз хан никадәр генә зиһенле, алдан күрүче булмасын, асылда ул, беркатлы сабыйлар кебек, үлемсезлеккә ышанган кеше. Даос монахы Чан-чунь чыннан да үлемсезлекне эзләгәндер һәм тапкандыр да. Ләкин Чыңгыз хан үлемсезлекне туры мәгънәсендә, физик мәгънәдә генә күз алдына китергән, күрәсең. Даос фәлсәфәсендә үлемсезлек турында Дань тәгълиматы бар, ул «фәлсәфә ташы» дип атала. Чан-чунь әнә шул тәгълимат вәкиле. Бу монахлар рухи дөньяда гына хәзинә табарга омтылалар, тормышның вак-төяк мәшәкатьләреннән аерылып, бар булганына риза булып, фәлсәфи тынычлыкка, фәлсәфи камиллеккә ирешергә омтылалар. Берничә айлар буена булган әңгәмәләрендә Чун-чань рәхимсез яулап алучы, бихисап күп бай шәһәрләрне харап иткән, миллионлаган халыкларны кырган бөек җиһангир Чыңгыз ханны кан коюлардан, илләрне талаудан ваз кичтерергә һәм үлемсезлеккә яхшы гамәлләр аша гына ирешергә мөмкин икәнлеген аңлатырга тырышкандыр, мөгаен.

Чынлыкта исә, яманлык кылганмы ул, әллә яхшылыкмы, Чыңгыз ханның исеме инде мәңгеләштерелгән, аның шәхесенә булган кызыксыну көннән көн арта гына бара.

## Чыңгыз ханның хромосомасы

*2003-нче елның мартында «Amerikan Journal of Human Genetics» журналында гадәттән тыш бер мәкалә басылып чыкты. Генетиканы өйрәнүче 23 белгеч-галим катнашында Евроазиядә яшәүче 2000 ләп ир кешедән алынган ДНК үрнәкләре тикшерелде. Галимнәрне хәйранга кал-*

*дырганы шулдыр ки, алынган үрнәкләрнең берничә дистәсе, тикшерелүчеләрнең кайсы илдән килүенә карамастан, уртак геннарга ия кешеләр булып чыга. Бу модель Каспийдан алып, Атлантика океанына хәтле сузылган киң мәйданга таралган халыкларга бер-берсеннән күчә килгән. Бу –шул мәйданда яши торган халыклар арасындагы 16 000 000 ир кешенең асылда бер геннан үрчегәнен раслый.*

*Y (игрик) хромосомасы хатыннарда булмый, ул бары тик ир җенесле адәмнәрдә генә була. Шушы хромосомада һәр ирнең үз «имзасы» була икән. Әнә шул имза аша бүгенге ир кешенең 850 ел элек яшәгән борынгы бабасын хисаплап чыгарганнар. Тикшеренүләрдә катнашкан галимә Татиана Зәрҗал ул борынгы бабаның исемен ачыктан-ачык:*

*– Чыңгыз хан! – диде.*

*(Җоһн Ман «Чыңгыз хан, хәяте, үлеме вә яңадан терелеше.» 13–14 битләр).*

Чыңгыз ханга чаклы булган җиһангирлар Искәндәр Икемөгезле *(Александр Македонский)*, мөселман илләренә булган Хаҗ яуларының каһарманнары, Чыңгыз ханнан соң яшәгән җиһангирлар Аксак Тимерләр, Баязид Елдырымнар, Сөләйман Канунилар, Наполеоннар, генералиссимус Сталиннар халыкларны кол итеп, шәһәрләрне юк итеп, артларыннан миллионлаган мәетләр, харәбәләр калдырып, нинди сәгадәткә ирештеләр соң? Урта гасырдагы дөньяга баш булган мангул кавеменнән ни калды? Өйрәтелмичә дә каһарман, бизәнмичә дә гүзәл булган мангул токымы кайда? Чинда *(Кытайда)* калган мангуллар Мао-Цзе-дун тегермәненә эләгеп, юкка чыгу чигенә килеп җитте, бу якта калган мангуллар Совет империясенең артта калган бер вассалы сыйфатында көчкә җан саклап килде. Чинда калганнарның күбесе кытайлашты; Европага, Русиягә ябырылган мангуллар да татарлашты, мөселманлашты. Бурят-мангуллар белән калмыклар урыслашуга йөз тоткан иде. Хәзер элеккеге бөек Мангул дәүләте җирләрендә яшәгән мангул булмаган күп халыкларның ирләрендә сакланып калган ДНКдагы 16 000 000 Y хромосомы белән мактансалар гына инде!

Хара-Даван язганча, шулай да бөек җиһангир Чыңгыз ханның максаты башка бөек яулап алучыларныкыннан шактый нык аерылган.

Искәндәр дә ярты дөньяны яулаган иде, Ләкин Искәндәр үлүгә үк гаскәр башлыклары Искәндәрнең хакыйкый варисы булган углын куып, тәхет өчен сугыша башлыйлар. Дәүләт таркала.

Наполеон да бөтен дөньяны яулап алырга теләгән иде. Чыңгыз ханнан аермалы буларак, ул үз гаскәрләрен иң авыр вакытта ташлап киткәләде –Мисырда зур гаскәрен калдырып качты, Русиядә бичара хәлдә калган гаскәрләрен ташлап качты һәм гомерен төрмәдә тәмамлады, улы

мирассыз калды, бөек җиһангир Наполеонның дәүләте үзе үлгәнче үк җимерелде.

Ленин–Сталин корган Советлар Союзы да йөз ел яши алмады, таркалды.

Ә Чыңгыз ханның империясе һәм варислары үзе үлгәннән соң 500 ел яшәде. Чыңгыз нәселле Кырым ханы Шаһин Гәрәй XVIII-нче гасырда (1783) тәхеттән төшерелде һәм шуның белән Чыңгызның ханлык нәселе төкәнде.

Аның максаты дала халыкларын бергә туплап, Бөек Дәүләт кору һәм шунда тынычлык һәм гаделлек урнаштыру иде!

Нинди төгәл зиһният белән корылган Чыңгыз хан дәүләте дә җимерелгәч, черек баганага төзелгән Русия империясенең егыласы көн кебек ачык. Ленин белән Сталин бүген уянсалар, үзләре төзегән «коммунизм»-ны күреп шаккатарлар иде. Халыкларга бәхет алып киләбез дип, бу ике Иблис милләтләрне фаҗигага, гариплеккә этәргәннәр икән, лабаса. XIX–XX-нче гасырларда яшәгән бөек вә рәхимсез деспотлар, бигрәк тә Сталин, Чыңгыз ханнан бик нык аерылып тора. Чыңгыз хан үзенә кайчандыр ярдәм иткәннәрне янына алдырган, үстергән, аларга дәрәҗәләр һәм идарә биргән, Сталин исә үзенең иң якын яраннарын үтертүдән тәм тапкан.

Мөхәммәт пәйгамбәр дә бик күп илләрне яулап алган гаскәр башлыгы: Испания, Африка, Төркия, Иран, Ирак, Кувейт, Кытай, Һиндстан, Пагыстан, Урта Азия, Идел буе Исламны кабул иткән... Ләкин Мөхәммәтнең Исламга өндәве белән Чыңгыз ханның басып алулары арасында аерма зур. Мөхәммәт халыкларны күпләп кырмаган, таламаган, Ислам дине кылыч белән кертелмәгән, мәҗбүрият аркасында мәҗүсиләр, христианнар, яһүдиләр арасында сугышлар булган икән, Мөхәммәтнең кан коешы Чыңгыз хан, Аксак Тимер койганнан күпкә, бик күпкә ким. Һәм Мөхәммәт үзе үлүгә аның империясе тиз генә таркалмый, әле бүген дә бер миллиард ярым мөселман Җир йөзендә яшәп ята. Миңа калса, Чыңгыз ханның киң колачлы яулап алулары тарихчыларны сокландырса да, Мөхәммәтнең гамәле игелекле булуы белән тарихчыларның игътибарын тартырга тиеш. Кылыч яулап алу коралы булса да, сына, чери, ә идея кодрәте сынмый да череми дә!

Чыңгыз хан Манчжуриядән Польшага, Себердән алып Һиндстанга хәтле бөек дәүләт корган шәхес. Аның империясе Искәндәрнекеннән дүрт, Римныкыннан ике тапкырга зур. Чынгыз ханның гаскәрләре бер Хәрәзмдә генә дә 3 миллион мөселманны кылычтан кичерде. Чынгызның дәүләте 28 миллион квадрат километр зурлыгында иде.

Чынгыз хан канэчкеч, миһербансыз бер залим идеме? Әйе, ул күп халыкларның кырган. Ләкин аның залимлеге алда исемнәре аталган-

нарныкыннан артык түгел. Италия, Испания, Франция, Нидерланд конкистадорлары Американың җирле халыкларына карата Чыңгыз ханнан миһербанлырак идемени? Иван Грозный, Петр I, Русиянең башка императорлары җирле халыкларга Чыңгыз ханнан да миһербанлырак булганмыни?

Мәңгелек Җәннәттә очрашкач, Чыңгыз хан да аптырар иде.

– Кайда минем бөек дәүләтем? Кайда минем дөньяга баш буласы бөек мангул милләтем? – дияр иде.

Бөек хан татарча сөйләшә торган миллионлаган мөселман торыннары, кытайча сөйләшә торган миллионлаган буддачы-мангуллар белән очрашкач, ни дияр иде икән?

– Кытайлашыгыз, татарлашыгыз, үзбәкләшегез, казаклашыгыз, дип төзедеммени мин дәүләтне?

Бөек җиһангир Чыңгыз хан Дуңгыз елында *(1227, 25 августында)* вафат була. Аны Бурхан Халдун тавына җирлиләр, ләкин тауның кайсы урынына җирләнгәне сер булып кала бирә. Шаһитләр калмасын өчен, имеш, аны гүргә иңдергәннәрне үтерә барганнар. Мангулларның изге китабы *(The Secret History)* «Яшерен тарих»ында ханның дәфен ителүе турында берни дә язылмаган.

Инглиз тарихчысы Җоһн Манның Мангул дин эшлеклесе Шаралдай белән әңгәмәсе:

***Шаралдай.*** *Хөкемдарның җирләнгән урыны турында бүгенгә чаклы могҗизалар-серләр сөйлиләр... Чыңгыз ханга кылган гыйбадәтләребез Мәңгелек Күк белән бәйләнешкә керергә теләвебездән килә.*

***Җоһн Ман.*** *Ягъни Сез Чыңгызның Күк белән арадашчы булганлыгы турында әйтәсезме?.. Чыңгызга багышлап кылынган гыйбадәтләр христиан кешесенең бер изге һәйкәлгә-потка (иконага) карап дога кылганы белән берме? Христиан турыдан-туры сурәткә дога кыла, ләкин ул һәйкәл-пот күренмәс изге рухның чагылышы, символы гына һәм кеше белән Тәңре арасындагы күпер генәме?*

***Шаралдай.*** *Әйе, моның өч баскыч бар: үзеңне сабыр-түзем булырга өйрәтү, Мәңгелек Җәннәт фәлсәфәсенең төп баганасы – дөньяда яшәүчеләрнең Мәңгелек Җәннәтнең бер кисәге булып торуыдыр. Без үзебезне иерархиянең иң өске катында дип уйласак, без Мәңгелек Җәннәттән аерылган булырбыз. Кешеләр бүген моның кирәклеген вә әһәмиятен аңламыйлар. Мәңгелек Җәннәт, Мәңгелек Җәннәтнең кодрәте вә Мәңгелек Җәннәтнең кодрәтенә баш ию... Бүген дөньяда яшәү фәлсәфе юк! Белем бар, ләкин вакыйгаларга бары тик өстән-өстән генә караш та бар. Белем атом-төш коралларын уйлап чыгара, тилергән адәмнәр ясаган ул куркыныч, файдасыз кораллар беркайчан да кулланылмаячак, чөнки кул-*

*ланган як үзе дә юкка чыгачак, шуңа күрә, ул кыйммәтле кораллар файдасызга тик ятачак! Җитәкчеләр атом-төш коралларын дошман якны куркытып торыр өчен генә асрыйлар... Бөтенесе дә Мәңгелек Җәннәтнең көче турында онытты.*

Менә *(Чыңгыз хан төрбәсен)* мавзолеен коруның төп максаты бу иде, бары тик мангуллар өчен генә түгел, бөтен дөнья өчен, җирләр яулаган һәркемне уйландырыр-уяндырыр өчен кирәк ул. Чын зиһният Мәңгелек Җәннәттә корылган бакчаның астында ятадыр. Китабымда әйткәнем менә шушы фикерне алга сөрергә этәрде. Чыңгыз хан барыбызның да җитәкчесе. Барыбыз да Мәңгелек Җәннәт тарафыннан яратылдык, әгәр аның юлыннан китсәк, ахырда барыбыз да үлемсез булачакбыз!

Чыңгыз хан үзенең Күк Тәңресе тарафыннан җир йөзенә җибәрелгәненә, Мәңгелек Җәннәтнең барлыгына һәм шул җәннәткә кererенә нык инана иде.

Анысын инде бер Аллаһу Тәгалә Үзе хәл итәр!

### Үзгә караш

Әле күптән түгел генә абруйлы галимебез Мәсгут Гайнетдин чыгарган «Мәңге тоныкланмас көзгебез» атамалы китапта (Тат. кит. нәшр., 2006.) борынгы тарихыбызга кагылышлы «Көнчыгыштан тәре яулары» дигән күләмле фәнни хезмәт урын алган. Автор «хач» сүзе урынына күнегелгән сүз «тәре»не кулланган. Гәрчә, «крестовые походы» гыйбарәсе «хач яулары» дип аталырга тиеш иде. Чөнки әдәбиятыбызда «икона-тәре» белән «крест-хач», мәгънәләрен бутау инде канунлашкан. Бу гыйбарәләрне бары тик керәшеннәр генә бутамыйча сөйли, бутамыйча яза. Өй почмагына куелган Мәрьям ана, Иисус Христос рәсемнәре икона – «тәре», ә муенга асып йөри торган крест – «хач» дип атала. Шулай итеп, «крестовые походы» гыйбарәсе «хач яулары» яки «хач сәфәрләре» дип аталырга тиеш.

Чыннан да, без тарих китапларыннан укып беләбез: Европа илләре йөз еллар буена христиан булмаган илләргә әледән әле һөҗүм итеп, аларны талап көн күргән, мөселман халыкларын юк итәргә теләгән. Ләкин Көнчыгыштан – Будда, Тәңре, Ислам, Шаман динле халыклар тарафыннан Европа тарафына хач яулары ябырылганы турында белүчеләр бик сирәктер. Галимебез Мәсгут Гайнетдиннең бу китабы татар мохите өчен генә түгел, бөтенрусия, бөтеневропа, бөтендөнья өчен дә гаять әһәмиятле хезмәт.

Бу китапны җентекләп укып чыккан соң аңларсыз: бөек Чыңгыз ханның, Батый ханның яулары ул Көнчыгыштан чыккан хач сәфәрләре икән. Юкса, Чыңгыз хан да, Батый да кычкырып торган христианнар түгел. Аларның несториан юнәлешендәге христианнар икәненә тарихта дәлил-

ләр юк түгел. Әлбәттә, галим Мәгсут әфәнде бу материалларны фараз, гоман шәкелендә генә китерә, ләкин аның тикшеренүләрендә мантыйк аксамый.

*Гомумән алганда, Үзәк Азия күчмәләре арасында христианлык IV–V гасырларда тарала башлый* [Гайнетдин: 2006. 8 б.].

*Бу төбәкләрдә VIII гасыр урталарына җиде епископлыкны берләштергән првослав Хәзәр-Харәзем митрополитлыгы оетырыла* [Гумилев: 1989. С. 163].

Европа ягыннан Иерусалимгә хач яулары башланган чорда Урта Азия һәм Үзәк Азия халыклары арасында (XII–XIII йөзләрдә) христианлыкның киң таралганлыгы турында мәгълүмат күп.

Европа дәүләтләренең берләшкән хәрби куәтләре Иерусалимдә аерым христиан католик дәүләте коруга ирешәләр. Ләкин мөселманнар тарафыннан каршылык та куәтле була. Идел буенда туып үскән мәмлүк баһадиры (бүгенге татар-нугайларның борынгы бабасы) Бәйбарс хач яуларына каршы аяусыз көрәш башлый. Күп уңышларга ирешә. Иерусалимдәге христиан дәүләтен саклап калырга көчләре калмаган христиан җитәкчеләре Көнчыгыш христианнарына өметләр баглыйлар, алар тарафыннан Ауропага хач яулары әзерли башлыйлар.

Алга таба автор Мәсгут әфәнде Чыңгыз ханың христиан анадан туганы турында да, шул христианлыгы аркасында гаиләдән куылулары турында да, Чыңгызның атасы Ясүгәйнең татарлар тарафыннан түгел, үз туганнары тарафыннан агулап үтерелүе турында да, Тимучинның Чыңгыз ханга әверелүе өчен христиан кераитлар үҗәт рәвештә тырышканлыгы турында да ышандырырлык дәлилләр китереп яза.

*Татар-монгол яуларының Көнбатыш христиан (католик) дөньясы белән бәйләнеше Батый дәверендә тагын да калкурак чагыла. Хәтта аның маршруты да инде Рим папалары белән герман императорлары арасындагы мөнәсәбәтләр белән турыдан – туры бәйләнгән. Мәгълүм булганча, X гасырлардан (Оттон Беренче вакытыннан) бирле, герман императорлары белән Рим папалары арасында Ауропа илләрен кул астына алу өчен каты ызгыш барган... 1230-нче елда Папа гаскәрләре тармар ителә. Ләкин моны папаның капитуляциясе дип уйларга һич ярамый. Бу чорда Рим папалыгындагы корольләр императорларны тезләндерерлек көч – кодрәткә ия була. Икеләнерлек урын юк. Григорий IX да үзен җиңелгәнгә саный алмый, баш бирмәгән императорны ул тәре яуларының «икенче фронты» – дәһшәтле монгол яулары тоягы астында юк итәргә карар кыла. Бу яңа монгол явының оештыру «штабы» да, Чыңгыз ханныкы кебек үк Үзәк Азия була. Анда 1235-нче елда гомуммонгол корылтае үткәрелә, яу башлыгы итеп Җучиның олы улы Урда-Ичен бил-*

*геләнә, тик бу дәрәҗәне ул энесе Батыйга тапшыра* [Гайнетдин: 2006. 25 б.].

Шулай итеп, атаклы Чыңгыз хан һәм Батый хан яуларының Рим папасын герман императорларының дәһшәтеннән коткарырга алынган монгол (хач) яулары икәненә ышана башлыйбыз. Чыңгыз ханның мөселманнарга булган нәфрәтен дә, Батый ханның урыс чиркәүләрен ясактан азат итү гамәлләренең серен дә шуннан чыгып аңлый башлыйбыз.

Ярый, Чыңгыз белән Батый ярымтәңрече, ярымшаманчы, ярымхристиан булган, шуңа күрә алар мөселман шәһәрләрен җимергәннәр. Ә Аксак Тимер үзе мөселман килеш тә Чыңгыздан да арттырып мөселман илләрен тар-мар китерә, шәһәрләрен җир белән тигезләп, ясмык чәчтерә, күп тапкырлар үзбәкләрне кыра, болгар-татарларның калаларын җир белән тигезли, фарсыларны пыран-заран китерә. Моны ничек аңларга?

Аксак Тимер Чыңгыз хан кебек үк үзен Алла химаясындагы кеше дип хисаплый. Чыңгыз илләре, Аксак Тимер биләмәләре аша узган христиан сәяхәтчеләре (җасуслары) мөселманнарны, төркләрне үзара талаштырып, Ауропаны афәттән саклап калу белән мәшгул булганнар; болары да хач яуларының дәвамыдыр.

*(Тәмам)*
*11.03.2007.*

## Әдәбият

1. Гайнетдин Мәсгут. Мәңге тоныкланмас көзгебез. Казан: Тат. кит. нәшр., 2006.
2. Гумилев Л.Н. Древняя Русь и Великая степь. М.: Мысль, 1989.
3. Owen Lattimore. Mongol Journeys. N.Y., 1941.

***А. Г. Хәйретдинов***

# КОРЪӘНДӘ БӘЯН ИТЕЛГӘН РЕИНКАРНАЦИЯ ТӘГЪЛИМАТЫНА КЕРЕШ

*Мәрхәмәт кыйлган Мәрхәмәтле Аллаһның исеме белән*

Минем бу язмамда ислам диненең, хаслап алганда Коръәннең әлегә кадәр игътибардан читтә кала килгән, бәлки дә, махсус сурәттә яшерелгән бер тәгълиматы аңлатылачак. Әлеге тәгълимат җаннарның башланган ноктасы булмаган тәмугътан соңгы ноктасы булмаячак оҗмахка таба туктаусыз-өзлексез сәфәр кылулары турындагы, башкача әйткәндә *реинкарнация** турындагы тәгълиматтыр.

Моннан күп еллар элек мин ислам динендә реинкарнация күренеше хакында бер ни дә әйтелмәве турындагы карашны яклап бер бәхәс мәҗлесендә катнашкан идем. Мине шул бәхәстә катнашыр өчен чакырып алучылар исламда реинкарнация тәгълиматының барлыгына ышана торган берничә татар зыялысыннан гыйбарәт булган төркем иде. Үзләренең бу дәгъваларына дәлил буларак алар Коръәннең ***«Алар: «Раббыбыз! Син безне ике мәртәбә үлдерден һәм ике мәртәбә терелттең! Һәм без гөнаһларыбызны таныдык. Чыгышка таба берәр юл бармы?», – дип әйттеләр»*** (40:11), дигән айәтен китерделәр. Башка дәлилләре юк иде. Араларында гарәп телен белүчеләр дә юк иде, шуңа күрә бу айәтне Коръән тәрҗемәсендә күреп алып, аны реинкарнациягә дәлил буларак кабул иткән булганнар.

Ул мәҗлес вакытында мин тешем-тырнагым белән дигәндәй, исламда реинкарнациянең юклыгын дәлилләргә тырыштым. Югарыда искә алынган айәтне дә мин шул күзлектән аңлаткан идем: беренче үлдерелү ул җанның юклыгы. Икенче үлдерелү – кешенең кабергә салынуы, имеш; беренче терелтелү – җанның барлыкка китерелүе, икенче терелтелү – мәетләрнең терелтелеп каберләреннән кубарылулары. Моннан тыш, Мөнкир белән Нәкир турындагы фәрештәләр турында да, кабер газаплары турында да сөйләгән идем, гәрчә бу нәрсәләр турында Коръәндә бер ни дә әйтелмәгән булса да. Кыскасы, ул истәлекле көнне ислам тәгълиматы турында ни белгән булсам, шуларны эшкә җиккән идем, сөйләгәннәремә дәлил буларак кулланган идем.

Хәзерге вакыттан ул чорга карап минем ул чактагы дәлилләвемнең әллә ни ышанычлы һәм төпле булмаганлыгын күрәм. Әмма иң зур хатам ошбу булган икән: мин үзем кичермәгән, үзем белмәгән нәрсә ту-

* Реинкарнация (лат. reincarnatio – татарчасы: «яңадан туу»; урысчасы: «перевоплощение») яки метемпсихоз (борынгы юнанча – «җаннарның күчеп йөрүе»). Әлеге тәгълимат үлемсез җаннарның бер тәннән икенче тәнгә күчеп йөрүен күздә тота.

рындагы бәхәстә катнашканмын. Ул чакта мин Аллаһы турында булсын, ислам турында булсын, иман, гыйбадәт, савап-гөнаһ кебек, кыямәт, җәннәт-җәһәннәм һәм башка шуның кебек нәрсәләр турында булсын – боларның һәммәсен дин әһелләре сөйләгәннәреннән ишетеп кенә, дини китапларда язылганнардан укып кына беләидем. Шуларны дин дип, үземне исә динне, азмы-күпме, белә торган кешемен, дип уйлый идем. Әмма югарыда искә алынган төшенчәләрнең, ягъни Аллаһ булсын, ислам булсын, иман, көфер, гыйбадәт, савап-гөнаһ булсын, кыямәт, җәннәт-җәһәннәм булсын – боларның берсен генә булса да миң үзем кичергән нәрсә буларак белми идем, шуңа күрә бәхәс дәвамында аларны үз тәҗрибәмнең бер казанышы буларак аңлата алмый идем, кайдан да булса укыганыма, кайдан да булса ишеткәнемә нигезләнеп кенә бәхәсләшә идем. Шулай да, мәҗлестә катнашучылар: «Ислам динен яхшы беләсең икән», – дип озатып калдылар. Бәхәстән соң алар реинкарнациягә карата фикерләрен үзгәрттеләрме, юкмы – анысын әйтә алмыйм, чөнки алга таба ул кешеләр белән һич аралашканым булмады.

Байтак еллар үткәч кенә мин ул очрашуның нинди тирән мәгънәгә ия булуын аңладым. Дөресрәге, миңа аның мәгънәсен аңларга Аллаһ тәгалә мөмкинлек бирде. Ул аңлау да бит миңа кисәк кенә ишелеп төшмәде. Бик күп төрле вакыйгалар аша уздым, күпне кичердем, тәҗрибә тупладым, акны карадан, ялгышны хатадан, ялганны дөреслектән аерырга, диндарлык белән «диндарлык» арасындагы аерманы күрергә өйрәтелдем. Шул рәвешле узган еллар дәвамында бөтенләй башка кешегә әйләндерелдем, дип әйтсәм дә була. Нәтиҗәдә, ул истәлекле очрашуның да минем өчен нәрсәсе белән әһәмиятле булуын аңлый алырлык хәлгә килдем. Беренче чиратта ул очрашу минем үзем өчен кирәк булган икән, чөнки анда катнашырга насыйп итүе белән Раббым миңа *«Үзеңнең бу очрашу вакытында, бу бәхәс дәвамында нинди карашларда булуыңны исеңдә калдыр, онытма»*, – дип искәртеп куйган сыман булып чыкты. Ягъни, кайчандыр мин ислам дине белән реинкарнация тәгълиматының берберсе белән һич тә янәшә тора алырлык нәрсәләр булмавына катгый рәвештә инана идем. Тик ул инануым дини китаплардан, тәфсирләрдән, вәгазь-хотбәләрдән алынган мәгълүматка нигезләнгән иде. Ягъни ул чакта реинкарнация мәсьәләсендә мин бүгенге көндә ислам динендә кабул ителгән гомуми һәм рәсми бер караш тарафтары идем.

Дөресен әйткәндә, минем ул халәтемне инану дип атарга ярамый да, хәтта. Аны *инану*, дип түгел, *кабатлау*, дип, *тәкълид*, дип атасаң дөрес булыр. Ә иң дөресе – чүбек чәйнәү булган ул. Ягъни, мин хакыйкатьне белми идем. Нәкъ киресе: дини китаплардан, вәгазь-хөтбәләрдән ишетеп үзләштергән белгәннәремне «хакыйкать шушы инде ул!», дип уйларга өй-

рәтелгән идем. Хәзер аңлыйм ки, мин бик нык ялгышкан булганмын, хәтта аңгыра, аңсыз берәү булган икәнмен. Мондый аңсыз хәлдә мин хәтта туплаган белемемнең асылда бары тик билгеле бер күләмдәге мәгълүматтан, хәбардарлыктан гыйбарәт булуын аңлар хәлдә дә түгел идем. Ул чакта аңсыз булуым сәбәпле мин «иман белән белем бер нәрсәдер», дип ышанганыма күрә аларның икесе ике төрле нәрсә булуын аера алмаслык халәттә яши идем. Ул чакта мин чын белемнең кешенең бары тик үз тәҗрибәсе нигезендә барлыкка килә торган нигъмәт булуын аңламый идем. Шуңа күрә «белемем», дип санаган нәрсәләр һич белем булмаган, иманым дип уйлаганым иман булмаган, хакыйкать дип уйлаганым хакыйкать булмаган. Нигә шулаймы? Чөнки ул чакта мин, хәтта, үзем дә әле юк идем...

Шулай да, Аллаһның рәхмәте, ригаясе һәм тәрбиясе белән минем эчке үсеш-үзгәрешем дәвам ителгән булган икән, чөнки байтак еллар узгач урта гасырларда яшәгән бер мәшһүр мөселман галименең *«игътикад белән белемне тәңгәлләштерү заманыбызның үтергеч бер бәласенә әйләнде»*, дигән сүзләрен күргәч, аның ни әйтергә теләгәнен шундук аңлый ала алдым. Аңладым да, хәйран калдым...

Ә бит юлымның башында мин бу әйтелгәннәрне аңларлык хәлдә түгел идем.

* * *

Моннан алдагы язмаларда сүзебез барлыкның Аллаһтан аерылгысыз булуы турында, барлыкның җегәрдән, җегәрнең нурдан торуын, нурның Аллаһның үзе булуын, терек Аллаһтан гына гыйбарәт булган барлыкта аның капма-каршысы булырлык үлемнең юклыгы турында фикерләр бәян ителгән иде. Әлеге нәрсәләрне аңламастан җаннарның күчеп йөрүе турындагы тәгълиматны кабул итү кыен да, кабул ителгән очракларда да аны аңлау ни төзек була алмый, ни дә ныклы була алмый.

Инде сүзебезне дәвам итәр өчен бер үтә дә әһәмиятле сорау куйыйк: җанга кеше гәүдәсе бирелде дә, ул җир йөзенә килде, ди. Әҗәленә тигән кадәр вакыт дәвамында җан җирдә яшәде ди, кайгысын да күрде, ди, хәсрәттән дә өлешенә тигәнен кичерде ди, ягъни кабер газабын узды, ди. Аннары үлеп китте ди. Шулай итеп җан тәннән кубарылды, Аллаһ хозурына китте, ә ул җанны йөрткән тән кабердә череп таркалырга калды. Моннан соң ни була? Әйе, голәмәләрнең өйрәтүенчә, җан кире кабергә иңә дә, шунда җавап бирә, аннары кыямәтне көтеп ята имеш. Ул җан кичә генә ахирәткә күчкәнме, моннан ике ел элекме, егерме елмы, ике йөз елмы, ике мең елмы, егерме мең ел элекме – һич әһәмияте юк: җан бер мәртәбә кеше тәненә ия булып дөнья дип аталган шушы сынау мәйданына атыла да, булдырган кадәрен майтарып, үлем фәрештәсе тарафыннан алынып, аннары кире кабергә иңдерелеп, череп таркалган калдыклар

арасында шул сынау мәйданында кыйлганнары өчен җавапка тартылачак сәгатен көтеп ята имеш.

Ә бит тарих фәненең раславынча, кешеләр, ягъни кеше тәненә ия булган җаннар, моннан ике йөз мең ел элек тә, ике миллион ел элек тә, егерме миллион ел элек тә, алтмыш биш миллион ел элек тә җиргә килеп яшәгәннәр, сынауга куелганнар. Алар да каберләрендә кыямәт купканын көтеп яталармы?

Бу сорауга: «Нух пәйгамбәр, галәйһис-сәлам, туфаннан коткарылып, шуннан башланган токым гына җавапка тартылачак, ә туфан моннан 10–12 мең ел элек булган», – дип җавап бирүчеләр бар. Әмма Коръәндә: ***«Без Адәм белән килешү корган идек инде, тик ул онытты»***, – диелә. Ягъни, Аллаһы тәгалә белән Адәм, галәйһис-сәлам, арасында корылган килешү гамәлдә кала бирә. Адәм, әлбәттә, Нух пәйгамбәргә кадәр булдырылган, ул хәтта беренче кешедер. Тик аның кайчан булдырылганы билгеле түгел. Егерме миллион ел элекме, ике йөз миллион ел элекме – нәмәгълүм. Һәрхәлдә, Перуда аждаһалар, ягъни динозаврлар белән бергә яшәгән, аларны эшкә җиккән, алар ярдәмендә күңел ачкан, өсләренә атланып яу чапкан кешеләрне сурәтләгән рәсемле бик борынгы ташлар табылган. Мәгълүм булганча, аждаһалар моннан 65 миллион ел элек юкка чыгарылганнар. Димәк, Адәм токымы моннан инде 65 миллион ел элек дөбердәтеп яши биргән. Шул заманнардан башлап бәдәннәргә иңеп, җир йөзендә гомер иткән һәр җан җавапка тартылачак. Бер мәртәбә җиргә килеп, җиде булсын, утыз булсын, кырык яки аннан да күбрәк дистә ел дәвамында яшәгәннән соң кабердә 65 миллион ел дәвамында Кыямәт купканын көтеп ятучы бер җанны күз алдыгызга китерегез... Ул җәннәткә лаеклы булса да, бу кадәр вакытны кабердә үткәрү җәһәннәмнең дә иң яман җәһәннәме түгелме?

Бу мәсьәлә турыда әнә шундый сораулар туа. Ул сорауларның җаваплары да бармы икән?

Җаваплары бар, әлбәттә. Җавап эзләп әллә кая барасы да юк, ул җаваплар Коръәннең үзендә бар. Әмма җавапларга күчкәнче безгә бер мөһим чигенеш ясап гыйлем белән иман кебек төшенчәләр турында бераз фикер йөртеп алырга кирәк булачак.

Коръәнне укыганда, укылган айәтләрнең мәгънәләре турында без бераз гына булса да уйларга да тиешле, әлбәттә. Уйлагач кына билгеле нәтиҗәләр ясала, белем барлыкка килә. Белем, ягъни, гарәпчә – *гыйлем* дигәндә, хәтта Аллаһы тәгалә дә үзеннән иман түгел, тәкъва түгел, сабыр түгел, ә нәкъ менә гыйлем сорарга кушкан: ***«Әйт: «Раббым, мине гыйлем белән арттырсана!», – диген»*** (20:114).

Игътибар итегез, бу дога, ягъни үтенеч: «миңа гыйлем бирсәнә!», «минем гыйлемемне арттыр!», дип түгел, «мине гыйлем белән арттырса-

на!», яки «мине гыйлемләндер», булып яңгырый. Чыннан да, гыйлем кешене булсын, җанны булсын – зурайта, олы итә, гыйлемнең әһәмиятенә күрә кешене дә, җанны да югарырак дәрәҗәгә күтәрә. Һәм тагын да әһәмиятлесе бар: гыйлем ул иманудан да өстендер, кадерлерәктер. Мәсәлән, Аллаһы тәгалә бардыр һәм бердер, дип инану – ул бер халәт, ә моның чыннан да шулай булуын белү – бөтенләй икенче халәт, күпкә югары булган халәт. Шуңа күрә булса кирәк, Коръәндә гыйлемле булуның, белемле булуның кыйммәтлелеге, мәртәбәсе һәм гыйлемлелек дәрәҗәләренең бихисап булуы кат-кат искә алына: ***«Үзебез теләгәннәрнең дәрәҗәләрен күтәрәбез, һәм һәр белем иясеннән югарырак булган тагын бер белүче бар»*** (12:76). Ягъни белемнең чиге юк, иң югары ноктасы юк, һәм, әгәр Аллаһы тәгалә теләсә бәндә булсын, җан булсын – гыйлем баскычлары буйлап һич туктамастан яңадан яңа дәрәҗәләргә күтәрелә алалар.

Гыйлемнең иманнан өстен булуын Коръән бәяннарында кат-кат күрәбез. Мәсәлән, «Мөхәммәд» сүрәсендә Аллаһы тәгалә Мөхәммәд галәйһис-саләмгә ***«Аллаһыдан башка бер илаһ юклыгын бел»*** (47:19), – дип әмер итә. «Бәкарә» сүрәсендә Аллаһы тәгалә Ибраһим пәйгамбәргә: ***«Аллаһының хикмәткә ия булган гыйззәтле булуын бел!»*** (2:260), – ди. Ягъни, «Аллаһыдан башка бер илаһ юклыгына инан», – диелмәгән. Инану гына аз. Аллаһыдан башка бер илаһ юклыгын белергә кирәк. Мондый боерыклар пәйгамбәрләргә карата гына әйтелмәгән, гади кешеләргә карата да күп мәртәбә әйтелгән: ***«Аллаһының мәрхәмәтле гафу кыйлучы булуын белегез!»*** (5:34); ***«Аның белән кавышачагыгызны белегез!»*** (2:223).

Шуңа күрә, җаннарның тәннән тәнгә, шәхестән шәхескә күчеп йөрүләре турында сүз кузгатабыз икән, моны бер фараз итеп кенә кабул итәргә түгел, Аллаһтан үтенеп, бу хакта белем бирүен сорарга кирәк.

* * *

Моннан алдарак җәннәткә лаеклы булып да, дистәләгән миллион еллар дәвамында кабердә ятарга дучар ителгән бер җан халәте турында уйлана башлаган идек. Инде дәвам итик. Билгеле булганча, җаннар Аллаһы тәгаләне үзләренең Раббы, ягъни Тәрбиячесе итеп таныячаклары турында сүз биргән булганнар. Димәк, кеше гәүдәсендә җиргә килеп сынаулар узачак һәр җанның иң беренче вазыйфасы булып Аллаһы тәгаләне исенә төшереп аның барлыгын һәм берлеген тану, Аңа гыйбадәт кыйлу тора. Коръәндә бу турыда болай диелгән: ***«җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гаыбадәт кыйлуларыннан кала һичнәрсә өчен халык кыйлмадым»*** (51:56).

Хуш, монысы аңлашыла. Димәк, болай булгач, кайчандыр Аллаһыга «Сине Раббым буларак, Тәрбиячем-Багучым буларак таныячакмын!», – дип сүз биргән һәр җан ул вәгъдәсен үтәргә тиеш. Бу сүзен тотуы-тот-

мавына күрә җанга җәзасы да биреләчәк: ул җан йә җәннәтне казаначак, йә җәһәннәмгә атылачак. Мәгълүмдер ки, Аллаһы тәгаләне таный алу кешенең билгеле бер яшькә җитеп балигъ булуына, акылы сәламәт булуына бәйле нәрсә. Ягъни, җиде яшенә җитеп балигъ булган һәм сәламәт акыллы бала гына шәһадәт кәлимәсен әйтеп үзенең ислам динен сайлавы турында хәбәр бирә ала, үз өстенә шәригать хөкемнәрен үтәүне ала, шәригать хөкемнәренә күрә хөкемгә тартыла ала. Болай булганда, аның турылыклы мөселман булып, игелекле бәндәләр җөмләсеннән булып гомер итүе һәм, кыяматтән соң җәннәткә кертелүе ихтималдыр. Һәрхәлдә, дини китапларда шулай язылган. Тик, дини китапларда аның мөселман булып та, иман иясе булмау ихтималы турында сүз юк, гәрчә Коръәндә бу хакта айәтләр булса да. Дини китапларда мөселман булуы-булмавына карамастан һәркемнең дә җәһәннәм аша узачагы турында искәртүләр, кисәтүләр юк, гәрчә Коръәндә бу хакта кычкырып торган айәтләр булса да. Без бу айәтләр турында алдагы язмаларыбызда инде сүз йөрткән идек, шуңа күрә, аларны истә тотыйк.

Яхшы: һәр җан Аллаһы тәгаләгә сүз биргән икән, һәр җан шул сүзен тотарга тиеш, ә Аллаһы тәгалә үз тарафыннан шул сүз тотылсын өчен, җанның биргән вәгъдәсе чынбарлыкка аша алсын өчен мөмкинлекләр, тиешле шартлар тудырылып тора: җанга кеше гәүдәсе, акыл, күз-колак, башка әгъзалар, һава, су, азык-төлек һ.б.ш. ризыкларны әзерләп куйган, җанны җир йөзенә китергән. Инде чират җанда – сүзен тотачакмы, юкмы? Моның өчен аңа бердәнбер мөмкинлек бирелгән – нибары бер гомер. Дини китапларда шулай язылган, һәрхәлдә. Тик ул китапларда кеше турында әйтелә, җан турында түгел.

Инде бер фараз: шулай итеп, Раббысына биргән сүзенә хуҗа булуын күрсәтергә дип ашкынып торган, «түбән булган тормышка иңәм дә, Раббыма биргән вәгъдәмне үтим», дип атлыгып торган җан, ниһаять, бала тәнендә дөньяга килде дә... ике көннән, ике атнадан, ике елдан, ягъни, балигъ булганчы, әҗәле җитүе сәбәпле шул бала тәнен калдырырга мәҗбүр ителде ди. Югарыда язылганнардан четерекле бер сорау туа: шундый хәлгә калган җан Раббысына ничек итеп җавап бирер икән? Яшьли үлгән бала ничек җавап бирәчәк?

Әлбәттә, бу сорауга күз ачып йомганчы җавап бирүчеләр табылмый калмас: «Аллаһы тәгалә кешеләрне әле барлыкка китергәнче үк кайсысының җәннәткә, кайсысының җәһәннәмгә эләгәчәген билгеләп куйган!», – диярләр.

Андыйлар мондый җавапны кайдан алганнардыр, белмим, тик ул җавап Аллаһы тәгаләнең тиңдәшсез гаделлек иясе булуына каршы килә. Болай булганда, Аллаһы тәгалә аңа сүз биргән җаннарның һәммәсенә дә

бертигез башлам шартлары тәэмин итәргә тиеш. Ягъни, безнең югарыда китерелгән мисалга нисбәттән, һәр җан сәламәт акылга ия булган кеше буларак балигълык дәверенә ирешеп, күпмедер вакыт шул балигъ зат буларак яшәп алу мөмкинлеге белән тәэмин ителергә тиеш. Бу шарт үтәлгәндә генә ул җан үзенең сүзендә тора алуын яки тора алмавын исбатлый ала. Чынлыкта ул башлам шартларының тигез булмавын истә тоткан хәлдә дини китапларда язылганнарга таянып фикер йөртә башласак, Аллаһы тәгаләнең гадел булмавы турындагы нәтиҗәгә килә алабыз. Ә нигә шундый нәтиҗәгә килмәскә ди? Ул дини китапларны язган галимнәр шундый нәтиҗәгә килгәннәр, әнәтрә, һәм Аллаһы тәгаләнең гаделлегенә тап төшердек, дип һич тә кайгырмаганнар.

Юк, мин ул галимнәр язып калдырган һәм Аллаһының күптөрле сыйфатларының берсенә генә булса да тап төшергән уйдырмалары белән ризалаша алмыйм. Шуңа күрә, «кешенең балигъ булганчы ук үлүе нәтиҗәсендә ахирәткә күчеп китәргә мәҗбүр булган һәм шул сәбәпле Раббыларына биргән вәгъдәләрен үти алу мөмкинлегеннән мәхрум ителгән җаннар Раббыларын танымаганнары өчен ничек җавап бирәчәкләр икән дә, гаделлек иясе булган Аллаһы тәгалә Үзен танымаулары сәбәпле ул җаннарны мәңгелек җәһәннәмгә ни өчен һәм ни йөзе белән сөрер икән?», – дигән сорау әлегә бик зур сорау булып кала.

Хуш, инде алга таба барыйк. Һәр җан өчен дә, җаннарның һәммәсе өчен дә тигез башлангыч шартлар бирелгән, дип фараз кыйлыйк. Ягъни, җаннарның һәммәсе җир йөзенә китерелеп, һәммәсенә дә сәламәт тәнбәдән, аек акыл, сәламәт әгъзалар бирелә, ул тәннең балигълык яшенә ирешүе тәэмин ителә, картаеп ахирәткә алынганчы «яшәргә» вакыт бирелә. Болар һәммәсе дә урынында, диик. Безнең бу фаразыбызда тик бер генә нәрсә үзгәрешсез калсын әлегә: Раббысына биргән сүзен тота алачагын яки тота алмаячагын күрсәтер өчен һәр җанга бары тик бер форсат, бер тән, бер гомер бирелә, имеш.

Болай булса ниләр булыр иде икән?

Җаннар күп. Биниһая күп. Без аларның никадәр булуын белмибез белмәячәкбез дә. Хәзерге вакытта җир йөзендә 7 миллиардка якын кеше яшиләр. Димәк, җир йөзен таптап йөрүче кешеләрнең саны җиде миллиард булса, ул кешеләргә иңдерелгән җаннарның саны да җиде миллиард булып чыга. Ә безнең көнгә кадәр ничәмә-ничә миллион еллар дәвамында ничәмә-ничә миллиардлар килеп киткәндер дә, каберләрдә Кыямәт сәгате сукканын көтеп ятадыр... Акылга сыймаслык саннар!

Мисал өчен бер фаразланган җанны алыйк. Үзенең бу түбән булган яшәеш мәйданындагы сәфәрен аңа бик фәкыйрь гаиләдә, бик фәкыйрь илдә туып башларга насыйп булды, ди. Ул ач-ялангач булып үсте, бали-

гъ булды, белем-фәлән ала алмады, чөнки фәкыйрь иде, белем алмаган җәмгыятьнең югары катламнарына да үрмәли алмады, шуңа күрә картайганчы угрылык белән шөгыльләнеп көн күрде, ди. Дөнья көтәр өчен аның башка юлы юк иде. Гөнаһ кыйлмас иде дә, тик, урламаса, ач калыр иде. Киярено киеме дә булмас иде. Өйләнү, гаилә кору дигәндә, әйтеп тә торасы юк – аның хәлендә бу нәрсәләр хыял гына булып калда бирде. Шулай итеп башы гөнаһтан чыкмастан бу фаразланган җан, тәнен җирдә калдырып Ахирәткә, дарел-бәкага алынды, ди. Инде, сорау: бу гомер сәфәрен гизгән җанга ни булачак: җәннәтме, җәһәннәмме? Әллә ни тегесе, ни монысы булмаячакмы? Ул бит ислам пәйгамбәре килгәнче яшәгән иде, шуңа күрә потларга табынучылар динендә иде.

Ә хәзер тагын бер җанның тәкъдиренә күз салыйк: ул бай гаиләдә туды, әмма гарип иде: кул аяклары хәрәкәтсез, күзе сукыр, колагы ишетми, борыны ис тоймый... Ата-анасы ислам динендә иделәр. Тик бай булсалар да, иң олы дин галимнәрен сарайларына чакырып алып, хәлләрен аңлата алсалар да, балаларына Аллаһ турында, дин турында бер генә булса да сүз, бер генә булса да ишарә ирештерә алмадылар. Шулай көенеп, кайгы-хәсрәт утында янып һәммәсе дә әҗәл сәгате җиткәч Ахирәткә күчтеләр.

Аңлашылганча, кешеләрнең язмышлары һәм аларның күрмеш-кичермешләренең биниһая төрлелеге кеше акылына сыя торган, иң кыю күзаллау белән колачлана торган нәрсә түгел. Бу дөньяга баксаң әгәр, җаннарның һичкайчан да ни тигез башлангыч шартлар белән, ни тигез яшәү шартлары белән тәэмин ителмәгәнлекләрен күрәсең. Һәрхәлдә, безгә шулай күренә. Алга таба акыл белән биләнеп алына алмый торган әлеге нәрсәләр турында фикер куертудан мәгънә юк. Шуңа күрә, Коръәнгә мөрәҗәгать итик, аның айәтләрендә бәян ителгән хакыйкатьләр турында уйланыйк, бәлки безне дөрес нәтиҗәләргә китерәчәк юлларыбыз да ачылыр.

Коръәндә ***«Без сезне куркыта торган нәрсәләр белән, ачлык белән, малыгызның кимүе белән, исәннәрнең саны кимүе белән һәм җимешләрнең кимүе белән, һичшиксез, сыныйбыз»*** (2:155);

***«Без сезне фетнә буларак яманлык белән дә, яхшылык белән дә сыныйбыз һәм сез Безгә кайтарыласыз»*** (21:35);

***«Кайсыларыгызның кыйлганнары яхшырак булуын сынау өчен Ул үлем белән яшәешне булдырды»*** (67:1–2), – дигән айәтләр бар. Бу айәтләрдән аңлашылганча, Аллаһы тәгалә җаннарны сыный. Әлбәттә, беренче карашка, сынауга нәкъ менә кешеләр дучар ителәләр. Әмма, (67:1–2) нче айәтләргә игътибар белән карасак, бу турыда бераз башкача уйлата торган нечкәлекләр күренә. Шулай да, фикер сөрешен беренче айәттән башлыйк.

Бәкарә сүрәсенең (2:155)нче айәтеннән күренгәнчә, җаннар, яки, хуш, кешеләр булсын, ди, күптөрле михнәтләргә юлыгалар. Гомумән алганда, сынаулар аша узу яки узмау кешеләрнең һәммәсе өчен дә мәҗбүридер: ***«Сездән әүвәлгеләрнең башына килгәннәрнең тиңе сезгә килмәстән генә җәннәткә керәчәкбез дип уйлаган идегезмени? Аларга мохтаҗлык та, чирләр дә кагылды, алар җир тетрәвенә дә дучар ителделәр»*** (2:214); ***«Кешеләр әллә: «Без иман китердек!» – дигәннәре аркасында [тынычлыкта] калдырылырлар да, фетнәләнүләргә дучар ителмәсләр, дип уйлыйлармы?»*** (29:2). Әлеге ике айәттә әйтелгәннәр, әлбәттә, Коръәнне пәйгамбәр авызыннан ишеткәннәргә дә аталган булган, аларны хәзерге вакытта укучыларга да. Шулай булгач, үзләрен иман иясе дип санаганнар да, имансыз булып саналган башкалар да – һәммәсе сынаулар ташкынына атыла. *Түбәндә булган тормыш*, ягъни дөньялык, шул сынаулар мәйданы буларак булдырылган да инде.

Инде «Бәкарә» сүрәсенең (2:155)нче айәтенә кабат күз салыйк. Караган саен кызыклы фикерләр туа тора. Мәсәлән, бер җан дөньялыкта мохтаҗлык белән генә сыналды да, бакыйга күчте, ди. Аннары Кыямәт көнендә җавапка тартылды да, җәһәннәмгә атылды, ди. Башка бер җан дөньялыкта мул тормышта яшәде, кайгы-хәсрәт, ачлык-ялангачлык кичермәде. Ул да җәһәннәмгә эләкте, ди. Болай булганда, дөньялыкта чагында һич рәхәт чыраен күрмәгән җан, баягы рәхәт тормыш кичереп җәһәннәмгә эләккән бәндә белән чагыштырганда кимсетелгән булып чыга түгелме? Аңа карата гаделсезлек кыйлынды түгелме? Әйе, без фараз кыйлган ике җанның икесе дә җәһәннәмдә утта яналар, әмма аларның берсенә дөньялыкта булганында ук ни өчен мескен тормышы насыйп ителгән иде дә, нидән икенчесенә – рәхәт тормыш? Алар әллә, җиргә киләчәк җаннар буларак Аллаһыга сүз биргәндә үк бертигез түгелләр идеме? Берсе начар, берсе аннан да яман идеме? Аллаһы тәгаләнең гаделлеге ноктасыннан карасаң, болай булырга тиеш түгел, ләбаса! ***«Аллаһ бәндәләренә золым теләми»*** (40:31), дигән айәткә карасак, мондый гаделсезлек һич тә булырга тиеш түгел: ***«Ул бит золым кыйлучыларны сөйми»*** (42:40).

Әлбәттә, дини китапларда бу мәгънәви-мантыйкый каршылык: «Аллаһ ни кыйлганын үзе генә белә», – дигән сүз белән әйләнеп узыла, җавапсыз калдырыла, чишелми. Ә чынлыкта, «ни кыйлганын үзе генә белә», дип әйтү Аллаһка карата зур җинаять, чөнки бу очракта Аллаһ чыннан да ни теләсә шуны кыла торган залим булып чыга. Мисал китерик: бер кеше туды, ди дә, Аллаһы тәгалә аңа насыйп иткән коточкыч авыр тормыш шартлары тозагына эләгеп, гел михнәттә яшәде, ди, ни иман, ни дин, ни тәкъва, ни бер рәхәт күрмәгәненә күрә һаман яман гамәлләр кыйлды да, китте ди. Әлбәттә, ул кеше җәһәннәмгә атылачак. Дини китаплар-

да бу болай аңлатыла: Аллаһы тәгалә ул кешенең җәһәннәмгә атыласын баштан ук белгән дә, имеш, шуңа күрә аны шундый авыр тормышка дучар иткән, имеш. Тик, Аллаһы тәгаләне болай күзаллаганда аның бер залим булуына ышанырга туры киләчәк. Дини китапларны язган кешеләр Аллаһның гаделлегенә кагылышлы әлеге четерекле мәсьәләне чишүдән баш тартканнар, әмма Аллаһны залим итеп калдыру берабәренә шулай иткәннәр. Чөнки алар җаннарның күчеп йөрүләре турындагы тәгълиматны танымаганнар, кабул итмәгәннәр. Ә бит шул «Бәкарә» сүрәсенең (2:155)нче айәте, миңа калса, һәр җанның, әйе, кеше кыяфәтендәге аерым шәхесләрнең түгел, ә нәкъ менә һәр җанның төрле-төрле сынауларга дучар ителүе турында хәбәр итә. Ул җан мохтаҗлыкны да татый, авыруларны да, бәла-казалар аша да уза, рәхәт, күңелле чаклары да була, бәхәет-сәгадәттә гизгән вакытлары да була. Тик, бу кадәр сынаулар аша узу өчен бер генә гомер җитми шул...

Ә хәзер ***«Без сезне фетнә буларак яманлык белән дә, яхшылык белән дә сыныйбыз һәм сез Безгә кайтарыласыз»*** (21:35), дигән айәткә күз салыйк. Нәкъ югарыда әйтелгән фикерне кабатларлык: җаннар яхшылык белән дә, начарлык белән дә сыналалар. Тик, чынлыкта, гадәттә, берәү гел яманлыкта гомер итә, башка берәү гел рәхәттә: бай гаиләдә туа да, тәмле ашап, матур киенеп, һич нужа күрмичә гомер итә дә, ахирәткә күчә. Ә айәт бит җанны рәхәт белән дә, михнәт белән дә сынау турында хәбәр бирә. Димәк, җиргә килеп бер яшәгәндә җан рәхәттә гизәргә мөмкин, икенче килгәндә – михнәттә, өченче килүендә – тагын бер хәлдә, дүртенче килгәндә башка бер хәлдә... Җан төрле-төрле халәтләр, сынаулар аша уза алсын өчен Аллаһ тәгалә үлемне булдырган: ***«кайсыларыгызның кыйлганнары яхшырак булуын сынап карар өчен үлем белән яшәешне булдыручы Улдыр»*** (67:1–2).

Чыннан да: җаннарны Аллаһ булдырганмы? Әйе. Саф, гөнаһсыз хәлдә яратканмы аларны? Әлбәттә. Нигә соң аларның берәүләрен баштан ук «монысы җәһәннәмгә керәчәк», – дип, берәүләрен «җәннәткә керәчәк», – дип тамгалап куйган, имеш? Җаннарның ни гаепләре бар иде? Алар бит әле хәтта кеше тәненә иңеп дөньяга да килмәгәннәр иде ул чакта! «Аллаһы тәгалә аларның җирдә ни кыйласыларын алдан ук белгәнгә күрә тамгалаган», – диләр. Гасырдан гасырга шундый җавап биреп киләләр. Хуш. Болай булгач, ***«кайсыларыгызның кыйлганнары яхшырак булуын сынап карар өчен үлем белән яшәешне булдыручы Улдыр»*** (67:1–2), дигән айәтнең аларның бу җавапларына нигә каршы килүен аңлатып бирсеннәр. Я, булмаса, менә тагын бер айәт: ***«Арагызда кайсыларыгызның тырышучылар икәнен һәм сабыр итүчеләр икәнен белеп ачыклаганга кадәр сезләрне, һичшиксез, сынаячакбыз»*** (47:31). Бу айәттә Аллаһы тә-

галә кешенең ни кыйласын баштан ук белеп торуы турында әйтәме, әллә, җанның үзен ничек күрсәтәсен ачыклаганга кадәр, белеп алганчыга кадәр аны түбән булган яшәеш мәйданында гомер иттерәчәге турында әйтәме?

Димәк, Аллаһы тәгалә җаннарны төрле халәтләр аша үткәрә. Җанның төрле халәтләр кичерә алуы өчен ошбу сынау мәйданы – дөньялык, түбән булган тормыш, җан сәфәре башланып киткән түбән нокта булдырылган. Дөресрәк итеп әйткәндә җан сәфәре башланып киткән нокта түгел. Җан үзенең сәфәрен дәвам итә. Кеше тәненә иңдерелеп сират күперенә бастырылганына кадәр дә җан сәфәрдә булган. Ул сират күпере җәһәннәм өстеннән сузылмаган. Сират күперен узу – кеше тәненә бикләнелгән җанның бу дөньяда сәфәр итүедер. Күперне үтә алмадың икән – кире бу дөньяга кайтарыласың да, туктаган урыныңнан хәрәкәтеңне дәвам итәсең. Үткән тормышыңда кыйлган гамәлләрең хәерле булса, һәр яңа тәнгә иңдерелгән саен сәфәрең җиңеләя, яманлыгың өстенлек итсә – авырая. Сәфәрнең Сират күперен узу дигән мөһим өлешен башлаганда җаннар бертигез башлангыч шартлар белән тәэмин ителәләр. Аннары, кыйлганнарына күрә, үсешләренә күрә, яулаган дәрәҗәләренә күрә аларның сыналу шартлары да, сынау алымнары да үзгәртелеп тора. Бер җан бары тик яхшы тормыш белән, яки начар тормыш белән сыналмый, ул яхшысын да татый, яманын да. Болай булуны Коръәннең ***«Без сезне фетнә буларак яманлык белән дә, яхшылык белән дә сыныйбыз һәм сез Безгә кайтарыласыз»*** (21:35), дигән айәте раслый. Аллаһының берлеген таныганга кадәр җан башта динсезлек, аннары потпарәстлек халәтен, ягъни потларга табыну халәтләрен дә кичерергә мәҗбүр була, исламга кадәр булган диннәрне тоту халәтен дә. Ислам диненең кагыйдәләрен, шәригатен кабул итү җанга туры юлга, сәфәренең финиш өлешенә чыгарга мөмкинлек бирә.

Потларга табыну халәте, дигәндә бер чигенеш ясап кайбер мөһим әйберләрне аңлатып узарга кирәк. Потларга табыну халәтенең Аллаһ тарафыннан булдырылуы турында Ибраһим пәйгамбәрнең кавемдәшләренә әйткән сүзләреннән күрә алабыз. Аның потларны җимерә башлавы турында белеп алган кавемдәшләре Ибраһимне кыйнарга дип янына убырылалар. Ә Ибраһим аларга: ***«Үз кулларыгыз белән чокып ясаган нәрсәләргә гыйбадәт кыйласызмыни?»*** (37:95), – дип әйтә. Аннары, ачыргаланып: ***«Хәер, Аллаһ булдырды сезне дә, сезнең кыйлганыгызны да»*** (37:96), – дип өзеп куя.

Бу айәтне тәфсир кыйлганда яки тәрҗемә иткәндә зур мәгънәви һәм лингвистик хата эшләнә. Мәсәлән, Габделбари хәзрәт Исаев аны болай итеп тәрҗемә иткән булган: ***«Үзегез юнып ясаган нәрсәгә гыйбадәт кыласызмы? Сезне һәм эшләгән нәрсәләрне Аллаһ яратты»***. Рабит Ба-

тулла тәрҗемәсендә болай диелгән: ***«Үз кулларыгыз белән юнып ясаган нәстәләргә табынасызмы? Гәрчә сезнең үзегезне дә кулларыгыз белән ясаган ул нәрсәләрнең барысын да Аллаһ барлыкка китерде, – диде»***. Ногмани тәфсирендә болай диелә: *«Ибраһим әйтте: «Үзегез агачтан, таштан юнып ясаган нәрсәләргә гыйбадәт кыласызмы? Бит үзегезне дә вә сез сыным ясаган агач, ташларны да Аллаһ юктан бар кылды»»*. Гарәп теленнән урыс теленә тәрҗемә ителеп Казанда бастырылган «әл-Мөнтәхәб» исемле Коръән тәфсирдә болай диелә: *«Әллә инде үз кулларыгыз белән ташлардан ясаганнарыгызга табынасызмы? Сезнең акылыгыз кайда соң? Чынлыкта Аллаһ сезне дә яратты, сез үз кулларыгыз белән ясаган потларны да яратты. Ул табынылуга лаек булган Бердәнбердер»**.

Әлеге мисаллардан югарыда искә алынган зур хатаның нидән гыйбарәт булуы бик яхшы аңлашыла. Ул мисалларның барысында да потларның Аллаһ тарафыннан барлыкка китерелүе бәян ителә. Тик, нидәндер, шул мизгелдә барлыкка килгән бик зур мантыйкый каршылыкка, сәламәт акыл тарафыннан кабул ителмәячәк башбаштаклыкка игътибар ителми: Ибраһим пәйгамбәрнең сүзләренә күрә кешеләрнең үз куллары белән ясалган потлар бер үк вакытта Аллаһ тарафыннан барлыкка китерелгән булсын ди? Хәер, шулай булсын да. Тик бу очракта, Аллаһ үзе потларны барлыкка китергәннән соң кешеләрне шул потларга табына башлаганнары өчен җәзага тартырга тиеш түгел. Болай итү бит кычкырып торган гаделсезлек булачак. Тик, юк, потларны, кешеләр ясаганнар. Бу турыда Ибраһим пәйгамбәр үзе әйтә. Башта: «Үз кулларыгыз белән ясаган потларыгыз», дигәннән соң, икенче җөмләдә үк үзе әйткәненә каршы килеп: «Потларыгызны Аллаһ яратты», дияр идеме икән бу олуг пәйгамбәр? Ибраһим, галәйһис-сәлам, әйтмәс иде, әмма тәфсир кыйлучылар әйткәннәр. Аларның ялгышлары Ибраһимнең соңрак әйткән сүзен дөрес тәрҗемә итмәүгә, дөрес аңламауга кайтып кала. ***«Аллаһ булдырды сезне дә, сезнең кыйлганыгызны да»***, дигән айәттә ***«сезнең кыйлганыгызны да»*** (*вә ма тәгъмәлүнә*) рәвешендә килгән сүзтезмәдә *гамилә* фигыле кулланылган. Бу фигыльне һич тә *ясарга* (*сделать*), дип тәрҗемә итәргә ярамый. *Ясарга*, дигән мәгънәне бирер өчен гарәп телендә башка фигыльләр бар, мәсәлән, *сәнәга* фигыле: ***«фиргавен һәм аның кавеме ясап яткан** (кәнү йаснәгунә) **нәрсәләрне җимердек»*** (7:137). Бу йөздән «мин гөнаһ ясадым», дип әйтү нинди зур хата булса, *гамилә* фигылен дә *ясарга*, дип тәрҗемә итү шундый ук зур хатадыр, чөнки «мин гөнаһ

* Урысчадан тәрҗемә. Урысчасы болайдыр: «Неужели вы поклоняетесь тем, кого вы своими руками создали из камней? Где же ваш разум? Поистине, Аллах вас сотворил и сотворил идолов, которых вы делаете своими руками. Он – Единый, кто заслуживает поклонения». Кара: [Аль-Мунтахаб фи тафсир аль-Кур’ан аль-Карим: 1421 г. хиджры (2001 г.). С. 419.].

кыйлдым», булырга тиеш. «Мин урындык кыйлдым», дип әйтү дә зур хатадыр, «мин урындык ясадым», булырга тиеш. Г. Исаев та, Р. Батулла да, «әл-Мөнтәхәб» тәфсире дә гамилә фигылен дөрес тәрҗемә итмәгәннәр. Ә инде Ногмани хәзрәтләренең тәфсиренә килгәндә, бигрәк тә кызыклы хәл килеп чыга. Әлбәттә, Ногманинең Р. Батулла кебек: ***«сезнең үзегезне дә кулларыгыз белән ясаган ул нәрсәләрнең барысын да Аллаһ барлыкка китерде»***, – дип әйтергә теле әйләнмәгән, чөнки ул *гамилә* фигылен болай итеп тәрҗемә итүнең хата булачагын бик яхшы белгән. Шуңа күрә, әл-Мөнтәхәбнең «Аллах вас сотворил и сотворил идолов», дигән авторы кебек, «Аллаһ потларны барлыкка китерде», дип язып Ногмани зур ахмаклык кыйла алмаган да. Әлеге четерекле урынны тәфсир кыйлу өчен ул *«үзегезне дә вә сез сыным ясаган агач, ташларны да Аллаһ юктан бар кыйлды»*, дияргә мәҗбүр булган. Әйе, Ногмани белән бу урында бәхәсләшеп булмый кебек: барлык матдәне, шул исәптән агачларны да, ташларны да Аллаһ булдырган. Ногмани хәзрәтләре тәфсиренең бер генә җитешсезлеге бар: «Аллаһ тәгалә агач вә ташларны булдырды», дигән сүз әлеге айәттә юк, ләбаса! Ногмани хәзрәтләренең бу кадәр кыюлыгына исең китәрлек. Аның ***«Китапны үз куллары белән язганнан соң «Менә бу Аллаһтандыр», – диючеләргә бәла булсын!»*** (2:79), дигән айәтне укыганы булмаган бугай дигән уйлар килә башлый...

Бу искә алынган *гамилә* фигыле *кыйлырга* (*совершать*) буларак кына тәрҗемә ителергә тиеш. Мәсәлән, «урындык кыйлдым», дигән гыйбарәдә «кыйлдым» фигылен куллану дөрес түгел, шуңа күрә «урындык ясадым», дияргә кирәк. «Дога ясадым», дип әйтү дөрес түгел, «ясадым» фигылен мондый мәгънәдә кулланмыйлар, шуңа күрә «дога кыйлдым», дип әйтү дөрес була. Гарәп теленең *гамилә* фигылен куллануда да шундый үзенчәлекләр бар.

Болай булганда, әлеге айәттә кешеләрнең дә, аларның кыйлмышларының да Аллаһ тарафыннан булдырылуы турында хәбәр бирелә. Бу очракта кешеләрнең кыйлмышлары аларның потларга табынуларын белдерә. Димәк, Аллаһы тәгалә кайбер кешеләрне, кавемнәрне, халыкларны потларга табына торган халәттә тота. Әлбәттә, болай итү Аллаһының аларны җәһәннәмгә атып җәзаларга теләгәненә күрә түгел, ә рухи үсеш дәрәҗәләре түбән булганга күрәдер. Рухи үсеш дәрәҗәсе дигәндә, әлбәттә, җаннарның дәрәҗәләре күздә тотылырга тиеш. Кешенең дә гамәлләре аның җанынын нинди дәрәҗәдә булуыннан тора ич.

Бу йөздән: ***«Үзебез теләгәннәрнең дәрәҗәләрен югары ашырабыз, һәм һәр белем иясеннән югарырак булган тагын бер белүче бар»*** (12:76), дигән айәтне искә алыйк. Биредә *дәрәҗәләр* [*дәрәҗа́т*] төшенчәсе телгә алына. Әлеге айәттә ул гыйлемлелек дәрәҗәләренең төрле бу-

луын белдерү өчен кулланылган. Ә алдагы айәттә дәрәҗәләр сүзе башка нәрсәләрне күздә тота: ***«гамәлләренә күрә тиешлесе бирелсен өчен һәркемнең кыйлганнарына күрә дәрәҗәләре бар»*** (46:19).

***«Ул сезләрне Үзе биргән нәрсәләр белән сынар өчен кайберләрегезне башкаларыгыздан югарырак дәрәҗәләргә күтәрде»*** (6:165).

***«Аллаһ ризалыгын кайгыртучы берәү Аллаһының канәгатьсезлегенә сәбәпче булуы аркасында торыр урыны җәһәннәм булган берәү кебек булсынмыни? Бикрәк тә ямандыр мондый нәтиҗә! Алар Аллаһ каршында төрле дәрәҗәләрдер, һәм Аллаһ аларның ниләр кыйлганнарын күреп торучыдыр»*** (3:162–163).

Җаннарның дәрәҗәләре турындагы сүзгә без әле, бәлки, киләчәктә әйләнеп кайтырбыз, ә хәзер башка бер нәрсә турында әйтергә кирәк. Уйлап карыйк: ни өчен баягы айәтне аңлауда шул кадәр хәтәр хаталар барлыкка килгән? Ул хаталарның сәбәбе нидә? Ә бит дөрес аңлатылмаган айәтләр бихисап, бу гына түгел, Коръәндә реинкарнация турында бәян итүче айәтләр дә шул җөмләдән. Андый айәтләрне алга таба басылачак мәкаләбездә китерербез, Аллаһ боерса.

*(дәвамы бар)*

### Әдәбият

1. Аль-Мунтахаб фи тафсир аль-Кур’ан аль-Карим. Толкование Священного Корана на русском языке. Перевод с арабского языка. (Первое издание). Казань, 1421 г. хиджры (2001 г.).

## Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар. Хатлар һәм кайтавазлар

## Краеведческие конференции и встречи. Письма и отклики

### ХРОНИКА

25–26 мая 2019 г. в Москве состоялась конференция демократического конгресса народов РФ, на которой обсуждались проблемы и перспективы федерализма в России, развития регионов в контексте межбюджетных отношений, положения родных языков народов РФ и ситуации вокруг их преподавания. В дискуссиях приняли участие кандидат физико-математических наук, старший научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани Академии наук РТ М. Лотфуллин, главный редактор журнала «Туган җир. Родной край», доктор исторических наук Д. М. Исхаков, журналист, политолог, координатор Демократического конгресса народов РФ Р. В. Айсин.

* * *

2019 елның 15 июнендә Актанышта, Ык елгасы бассейнында кеше һәм табигать үсешенә, Актаныш районының тарихына һәм мәдәниятенә багышланган Бөтенроссия фәнни-гамәли, тарихи төбәкне өйрәнү конференциясе үтте. Ул III-нче төбәкара Ык буе Сабантуе – 2019 кысаларында һәм Татарстан АССР оешуга 100 ел тулу уңаеннан гамәлгә куелды.

Конференциядә район җитәкчелеге, республиканың музей-төбәкне өйрәнү берләшмәсе, төрле төбәкләр, республика, Идел-Урал буе вәкилләре, иҗтимагый эшмәкәрләр, галимнәр, төбәкне өйрәнүчеләр, тарихчылар, музей хезмәткәрләре, мөгаллим-белгечләр катнашты.

Көн буе дәвам иткән конференция программасы киңкырлы булып, эш алты секциягә бүленеп алып барылды. Аларда Ык буе авылларының тарихи һәм табигый саклану урыннары турында бай эчтәлекле, кызыклы чыгышлар тыңланды. Төштән соң Әлфия Афзалова исемендәге район мәдәният йортында барган пленар утырышта секцияләр эшенә йомгак ясалып, бергәләп хәл итүне сораган проблемалар күтәрелде, киләчәккә планнар билгеләнде.

* * *

22 июня 2019 в селе Мяндей (Мэндэй) состоялось мероприятие, посвященное памяти и 60-летию знаменитого земляка Хамита Салиховича

Мустакимова (1959–2000). Добрые дела, которые совершил земляк мяндеевцев за свою жизнь на благо родной деревне и района, оставили глубокий след в сердцах и памяти односельчан.

После открытия мемориальной доски, участники и гости собрались в зале Сельского дома культуры, где был презентован фильм, посвященной жизни и деятельности Х.С. Мустакимова. Затем участники и гости посетили в могилу Х.С. Мустакимова в сельском кладбище. В этих мероприятиях принял участие начальник Комитета по работе с краеведами Исполкома ВКТ, председатель РОО «Общество татарских краеведов» РТ, заслуженный деятель науки РТ А.А. Бурханов. На стене Сельского дома культуры с. Мяндей сейчас уже установлены две памятные (мемориальные) доски.

* * *

28 июня 2019 г. в Молодежном центре г. Альметьевска состоялся «круглый стол» по проблемам развития краеведения, сельского и этнического туризма с участием ученых и специалистов, краеведов, сотрудников туристических структур, общественных, религиозных и молодежных организаций Казани, Чебоксар, Альметьевска, Азнакаево, Бугульмы, Лениногорска и сел Альметьевского района РТ. Мероприятие проводилось по инициативе Татарстанского отделения Национальной академии туризма РФ, Центра развития туризма «Золотая подкова» (г. Альметьевск), РОО «Общество татарских краеведов» РТ и Фонда изучения и сохранения историко-культурного наследия «Тамырлар-Корни». В ходе «круглого стола» были обсуждены основные вопросы дальнейшего развития краеведения в районах Юго-Востока Татарстана и сопредельных территорий, подняты вопросы активизации основных направлений и объектов сельского туризма в татарских и чувашских селах Альметьевского и сопредельных районов Татарстана, а также Чувашии.

* * *

В ходе поездки 28 июня 2019 г. по районам Юго-Восточного Татарстана председатель РОО «Общество татарских краеведов» РТ, начальник Комитета по работе с краеведами Исполкома ВКТ, заслуженный деятель науки РТ А.А. Бурханов посетил ряд населенных пунктов региона, встретился с активистами краеведческого движения, учителями и авторами краеведческих книг. В частности, А.А. Бурханов вместе с руководителем Фонда по изучению и сохранению исторического и культурного наследия «Тамырлар-Корни» (г. Альметьевск) М.Н. Туйкиным посетили село Зай-Каратай и провели встречи в рамках подготовки и проведения исто-

рико-краеведческой конференции по истории села и всего Юго-Восточного Татарстана.

В селе состоялись встречи в местной школе и сельской администрации, посетили школьный краеведческий музей и познакомились с экспонатами и материалами по истории села, осмотрели классы и залы школы, а также провели беседы с участием директора школы Л.Ш. Ахметовой, местного краеведа Ж. Халимова и учителей. А.А. Бурханов передал в библиотеку школы книги по истории татарского народа.

* * *

18–22 июня 2019 г. главный редактор журнала «Туган җир. Родной край» принимал участие в г. Горно-Алтайске в работе Всероссийской научно-практической конференции с международным участием «Алтайское языкознание: проблемы и исследования», посвященной 150-летию первой «Грамматики алтайского языка», изданной в 1869 г. в г. Казани. В ходе конференции доктор исторических наук Д.М. Исхаков прочитал доклад на тему «Неизученные аспекты эпоса «Идегей»: вопросы об отражении в дастане социально-политического устройства Золотой Орды». Кроме того, он имел встречу с руководством местной татарской диаспорой, проживающей в г. Горно-Алтайске.

* * *

24 июня 2019 г. доктор исторических наук, главный редактор журнала «Туган җир. Родной край» Д.М. Исхаков участвовал в работе IV Форума гуманитарных наук «Великая степь» (г. Нур-Султан, Казахстан). Им был прочитан доклад на тему «О клановой принадлежности Чуры (Шуры) Нарыкова – главного героя дастана «Чура батыр». В ходе настоящего Форума Д.М. Исхаков был награжден «Золотой медалью» Международной Тюркской академии в связи с вкладом в тюркологические исследования. После завершения конференции он 26–28 июля 2019 г. посетил г. Алма-Ату, где встретился с представителями местной татарской диаспоры и обсудил с ними проблемы включения в готовящуюся Стратегию развития татарского народа разделов, связанных с сохранением культуры и языка татар, проживающих в Казахстане.

* * *

Группа ученых и краеведов из Татарстана и Башкортостана под руководством доктора исторических наук, главного редактора журнала «Туган җир. Родной край» Д.М. Исхакова 14 июля 2019 г. совершила экспедиционный выезд к оз. Аслыкуль и находящемуся недалеко от него легендарному Балкантау, фигурирующим в татарско-башкирском дастане

«Туляк и Сусылу». Целью выезда было изучение и фиксация на фото этой местности. В результате было достигнуто лучшее понимание содержания известного эпического произведения.

* * *

2–4 августа 2019 г. в г. Тобольске Тюменской области проходил XII Международный фестиваль историко-культурного наследия сибирских татар «Искер-жыен». В рамках данного мероприятия, организованного РТОО «Наследие» при поддержке Министерства культуры РТ, Исполкома ВКТ и органов власти Тюменской области, состоялась XIII Всероссийская научно-практическая конференция «Историческая судьба Искера». На конференции выступили с докладом ученые из Татарстана Д. Исхаков, И. Закирова, Ф. Байрамова, И. Кадыров, а в концертной программе фестиваля приняла участие группа татарских артистов Ф. Фатхи, А. Хасанов, Г. Имамиева, Г. Валиева. Кроме татарских участников конференции и фестиваля надо отметить присутствие на мероприятии представителей хакасского, алтайского, тувинского, телеутского и казахского народов. Были на мероприятии и татарские группы из соседних регионов РФ, в частности, из Новосибирской, Омской, Кемеровской областей.

По итогам фестиваля ее участники были награждены грамотами, подарками, в том числе и от имени ВКТ. Среди лауреатов были и дети, часть которых участвовала с номерами фольклорного характера, а также художественным словом и исполнением небольших сценариев на родном языке.

По итогам XIII Всероссийской научно-практической конференции принята резолюция, которая после окончательной доработки будет доведена до органов власти Тюменской области и участников данного форума.

## Төбәк тарихына караган хезмәтләр турында мәгълүмат. Рецензияләр

## Информация о краеведческих трудах. Рецензии

*Луиза Сурметова*

### Ф.ЙОСЫПОВНЫҢ «СЕБЕР ТАТАРЛАРЫ ФОЛЬКЛОРЫ АНТОЛОГИЯСЕ»НӘ КҮЗӘТҮ

2018-нче елның ахырында Төмән шәһәренең мәдәният йортында шушы китапның тәкъдим итү кичәсе үтте. Аннан соң себер татарларының фольклоры буенча яңа, саллы музыкаль хәзинәсен туплаган җыентык дөнья күрде.

Фәрит ага Юсуповның әлеге себер татарларының музыкаль фольклоры буенча антологиясе җирле халыкның гасырлар тирәнлегеннән үзгәртелмичә сакланып килгән тел хәзинәсен, рухи көзгесен, халыкның борынгы төрки уртаклыклары чагылыш тапкан байлык. Бу үрнәкләрне бер җиргә туплап, бер җыентык итеп бүгенге укучыга кайтару әйтеп бетергесез зур эш. Бу авторнын себер татарларының халык авыз иҗатына багышланган хезмәте 4 томлы, беренче томы: «Дастаннар. Мөнәҗәтләр. Бәетләр», икенчесе: «Йомаклар/Әкиятләр», өченче томы: «Хикәятләр. Риваятьләр. Мифлар», дүртенчесе – В.В. Радловның хезмәтен яңадан бастыру. Алар төрле жанрларга багышланган.

Бу хезмәттә автор үрнәкләрне алты жанр төркеменә бүлеп биргән. Иң зур жанрларның берсе: ***«Лирик озын җырлар»***, алар бары 127 үрнәк. Бу жанр борынгы жанрларның берсе булып санала, бүгенге көндә бу өлгеләрне белүчеләр юк дәрәҗәсендә. Себер татарларының чын «озын көйләре» булып саналган үрнәкләре кайсы төбәкләрдә киң таралганнарына һәм иң популяр булганнарына тукталып үтәсе килә: Тубыл һәм шулай ук Бараба татарларында да киң таралган җырларның берсе *«Кара елан»*, *«Сәктәйән пашмак»*, Тубыл һәм Вагай районнарында гына таралган җырлар: *«Усакайлар», «Мәтинәкәй», «Кәшәмир чаршау», «Карлыгаң», «Эскатрон», «Тал пасмакай»*. Аерым тукталып үтәсе килә *«Соло пәйете»*нә (искәртеп шуны әйтеп китәргә кирәк, Вагай районында «пәйет» тип «озын көй» жанрын атыйлар). Безнең тикшерүнәләр күрсәткәнчә, бу көй Вагай районының Тугыз авылында гына кайчандыр киң таралган

булган һәм хәзерге көндә дә себер татарларының иң моңлы, иң борынгы көйләренең берсе дип санала. Хәтта шушы «Соло пәйете» җыры «озын көйләр» жанр бүлеген ачып җибәрә. Шулай ук себер татарларының борынгы дип саналган көйләрнең берсе *«Утыртым кимәнең түренә»* яки аның тагы икенче исеме бар – *«Шәмшәрипкәй»* җыры. Бу үрнәк хәзерге көндә дә яшәп килә, аны соңгы вакытта «Түгәрәк уен» фольклор конкурсында төрле фольклор-этнографик төркемнәре яисә вокаль ансамбльләре башкаруында еш ишетергә туры килә. Омск өлкәсендә яшәүче татарлар арасында гына таралган җырларның үрнәкләре: *«Мәхмүзә», «Саҗидә», «Тау авылы көе», «Балавыз шәм», «Кәлмәт (авылы) көе», «Аргамагым»*, Бараба татарлары арасында танылган җырлар: *«Марьям», «Карчыга», «Камыш көе», «Җаныем, сылуым, бибием»* һәм башкалар. Тагы өстәп шуны әйтергә кирәк, бу бай җыр хәзинәсен, 1968–70 елларда Төмән, Омск, Новосибирск, Томск, Кемерово өлкәләрендә, себер татарларының музыкаль фольклорын ин яхшы белүче – Илгиз Кадыров җыеп алган. Аның бу 50 ел элек яздырып алган материаллары, тиздән чыгачак ноталы җыентыкта 303 җыр, диск аудиоязмасы белән биреләчәк! Ә инде Төмән өлкәсендә 1992–2003-нче елларда без оештырган экспедиция материаллары күрсәткәнчә, кызганычка каршы, бу бай музыкаль мирас безнең көннәргә кадәр сакланып калмаган, аларны белүчеләр, хәтерләүчеләр исән калмаганнар.

Ләкин бу «озын көйләр» жанрына алмашка дияргә була, соңырак барлыкка килгән ***«Авыл көйләре»*** жанры килә. Бу себер татарларының иң яраткан жанрларының берсе, ул башкару ягыннан җиңелерәк, бу көйләрне һәрбер авылда беләләр, төрле көй вариантлары белән яратып башкаралар. Бу хезмәттә дә шушы жанрда 130 үрнәк урын алып тора. Ләкин шуны әйтергә кирәк, автор бу төркемгә «Кыска җырлар» белән «Такмаклар» жанрын бергә бирә. Шуңа күрә, монда бераз буталчык килеп чыга, кайсы үрнәкләр нинди жанрга керәсен тиз генә аңлап бетереп булмый, аларны слогоритмик төзелешләреннән генә белеп була.

Күләме буенча өченче урында ***«Дастаннар»*** жанры. Бу хезмәткә алар 54 үрнәк кергән. Биредә себер татарларының музыкаль мирасының байлыгын күрсәтеп торган дастан көйләре поэтик текстлары белән берничә вариантларда бирелгән, мәсәлән: *«Алып Мәмшән», «Сәйфелмөлек», «Әйтүкә», «Туктасын Мәргән», «Кузы-Көрпәц», «Таһир һәм Зөһрә»*. Шулай ук монда музыкантларыбыз өчен бик тә мөһим һәм кирәкле материаллар бар, югалып барган жанрларыбызның берсе: ***«Инструменталь көйләр»***, алар монда 17 мисал итеп бирелгән. Бүгенге көндә себер татарлары арасында югалган дип саналган жанрларның берсе – ***«Йола йырлары»,*** алар монда бары 16 үрнәк варианлары белән генә күрсәтелгән. Шуның белән

бу көйләр бигрәк тә кыйммәтле. Соңыннан 14 үрнәк белән ***«Бәетләр»*** жанры китә һәм иң аз санлы, бары тик 6 үрнәк – ***«Солдат җырлары»,*** күрсәтелгән. Шуны әйтеп үтәргә кирәк, «солдат җырлары» Төмән регионында бөтенләй танылмаган жанр.

Бу антология булганга күрә, монда күп авторларының хезмәтләре кулланылган. Ф. Юсупов, бөтен үрнәкләрне дияргә була, тыңлап, аларга фонетик транскрипция ясаган, бу эшкә зур өлеш керткән, җырларны нотага бик оста итеп, профессиональ рәвештә салган, Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаган, музыка-белгече, Республика традицион мәдәнияте үстерү үзәге хезмәткәре – Дания Арсланова. Җырларның поэтик текстларын рус теленә оста итеп, себер татарларының теленең байлыгын, музыкаль мирасының матурлыгын күрсәтә белгән тәҗрибәле журналист – Бибинур апа Сабирова. Хәзер бу антологияга кергән хезмәтләрнең һәрберсенә тукталып, әзерәк анализ ясап үтәсе килә.

Себер татарларының рухи мирасы белән ныклап, профессиональ рәвештә төрле Рәсәй галимнәре XX гасырның урталарыннан башлап кына кызыксынып, җыеп өйрәнә башлаганнар. 1940-нчы елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Казан музыкаль фольклор кабинеты Омск, Новосибирск, Төмән өлкәләренә оештырган фәнни экспедиция вакытында язучы Мөхәммәт Садри (14 озын көе, 13 авыл, 6 дастан көйләре) һәм композитор Александр Ключарев (25 озын көйләре, 21 авыл, 5 дастан көе, 3 солдат җыры, 3 инструменталь көе) бик күп бай материаллар алып кайталар. Бу материалларны А. Ключарев 1986-нчы елда (беренче басмасы 1955-нче елда чыккан) тулыландырып, җыентыгында кабат бастырып чыгарган, ә Садри 1989-нчы елда аларны «Иртешкә сәяхәт» исемле китабына керткән. Ключаревның хезмәтендә бу үрнәкләр ноталар белән бирелгән, ә Садри китабында җырларның бары тик поэтик текстлары гына күрсәтелгән.

Әлеге антологиядә, шулай ук 1965-нче елда Тубыл шәһәрендә композитор Җәүдәт Фәйзи яздырып алган себер татарларының кайчандыр бик популяр булган борынгы озын көйләрен *«Усакайлар», «Сахраларда»*, авыл көйләрдән: *«Яңа Атьял», «Ярхәм»* һәм шулай ук *«Солдат җыры»*н табарга була. Бу үрнәкләр аның «Халык җәүһәрләре» исемле җыентыгында 1987-нче елда бастырылган.

Шушы хезмәткә, иң күп үрнәкләр якташыбыз, танылган фольклорчы Флора апа Әхмәтова тарафыннан 1968–1972-нче елларда себер якларында яздырып алынганнары буларак кергән. Монда себер татарларының фольклор үрнәкләренең иң кыйммәтлесе, иң затлы мәрҗәннәрен күрсәткән 33 озын көй, 29 дастан, 13 туй йоласына караган *«Кияү типсәү»* һәм *«Яр-яр»* көйләре вариантлары белән, 8 авыл көе, 7 бәет, 7 инструменталь

көйләре, 2 солдат җыры үрнәкләре зур урын алып тора. Бу хезмәткә, Флора апа тарафыннан җыелган 99 үрнәк кергән, дөресрәге ¼ өлешен аның җыйган материаллары тәшкил итә.

1970-нче елларда безнең якларга музыка-белгече, фольклорчы Мәхмүт Нигъмәтҗанов та аягын баскан. Аның тарафыннан Төмән, Омск, Новосибирск өлкәләрендә җыйган 9 озын, 4 инструменталь, 7 авыл көйләре, 1 бәет үрнәкләре, 1976-нчы елда бастырылып чыккан «Татар халык җырлары» исемле җыентыгына кергән. 1990-нчы еллар башында себер татарларының фольклоры белән кызыксынып киткән, «Төзүче» исемле милләтләр мәдәният йортында методист булып эшләгән, һәвәскәр җырчыбыз Әлминур Патршина да күп кенә материаллар җыеп алган һәм үзенең 2006-нчы елда чыккан китабында аларны бастырып чыгарган. Шулар арасында 13 авыл, 8 озын көйләре, 4 мөнәҗәт, 3 бәет, 1 туй йыры үрнәкләре биредә бирелгән. Әлминур апа ярдәме белән композитор, музыка-белгече Котдус Хөснуллин җитәкчелегендә Казан фольклор үзәге хезмәткәрләре 1996-нчы елда шул ук Вагай районында кабат йөреп тагы да яңа 13 озын җыр, 2 бәет, 1 авыл көе өлгеләре табалар. Болар барысы да, бу антологиядә урын тапкан.

Әйтелгән хезмәткә иң соңгылары булып, 2014–2015-нче елларда Төмән өлкәсенә Казан дәүләт университеты оештырган экспедицияләрдә Фәрит абый Юсупов үзе катнашкан материаллары кергән. Алар монда барысы 23 үрнәк туплаган. Бу вакытта автор себер татарларының онытылып барган озын җырларының берсе *«Эскадрон»*, бик таныш булмаган *«Мәгзәнур әби җыры»*н, хәтта *«Пурихан»* дигән дастан көен дә яздырып өлгерә.

Себер татарларының аерым этнографик төркемнәренең музыкаль фольклорын фәнни яктан җыюга һәм тикшерүгә Новосибирск шәһәренең М. И. Глинка исемендәге дәүләт консерваториясенең профессорлары зур көч куйган. Алар тарафыннан 1999–2008-нче елларда Новосибирск һәм Томск өлкәләрендә шактый фольклор материаллар җыеп алынган. 1992–2003-нче елларда без Төмән регионнында җыеп алган материаллар белән чагыштырганда, жанр ягыннан, бараба һәм чат татарларында да «авыл көйләре» бик популярлылыгын күреп була. Бу антологиядә алар җыеп алган 49 авыл көе урнәкләре кергән, дөрес, алар Төмән өлкәсендә бер дә танылмаган, мәсәлән: *«Апа багла дисәң иде», «Байкал бит ул, байтак бит ул», «Кызыл-кызыл бөрлегән», «Абау, Алла диеп кенә», «Алалмадым, киялмәдем»* һәм башкалар. Озын көйләргә килсәк, бу регионда безнең өлкәдәге шикелле: *«Кара урман», «Шахта», «Зөләйха»* көйләре сакланып калган. Безгә таныш булмаганнары да бар: *«Җир җиләкләре пешкәнче», «Сандугачым икәнсең», «Сандугачның балалары»* һәм баш-

калар. Бер генә үрнәк булса да *«Йола җырлары»*на кергән *«Хан кызы»* җырын яздырып алганнар. Бу материаллар 2013-нче елда чыккан «Народные песни сибирских татар» исемле хезмәттә бирелгән. Аның авторлары Н.С. Капицына белән Н.М. Кондратьева. Бүтән жанрларга килсәк, күргәнебезчә, бәет-мөнәҗәтләр, бишек җырлары, солдат, туй йоласына кагылышлы җырлар, дастан көйләре бөтенләйгә сакланмаган дип әйтергә була.

Новосибирск галимнәреннән, телче Л.В. Дмитриева 1967–1968-нче елларда бараба татарларыннан *«Әйтүкә»* дастанының берничә вариантын яздырып ала һәм үзенең 1981-нче елда Ленинград шәһәрендә бастырылып чыккан «Язык барабинских татар» исемле китабында аны чыгара. Шулай ук 1994–1998-нче елларда Төмән, Омск, Новосибирск, Томск өлкәләренә Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырган экспедицияләр барышында язып алынган хезмәтләргә тукталып үтәсе килә. Дөрия Рамазанованың «Себер диалектларыннан материаллар» (2001) һәм Флера Баязитованың «Себер татарлары» (2002) исемле китапларында җирле халыкның фольклор үрнәкләре дә күп урын алган: монда җырлар, риваятьләр, ырымнар, юраулар, дастаннар бар.

Шулай ук, әйтергә кирәк, бу хезмәттә күренекле тюрколог, галим, академик Вильгельм Радловның 10 томлык фундаменталь хезмәтенең себер татарларының теленә һәм фольклорына багышланган 4-нче томыннан да күп мисаллар кулланылган. Бу исә укучыларга себер татарларының гасырлар буена сакланып килгән байлыгы белән танышырга зур мөмкинлек бирә.

Һәрбер эшнең уңай яклары һәм китек яклары була. Бу хезмәтнең дә кимчелекләренә әзерәк тукталып үтәсе килә. Безнең фикребезчә, техник яктан уйланылып бетмәгән кимчелек яклары бар: ноталар астында күп җырларның бөтен поэтик текстлары да бирелмәгән, шулай ук аларның янәшәсендә тәржемәләре дә юк. Бу бик уңайсыз, мәсәлән, китапны бүтән милләт музыкантлары кулына алса, җырның мәгънәсен, сюжетын аңлар өчен, аңа аның тулы поэтик текстын һәм тәржемәсен китап битләре буенча эзләргә кирәк була. Тагы да зур җитешмәгән ягы: аудиоязма юклык. Тыңлап карарга иде бу информантларны, дигән теләк туа...

Гомумән алганда, Фәрит ага бик зур һәм җитди хезмәт эшләгән. Әлеге антология материаллары киләчәк буынга, шулай ук галимнәребезгә, музыкантларыбызга бик кирәкле һәм файдалы кулланма булыр, дип ышанып калабыз.

## Хушлашу

## Некрологи

### УЛ ЯШӘРГӘ ТИЕШ ИДЕ...

**Самара татарлары зур югалту кичерә**

*[Фәрхәт Махмутов, 27 май 2019 ел]*

Юк-бар сүзләр ишетсәм элек,
Көйсезләнә иде йөрәгем.
Яши-яши, акыл тупланадыр,
Игътибар итмәскә өйрәндем.
Сөйлиләр икән – димәк яшим!
Көнләшерлек итеп, гөрләтеп!
Әллә кайдан сәлам биреп китәм,
Эчләрендә утлар дөрләтеп.
Тартып барган арбам тәгәрмәченә
Тыксалар да кайчак таяклар,
Яннарымда – Раббым, ярдәм бирә,
Һәм нык тора әле аяклар...

Бу шигырьне «Вконтакте» социаль челтәрендәге Фәрхәт Мәхмүтов битеннән табып алдым. Анда ул башкарган күпсанлы эш нәтиҗәләренә багышланган язмалар һәм шушы бердәнбер шигырь эленеп тора. Белмим, аны ул үзе язганмы, әллә кайдандыр алып куйганмы... Хәзер инде моны белә дә алмыйбыз. Ләкин андый шигырьне кую өчен җитди сәбәп булгандыр, дип уйлыйм.

Фәрхәткә бары тик 47 яшь иде. 26 майда ул көнозын бихисап эшләре буенча чаба – өлкә Сабан туен, Камышлыда үткәреләчәк Бөтенроссия авыллары Сабан туен, Казан лагерьларында Самара балаларының җәйге ялын, июньгә билгеләнгән «Самара чибәре» конкурсын оештырырга, ике улын ике якка – балалар бакчасына, мәктәпкә, тренировкаларга илтергә һәм алып кайтырга, шәхси ГАЗель машинасында йөк ташып, бераз акча эшләргә, ә кичен Самараның Җәмигъ мәчетендә уздырылган зур ифтар мәҗлесенә барырга кирәк булган...

Фәрхәт ифтар мәҗлесендә, бер нәрсәгә дә зарланмыйча, кешеләр белән бергә авыз ача, тәравих намазын укыганнан соң, машинасына чыгып утыра һәм кайтып ята. Ә иртән, хатыны Альбина белән бергә, кече

улы Таһирны балалар бакчасына алып барганда, Фәрхәтнең хәле начарлана һәм ашыгыч ярдәм машинасында гомере өзелә. Менә шундый тиз һәм мәшәкатьсез, ләкин бик вакытсыз һәм аянычлы үлем, Самара җәмәгатьчелеген тетрәндерде...




1989-нчы елда Куйбышевта «Туган тел» җәмгыятен оештырып йөргән кешеләр Фәрхәтне беләә башлаганда ул әле мәктәптә укып йөри иде. Татарстанның Аксубай районы, Ибрай авылында туган, әтисе Сабирҗан Хафиз улы һәм әнисе Миңлегөл Хәсәнҗан кызы Мәхмүтовлар Куйбышев өлкәсенең Красный Яр районындагы Ялтай бистәсенә күчеп киткәч, шушы авыл мәктәбендә укып чыккан балада милли җанлылык шулхәтле көчле булган ки, ул хәтта унынчы сыйныфта укыганда әле оештырылып та бетмәгән «Туган тел» оешмасы утырышларына килеп йөргән. Соңрак, армиядә хезмәт итүенең икенче елында, ун көнлек ялга кайткач та, ул тик ятмый, өлкә Сабан туе уздырылган вакытка туры килеп, аны оештыруда һәм алып баруда актив катнаша.

Казан университетының татар тарихы, филологиясе һәм шәрыкъ телләре бүлеген тәмамлап кайткан Фәрхәт «Туган тел» оешмасы каршында яшьләр бүлеген оештырып җибәрә. Ул вакытта оешма бик көчле иде. Аның тирәсендә тупланган студентлар берсеннән-берсе кызыклы шигърият, җыр-бию кичәләре, Яңа ел, 8 Март, 9 Май кебек бәйрәмнәргә һәм истәлекле даталарга карата тематик чаралар, «Яшь зыялылар клубы» утырышлары оештыралар, Сабан туйларына балалар һәм яшьләр мәйданчыклары, яшьләр өчен татар дискотекалары уздыралар иде. Нәкъ Фәрхәт Самара яшьләрен Татарстанның яшьләр лагерьлары белән

таныштырды. Нәтиҗәдә ничәмә буын яшьләребез Казанның кадерле кичләре, Болгар музей-тыюлыгы, Габдулла Тукайның туган авылы Кырлай белән танышып, гомерлеккә татарлык, милләтпәрвәрлек чире белән авырдылар, үзләре олыгайгач, балаларын да татар мәктәбенә укырга алып килделәр, татар лагерьларына җибәреп, татарлык хисләре тәрбияләделәр.

Тик Фәрхәт олыгая алмыйча калды, бугай. «Яктылык» татар мәктәбендә музыка укытучысы булып эшләгән Альбина Мамедалиевага өйләнгәч тә, өч баласы тугач та, ул әле һаман Самара татар яшьләре оешмасын җитәкли иде. Беренче кызы Фәрзанәнең музыкага хирыслыгы билгеле булгач, гаилә ансамбле буларак ТНВ телевидениесе тапшыруларында, конкурс-викториналарда еш катнаштылар. Ә 2008-нче елда Киров мәйданындагы Литвинов исемендәге мәдәният сараенда үткән «Самара – күпмилләтле гаилә» конкурс-фестивалендә Мәхмүтовлар гаиләләренең дүрт буын шәҗәрәсен тәкъдим иткәннәр иде.

Фәрхәт соңгы көннәренә кадәр шәһәр генә түгел, татар районнары белән дә тыгыз элемтәдә эшләде.

*– Камышлы район администрациясенең мәдәният бүлеге белән берлектә Фәрхәт Сабирҗан улы Мәхмүтов безнең балаларны ике ел рәттән Татарстанның «Лидер» лагерена җибәрергә булышты. Укучыбыз Дамир Минһаҗев шагыйрь Әнвәр Давыдовның юбилеена карата язылган хезмәте белән Мәскәү конкурсына бару бәхетенә иреште. Фәрхәт безгә «Тотальный диктант» язарга, «Мирас» I Халыкара фестивалена әзерләнергә, шигърият конкурсы оештыруда зур ярдәм күрсәтте,* – дип сөйләде кайгы уртаклашырга дип шалтыраткан район китапханәсе мөдире Римма Галимуллина.

Биш-алты ел элек, Фәрхәт Сабирҗан улы – «Туган тел» татар җәмгыятенең, ә ике ел элек өлкә милли-мәдәни автономиясенең дә башкарма директоры булып эшли башлагач, аның вазифалары тагын да күбәйде. Ләкин беркайчан да аңардан зарлану сүзләре ишеткәнебез булмады. Киресенчә, ул милләтебезне торгызу эшенә тагын да гайрәтләнебрәк алынды. Урыслаша башлаган кешеләрнең рус телендә сөйләшүен, башка милләт кешеләре белән гаилә коруларын, балаларга ана телен өйрәтмәүләрен бик авыр кичерә иде. Һәрвакыт бу турыда кистереп, үпкәләтерлек итеп әйтеп куярга да ике уйлап тормады.

«Татарларым!» дип өзелеп яшәгән Фәрхәтнең тормышы, чын мәгънәсендә, вакытсыз өзелде. Бигрәк тә аның кечкенә балалары һәм сөекле хатыны Альбинаның олы кайгысы чиксез. Без аларга сабырлык һәм түземлек телибез. Фәрхәт туксанынчы еллар ахырында «Бердәмлек» һәм «Азан» газеталарында да эшләп, матур-матур мәкаләләре белән газета

укучыларын куандырып торган иде. Без аны үзебезнең коллегабыз, фикердәшебез буларак, урынының оҗмахта булуын телибез.

Фәрхәт Сабирҗан улы Мәхмүтовның җәсаде туган авылында – Кызыл Яр районының Ялтай бистәсендә җирләнде. Мәрхүмне соңгы юлга озатырга дип аның сабакташлары, фикердәшләре, дуслары, хезмәттәшләре, туганнары, Ялтай авылы халкы җыелды. Җеназа намазын төбәкара Дини нәзарәте рәисе, мөфти Талип хәзрәт Яруллин үткәрде.

Татар җәмәгатьчелеге өчен бу зур югалту – «Самара татарлары» сайтында аның гаиләсенең, җәмгыятебезнең аны югалтуы турында ихлас күңелдән язылган бик күп яхшы сүзләрне укырга була. Яшь, көчле рухлы, җил кебек җитез, уңган егетебезне югалттык. Арабызда аның кебек үҗәтле, милли җанлы, үз гомерен дә милләт эшенә корбан итәрлек кешеләр тагын бармы? Әлегә аның урынын алырга атлыгып торучылар күренми. Җәмәгать эшендә үзен дә, тапкан малын да халкы өчен, милләт өчен бирергә әзер булган риясыз кешеләр генә эшли ала бит.

Рамазан аенда өч бала белән тол калган Альбина Харис кызы Мәхмүтовага матди ярдәм күрсәтергә теләүчеләр Сбербанк картасына садака җибәрә ала. Карта 89277334148 номерына беркетелгән.

*Эльмира Шәвәлиева, Шамил Галимов.*

## Авторлар буенча белешмә

**Алексеев Игорь Евгеньевич**, Татарстан Республикасы Президентының эчке сәясәт мәсьәләләре буенча Департаментының дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсенең баш киңәшчесе.

**Бакиров Марсель Хәернас улы**, филология фәннәре докторы, КФУ профессоры.

**Батулла Рабит Мөхлис улы**, татар халык язучысы.

**Бугарчёв Алексей Игоревич**, ТФА А.Х.Халиков исемендәге Археология институтының кече фәнни хезмәткәре.

**Бәйрәмова Фәүзия Әүхади кызы**, тарих фәннәре кандидаты, язучы, җәмәгать эшлеклесе.

**Габдуллин Илдус Рашит улы**, тарихчы, төбәк тарихын өйрәнүче, «Әлмәт энциклопедиясе» иҗат төркеме инженеры.

**Гариф Нурулла Гыймадетдин улы**, тарих фәннәре кандидаты, педагогия хезмәте ветераны.

**Гатауллин Ринат Фәйзлтдин улы**, икътисад фәннәре докторы, РФА ӨФҮ СЭТИ.

**Гыйльманов Фәнүр Мөгамбәр улы**, Башкортстанда нәшер ителүче «Кызыл таң» гәҗите хәбәрчесе, БРның атказанган матбугат хезмәткәре, республика хөкүмәтенең Ш.Ходайбирдин ис. Журналистлар премиясе лауреаты.

**Гыймадиев Минзәгыйт Миргасыйм улы**, төбәк тарихын өйрәнүче.

**Закирова Илсөяр Гамил кызы**, филология фәннәре докторы, ТФАның Г.Ибраһимов исемендәге ТӘСИның Халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре, гыйльми совет әгъзасы.

**Измайлов Искәндәр Лерун улы**, тарих фәннәре докторы, ТФАның А.Х.Халиков исемендәге Археология институтының баш фәнни хезмәткәре.

**Исхаков Дамир Мәүләви улы**, тарих фәннәре докторы, РТФА академигы, БТК Милли Шура әгъзасы, журнал мөхәррире.

**Минһаҗев Рәшит Рәкыйп улы**, «Ватаным Татарстан» газетасының бүлек мөдире.

**Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы**, филология фәннәре докторы, доцент, ТФАның Г.Ибраһимов ис.ТӘСИның баш фәнни хезмәткәре, гыйльми совет әгъзасы.

**Нигъмәтҗанов Томас Тимерхан улы**, ТР һәм РФ журналистлар берлеге әгъзасы, «Теплоконтроль» акционерлар җәмгыяте Казан приборлар төзү предприятиесе баш метрологы.

**Норлан Балгынай**, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институты студенты, кинорежиссер. Өремче шәһәреннән (Кытай).

**Нуриева Фәнүзә Шәкүр кызы**, Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге фәнни хезмәткәре, КФ(П)У татар теле белеме кафедрасы профессоры, филология фәннәре докторы.

**Нәбиуллин Фәнис Масабих улы**, табиб, психогенетик, гаилә-туганлык системалары буенча белгеч.

**Саначин Сергей Павлович**, архитектор, төбәк тарыхын өйрәнүче.

**Степанов Олег Витальевич**, нумизмат-тикшерүче, туган якны өйрәнүче, БТК каршындагы Гомумтатар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте идарәсе әгъзасы.

**Сурметова Луиза Рәис кызы**, Төмән шәһәренең 18-нче китапханә мөдире, себер-татар халык һәм эстрада җырларын башкаручы, Халыкара һәм Бөтенроссия конкурс-фестивальләре лауреаты, филология фәннәре кандидаты, музыка белгече, фольклорчы.

**Таҗиев Дамир Нәзир улы**, РФ Журналистлар берлеге әгъзасы, Р.Төхфәтуллин исемендәге бүләк иясе, Әлмәт төбәгенең җәмәгать эшлеклесе, төбәк тарихын өйрәнүче.

**Хәйретдинов Айдар Гарәфетдин улы**, фәлсәфә фәннәре кандидаты, доцент, ТФАның Ш. Мәрҗани ис. Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре.

**Шәйдуллина Равиля Шамил кызы**, эшмәкәр һәм бизнесмен, язучы, «Ел китабы – 2016» республика бәйгесе дипломанты.

**Әмирханов Рәфыйк Хәзыйм улы**, Татарстан Республикасының атказанган нефтчесе, «Әлмәт энциклопедиясе» иҗат төркеме җитәкчесе, төбәк тарихын өйрәнүче.

## Сведения об авторах

**Алексеев Игорь Евгеньевич**, кандидат исторических наук, главный советник Управления по взаимодействию с религиозными объединениями Департамента Президента Республики Татарстан по вопросам внутренней политики.

**Амирханов Рафик Хазимович**, заслуженный нефтяник РТ, руководитель творческой группы «Альметьевская энциклопедия», краевед.

**Байрамова Фаузия Аухадиевна**, кандидат исторических наук, писательница, общественный деятель.

**Бакиров Марсель Хәернасович**, доктор филологических наук, профессор КФУ.

**Батулла Рабит Мухлисович**, народный писатель РТ.

**Бугарчёв Алексей Игоревич**, младший научный сотрудник Института археологии им. А. Х. Халикова АН РТ.

**Гатауллин Ринат Файзлтдинович**, доктор экономических наук, профессор, ИСЭИ УФИЦ РАН.

**Габдуллин Илдус Рашитович**, историк-краевед, инженер творческой группы «Альметьевская энциклопедия».

**Гариф Нурулла Гыймадетдинович**, кандидат исторических наук, ветеран педагогического труда.

**Гильманов Фанур Мугамбарович**, корреспондент газеты «Кызыл таң», заслуженный работник СМИ РБ, лауреат журналистской премии Правительства РБ им. Ш. Худайбердина.

**Гимадеев Минзагит Миргасимович**, краевед.

**Закирова Илсеяр Гамиловна**, доктор филологических наук, главный научный сотрудник отдела народного творчества ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, член ученого совета.

**Измайлов Искандер Лерунович**, доктор исторических наук, главный научный сотрудник Института археологии им. А. Х. Халикова Академии наук Республики Татарстан.

**Исхаков Дамир Мавлявеевич**, доктор исторических наук, академик РАЕН, член Национального Совета Всемирного конгресса татар, редактор журнала.

**Мингазов Рашит Ракипович**, редактор отдела газеты «Ватаным Татарстан».

**Мухаметзянова Лилия Хатиповна**, доктор филологических наук, доцент, главный научный сотрудник ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, член ученого совета.

**Набиуллин Фанис Масабихович**, врач, психогенетик, специалист по семейно-родовым системам.

**Нигаматзянов Томас Тимерханович**, член Союза журналистов РТ и РФ, главный метролог Казанского приборостроительного предприятия АО «Теплоконтроль».

**Норлан Балгынай**, студент Казанского государственного института культуры и искусств, кинорежиссер. КНР, г. Урумчи.

**Нуриева Фануза Шакуровна**, доктор филологических наук, научный сотрудник ГБУ «Республиканский центр развития традиционной культуры», профессор кафедры татарского языка КФ(П)У.

**Саначин Сергей Павлович**, архитектор, краевед.

**Степанов Олег Витальевич**, исследователь-нумизмат, краевед, член Совета Всетатарского общества краеведов Всемирного конгресса татар.

**Сурметова Луиза Рәисовна**, кандидат филологических наук, заведующая библиотекой №18 МАУК ЦГБС г. Тюмень, исполнительница сибирскотатарских народных и эстрадных песен, лауреат Международных и всероссийских конкурсов-фестивалей, музыковед-фольклорист.

**Тазиев Дамир Назирович**, краевед, член Союза журналистов РФ, лауреат премии имени Рафаила Тухватуллина, общественный деятель г. Альметьевска, сотрудник ООО «ТаграС-ХимСервис».

**Хайрутдинов Айдар Гарифутдинович**, кандидат философских наук, доцент, старший научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани АН РТ.

**Шайдуллина Равиля Шамиловна**, предприниматель и бизнесмен, писательница, дипломант республиканского конкурса «Книга года – 2016».

# ИНФОРМАЦИЯ ДЛЯ АВТОРОВ

Редакционный совет журнала «Туган җир/Родной край» сообщает что к публикации принимаются статьи и материалы как на татарском, так и на русском языках. В этой связи обращаемся ко всем заинтересованным в развитии указанного журнала авторам с предложением принимать участие в его издании. Для этого необходимо подготовить и направить соответствующие статьи в наш адрес.

Рекомендуемая тематика публикаций:

- методика и методология историко-краеведческих исследований;
- история краеведения и историко-краеведческое наследие;
- проблемы региональной истории;
- новые археологические, нумизматические, фольклорные и эпиграфические находки;
- публикация источников;
- история конкретных сел и деревень;
- история музеев и публикация музейных коллекций;
- жизнь и деятельность выдающихся краеведов и земляков;
- использование краеведческих материалов и музейных коллекций в школе;
- популярные статьи по краеведению;
- краеведческая хроника (конференции, встречи и т.д.);
- рецензии, обзоры книг на краеведческую тематику.

Статьи оформляются согласно указываемым ниже требованиям:

### *Технические требования к оформлению статей*

*1. Внутри публикаций ссылки оформляются следующим образом* [Аминов 2017. С. 82.]; [Денисов 2012. С. 25; Черкас 2005. С. 16.]; [ГАОО. Ф 476. Оп. 3. Ед. хр. 609. Л. 6.]

*2.* Список использованной литературы оформляются согласно ГОСТу и приводятся в алфавитном порядке в конце статьи в виде нумерованного списка:

### *Источники и литература*

1. Аминов Р. Р. Татары-казаки в составе Оренбургского казачьего войска (1748–1917 гг.). Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2017. – 348 с.

*2.* Государственный архив Оренбургской области (ГАОО). Ф. 98. Оп. 2. Ед. 25.

3. ГАОО. Ф. 98. Оп. 2. Ед. 26.

4. *Денисов Д.Н.* Очерки по истории мусульманских общин Оренбургского края (XVIII – начало XX в.). М. – Н. Новгород: Издательский дом «Медина», 2012. – 410 с.

5. Черкас Т.Г. Хронограф города. Орск: [Б.и.], 2005. – 67 с.

***Редакционные требования к оформлению*:**

Инициалы и фамилия автора указываются справа, далее по центру публикации идет название статьи.

1. Текстовый редактор – Microsoft Word, в формате doc или docx.
2. А4.
3. Поля: слева – 3 см., справа –1,5 см. сверху и снизу – 2 см. Нумерация страниц снизу справа.
4. Шрифт – Times New Roman
5. Размер шрифта – 14
6. Межстрочный интервал – 1,5
7. Абзацный отступ – 1,0

***Требования к иллюстративным материалам*:**

Фотоматериалы и рисунки (сканкопии) принимаются только качественные (в формате JPEG, объемом не менее 3,50 МБ).

Объем публикаций в пределах от 0,5 до 1,0 п. л. (20 000–40 000 знаков с пробелами). К публикациям прилагаются аннотации из 5–6 предложений, а также выделяются ключевые слова (4–5).

***Сведения об авторе:***

1. Фамилия, имя, отчество ______________________________
2. Ученая степень ______________________________
3. Ученое звание ______________________________
4. Занимаемая должность ______________________________
6. Почтовый адрес с индексом ______________________________
7. Адрес электронной почты (e-mail) ______________________________
8. Контактный телефон ______________________________

Редакция отмечает, что после получения статьи от автора и детального его изучения членами редколлегии она в случае соответствия всем требованиям передается в печать. Если материалы не соответствуют техническим и научным требованиям, статья возвращается автору с замечаниями для устранения недостатков. В связи с большим объемом поступающих материалов редколлегия может ограничиться пересылкой автору, в случае необходимости, соответствующих правил оформления для приведения ее в соответствие с требованиями.

Редколлегия оставляет за собой право размещения публикаций в журнале согласно рубрикаций и наличия мест в выпускаемых номерах. После выхода журнала авторы статей могут получить по одному экземпляру издания.

Авторам выплачивается гонорар. Для этого необходимо вместе с материалом прислать сканкопии паспорта, ИНН, СНИЛС, счет со всеми банковскими реквизитами.

Электронная версия журнала размещается на сайтах Всемирного конгресса татар и «Всетатарского общества краеведов».

Материалы следует присылать по эл.адресу: monitoring_vkt@mail.ru с указанием темы: «Для журнала «Туган җир/Родной край». Допускается и прямая передача публикаций в редакцию, но лишь в электронных версиях. Для этого указываем адрес нашего журнала: Казань, ул. А. Пушкина, 52, офис 303, редакция журнала «Туган җир/Родной край».

# Туган җир

*Төбәк тарихы буенча журнал*

# Родной край

*Краеведческий журнал*
3’2019

Подписано в печать 27.08.2019 г. Формат 70×100 1/16
Усл. печ. л. 19,5 Тираж 1000 экз.
Отпечатано с готового оригинал-макета.
в типографии ООО «Грумант»
В данном номере журнала использованы фотографии из личных архивов авторов



Балкан тау



Төбәк тарихын өйрәнүчеләр, Татарстан һәм Башкортстан галимнәре
Балкан тауда


Актанышта фәнни-гамәли конференция


Д.М. Исхаковны Халыкара Төрк академиясенең “Алтын медале”
белән бүләкләү. Алматы (Казахстан)



Чәүчәктәге милләттәшләребез



Уйгыр каганы Моюн-Чураның искә алу комплексы  (Сайхан Аймак, Монголия)



Төмән шәһәрендә «Себер татарлары» китабы презентациясе



Себертатар кызлары Искер җыенда

